www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 6 (1371) 18 февраль 2022 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga



8

XIX йөздә диннәре өчен ватаннарыннан куылган татарлар ерак Себердә дә аклыгын-пакьлеген, белемгә омтылышын саклап калган.

13

Чираттагы иҗат җимешен халыкка тәкъдим иткәнче, тимерче Ренат Нуретдиновка эретеп ябыштыручы да, химик та булырга туры килә.



14

Әфганстан, Пакыстан таулары арасында гомер кичерүче ак битле, сары чәчле калаш халкы йөз-кыяфәтләре генә түгел, гореф-гадәтләре белән дә аерылып тора.

Кышларда да бер хушланыйк әле Балык шулпасының татыннан!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казахстан Президенты Касым-Жомарт Токаевка «Дуслык» ордены тапшырды.

- 1896 елның 4 февралендә Шәһәр Думасы карары белән Александр Пушкин исемендәге беренче халык китапханәсе ачылуына нигезләнеп, Алабуга үзәк китапханәсенә Александр Пушкин исеме бирелде.

- Татарстан Язучылар берлегенең 8 апрель көнне узарга тиешле чираттан тыш корылтаенда Берлек уставына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе дә каралачак.

- «Шәһәр үзәгенең туристлык коды» федераль конкурсына Казанның Иске Татар бистәсендә Таҗи Гыйззәт урамыннан Вахитов мәйданына кадәр 100 гектар территорияне төзекләндерү һәм сәнгатьчә бизәү концепциясен тәкъдим итәчәкләр.

- Самара шәһәренең «Яктылык» мәктәбендә «Яктылык» татарча сөйләшә» милли проекты гамәлгә ашырыла.

- Казанда Р. Нуриев фестивале кысаларында Рудольф Нуриев турында 7 фильм күрсәтеләчәк.

- Драматург, актер, режиссер Кәрим Тинчуринның 135 еллыгы уңае белән Тинчурин театрында «Театр яктылыкка, нурга илтә!» дип аталган экскурсияләр үткәрелә.

- Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» татар музыкасы фестиваленең икенче концертында Мәсгудә Шәмсетдинова һәм Канадада яшәүче татар дирижеры Айрат Ишморатов әсәрләре яңгырады.

- Эпидемиологик вәзгыятьне исәпкә алып, Уфа «Нур» театрының Казанга гастрольләре февральдән көзгә күчерелде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Илшат РӘХИМБАЙ, режиссер, продюсер:

«Үзебезне дәүләт акчасына бәйләп куябыз да, аннан ярдәм көтәбез һәм кайда бүген безнең кинематография? Ул – юк. Фильм – ул бизнес белән иҗат көрешкән бер урталык. Каяндыр акча аласың икән, аны кайтару ягын да уйларга тиешсең. Дөрес, фильмнар төшерү – бар очракта да үзен акламаска да мөмкин бизнес, әмма индустрия буларак бүген ул дәүләттән торырга тиеш түгел».

СЫНАМЫШЛАР

Салкын көндә кар яуса – җылыта ● Төнлә ай зур, кызгылт күренсә – җепшекләтә ● Ала каргалар агачның иң өске ботакларына кунып чистарынса, тавыклар кытакласа, тиздән кар ява ● Кар түбәләрдән салынып төшсә, җәйгә иген уңа ● Кояш бик еракта булып күренсә, көннәр суыта.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 01 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 54 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **9 сәгать 53 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озыначак** һәм киләсе җомгада, ягъни **25 февральдә 10 сәгать 25 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

18 февраль – язучы, Татарстан һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Рәфкать Кәраметдин улы Кәрамиевкә 80 яшь (1942);

– социология фәннәре докторы, педагог, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Флюра Газиз кызы Зыятдинованың тууына 75 ел (1947–2011).

20 февраль – монументаль сәнгать рәссамы Нурхәтим Зариф улы Бикколовның тууына 85 ел (1937–2018).

23 февраль – рәссам, сынчы, педагог, Татарстанның, Россиянең халык рәссамы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Бакый (Габделбакый) Идрис улы Урманченың тууына 125 ел (1897–1990);

– Татарстан һәм Башкортстанның халык артисты, җырчы, җәмәгать эшлеклесе Айдар Гани улы Галимовка 55 яшь (1967).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Февральнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(16-24 февраль)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 февральдән 29 апрельгә кадәр** бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

###ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген рәҗәб аеның 17 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рүзәл ЮСУПОВ

Алгарыш нигезе – әдәби тел



Соңгы берничә дистә елда Җир шарында яшәүче аз санлы халыкларның телләре борчулы халәттә: ЮНЕСКО мәгълүматлары күрсәткәнчә, дөньядагы 6 меңләп телнең яртысына якын арада юкка чыгу куркынычы яный. Хәлнең җитди булуын аңлап һәм халыкларның кыйммәтле милли мирасларын саклап калуны кайгыртып, бөтендөнья оешмасы ЮНЕСКО 1999 елның ноябрендә 21 февральне Халыкара туган тел көне дип игълан итте. Шул вакыттан бирле бу көн халыкларга һәм аларның хөкүмәтләренә телләрне, бигрәк тә аз санлы халыкларның һәм этносларның телләрен саклау өчен, барлык чараларны күрергә кирәклекне искәртеп торган дата буларак билгеләп үтелә.

Бу уңайдан ЮНЕСКОның Генераль директоры Коитиро Мацуура барлык дәүләтләргә гаять әһәмиятле мөрәҗәгать җибәрә. Анда болай диелә:

“...Күп телләр мәгариф системасында, мәгълүмат чараларында, нәшриятта һәм гомумән иҗтимагый өлкәләрдә кулланылмый... Ашыгыч чаралар күрергә кирәк... Һәр милләтнең үзенең беренче телен яки туган телен куллана алуына, шуның белән бергә мәгариф өлкәсендә милли яки региональ һәм халыкара телне үзләштерә алуына юнәлтелгән тел сәясәтен үткәрергә. Өстенлекле тел ияләрен шулай ук башка милли яки региональ телне һәм ике халыкара телне үзләштерүләренә өндәргә. Аңлы рәвештә күп теллелек кулланылганда гына барлык телләргә дә дөньядагы глобальләшү чорында үз урыннарын табу мөмкин булачак.

ЮНЕСКО Берләшкән милләтләр оешмасы системасындагы хөкүмәтләргә, учреждениеләргә, гражданлык җәмгыяте оешмаларына, уку йортларына, һөнәр ассоциацияләренә һәм практик файдасын күрерлек башка барлык оешмаларга бөтен телләргә, бигрәк тә юкка чыгу куркынычы янаган телләргә, индивидуаль һәм коллектив тормышның бөтен очракларында да хөрмәт белән карау, ярдәм итү һәм аларны саклау мәнфәгатьләрендә кылган гамәлләрен активлаштырырга”.

Аяныч: Россиядә ЮНЕСКО Генераль директорының бу мөрәҗәгатенә игътибар итмиләр, хакимият руслардан башка халыкларның телләренә хөрмәт белән карый һәм аларны саклый дип әйтеп булмый. Киресенчә, соңгы елларда рус теленнән башка телләрнең иркен кулланылуы өчен мәйдан көннән-көн тарая. Кайбер шовинистик карашлы идеологларның “бер милләт, бер тел, бер дәүләт” дигән лозунглары гамәлгә ашырыла. Үзәк хакимият карары белән дәүләтнең мәгариф стандартларындагы милли компонент бетерелде, гомуми белем бирү уку йортларында милли телләр, факультатив предмет итеп, атнасына ике сәгать кенә укытыла башлады, милли мәктәпләрдә чыгарылыш имтиханнарын рус телендә тапшыру тәртибе урнаштырылды һәм шуның аркасында татар мәктәпләрендә русча укытуга күчү бара. Соңгы берничә елда гына да йөзләрчә татар мәктәпләре ябылды. Гаҗәп хәл: руслардан башка балаларның туган телләрен, милли әдәбиятларын һәм үз халкының тарихын өйрәнүдә бу һәм башка төрле чикләүләр Россия Федерациясенең дә, республикаларның да конституцияләрен бозып гамәлгә ашырыла. Демократиягә каршы килә торган чаралар күрү аркасында яшьләрнең күбесе туган телләрен, милли мәдәниятләрен һәм тарихларын үзләштерүдән мәхрүм итеде. Бу хәл цивилизациягә дөнья кешеләренең табигый ихтыяҗларын үтәү хокукын юкка чыгара.

Табигатьтән бирелгән тулы хокуклы, акыллы булып туган кешеләр, күктән бәхет яуганын, халык, милләт, этнос буларак сакланулары өчен кемнәрнеңдер кулай шартлар булдырганын көтеп тормыйча, кичектермичә, миллилек сыйфатларын саклау чараларын үзләре күрә башларга тиеш.

Бай тарихлы, алдынгы мәдәниятле, борынгы дәүләтле татар халкы, туган теленең абруе түбәнәя, кулланылышы кими баруын һәм яшәешенә куркыныч янавын тыныч кына күзәтеп, аның югалуын көтеп торырга тиеш түгел. Туган теленең, кулланылыштан туктап, югала баруына риза булып торган халыкны киләчәк буыннар гафу итмәс. Хәер, безнең халык андый түбәнлеккә төшмәс, анда әле кыюлык сыйфатлары югалып бетмәгәндер, һәм, димәк, ул милләтнең нигезен тәшкил иткән туган телен саклау өчен тиешле чаралар күрер дип фараз итик.

Татар телен, саклап, кулланылышын җәелдерә баруның нигезе, милли мәгариф системасын савыктырып, аның нәтиҗәлелеген күтәрүдә, шул ук вакытта татар балаларына ана телләрен укытуны яхшыртуга һәм камилләштерүгә зур игътибар бирүдә.

Татар телен укыту формалары мәсьәләсендә аларның әһәмиятләре буенча дәрәҗәләрен билгеләү мөһим. Хикмәт шунда: татар телен өйрәнүгә мөнәсәбәтле кешеләр арасында баланы татарчага гаиләдә өйрәтүгәме, әллә мәктәптә укытуга өстенлек бирергәме дигән бәхәсләр булгалый. Андый сүз көрәштерүләр белән, безнеңчә, үзенә тапшырылган эшнең нәтиҗәсе өчен җавап бирергә әзер булмаган яки теләмәгән кешеләр шөгыльләнә. Балаларга телне гаиләдә өйрәтү әһәмиятлерәкме яки мәктәптә укытумы дигән сорау буенча бәхәсләр буталчыклык кына китереп чыгара һәм бу гаять әһәмиятле эшкә зыян гына китерә. Мондый бәхәснең кирәге юк, чөнки тел өйрәтүнең бу ике формасына да ихтыяҗ зур.

Балаларына ана телен өйрәтү, туган телләреннән башлангыч белем бирү – һәр ата-ананың, бигрәк тә ананың изге бурычы. Аннары аларның ул белемнәре табигый рәвештә башка кешеләр белән аралашу мохитендә камилләштерелә. Ләкин балаларның туган телләреннән ул белемнәре, нигездә, сөйләм теле дәрәҗәсендә була. Аларның телне ничек белүе, ата-аналарның белемнәренә карап, төрлечә була. Балаларның туган телләрен гаиләләрендә һәм аралашу процессында алган белемнәре нинди генә булмасын, ул белемнәрне әле мәгариф мохитендә – уку йортларында камилләштереп, әдәби тел дәрәҗәсенә җиткерергә кирәк була. Табигый, гаиләдә ныграк белем алган балалар уку йортларындагы белем алу системасына тизрәк һәм җиңелрәк кереп китә. Һәм аннан соң телдән гаиләдә белемнәре зуррак булган балалар гомумән белем дәрәҗәләре буенча, гадәттә, алдагы сафларда була. Шуңа күрә балага туган телен башта гаиләдә ныклап өйрәтергә тырышырга кирәк.

Ләкин хәзерге вакытта күп татар гаиләләрендә баланы ана теленә өйрәтү мәсьәләсендә җитди проблема бар. Ул шуннан гыйбарәт: Россия халыкларында, күп гасырлар буена дәвам итеп килгән социаль һәм милли тигезсезлек сәбәпле, өстенлек бирелгән рус теленең башка телләргә караганда мөмкинлекләре күпкә зуррак булган. Шунлыктан руслардан башка халыклар һәм этнослар, үз телләренә зыян китереп, рус теленә беренче урынны бирергә мәҗбүр ителгән. Туган теленең озак вакытлар шулай кимсетелгән хәлдә булуы аркасында, татарларның күбесе үз телләрен начар белә яки бөтенләй белми башлаган, күп татар ата-аналары балаларын туган телләренә өйрәтә алмаслык хәлгә килгән. Бу аяныч хәлне исәпкә алып, үз милләтенең саклануы һәм теленең иркен кулланылуы өчен җаваплы республика җитәкчеләре үзләренә шушы бик әһәмиятле ике бурычны куеп эш итәргә тиеш: кичектермичә, милли мәктәпләрне арттырып, татар укучыларына туган телләрен укытуның дәрәҗәсен күтәрү һәм урта буын кешеләренең дә туган телләрен яхшылап өйрәнүе өчен мөмкинлекләр булдыру.

Шулай итеп, без, балаларга гаиләдә туган телләрен өйрәтүнең зур әһәмияткә ия булуын инкяр итмичә, ана теленнән тулы белем бирүнең төп формасы уку йорты дигән нәтиҗә ясыйбыз. Хакыйкать шул: туган телен нәкъ менә гомуми белем бирү һәм махсус урта, югары уку йортларында өйрәтү нәтиҗәсендә яшь буын камил әдәби телне үзләштерә ала. Халыкның әдәби телгә ия булуы исә – аның алдынгы милләт дәрәҗәсенә ирешүенең бер шарты. Димәк, татар халкының алдынгы милләт булып уңышлы рәвештә алга баруының нигезе – аның татар уку йортларында өйрәтелә торган әдәби телгә ия булуы.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидегән
вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

ХАЛЫКНЫ ХАКИМИЯТТӘН ЧИТЛӘШТЕРҮ ҖАЕ

Россиядә «хакимият вертикале» төзүнең соңгы этабы – җирле үзидарәне аның түбән баскычы итеп үзгәртү сөреше бара. Парламент күпчелеген һәркемгә билгеле партия тәшкил иткән Дәүләт Думасына җирле халыклар өчен мөһим ул закон проектын 25 гыйнварда беренче укылышта кабул итү өчен нибары 35 минут вакыт кирәк булган. Тулы исеме «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» дип аталган әлеге проектны (авторлары – халыкта яманатлы шул ук А.Клишас һәм П.Крашенинников) гади телгә күчерсәк, ул илдә җирле үзидарәне, «хакимият вертикале»нә яраклаштырып, аның түбән баскычы итеп үзгәртүне аңлата. Закон проекты Россиядә моңа кадәр гамәлдә булган ике дәрәҗәле (округ һәм җирлек) җирле үзидарәне 2028 елга кадәр бер дәрәҗәле (муниципаль яки шәһәр округлары) итеп калдыруны күздә тота. Димәк, әлеге көчеш чорында беренче дәрәҗә муниципалитетлар (авыл һәм шәһәр җирлекләре), үзара кушу юлы белән зурайтылырга һәм, муниципаль яки шәһәр округлары итеп үзгәртелергә, агломерацияләргә җайлаштырылырга тиеш була. Закон проекты шулай ук барлык мэрлар өчен дә вәкаләт срогын бердәй – 5 ел итеп билгели, төбәк җитәкчеләренә муниципалитет башлыкларын билгеләгәндә турыдан-туры катнашу хокукы, ул гына түгел, эш дәверендә аны вазифасыннан бушату хокукы да бирә. Димәк, җирле түрәләр халык алдында түгел, режим каршында гына җаваплы булачак. Проект кабул ителгәч, яңа тәртип инде 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә дә керәчәк.

Әлбәттә, проект авторлары законның яхшы ният белән әзерләнүе турында әйтә. Имеш ул, халык һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә, илнең тотрыклы социаль-икътисади үсеше өчен шартлар тудырачак. Чынлыкта исә, җирле үзидарәнең халыкка иң якын торган һәм чагыштырмача мөстәкыйль саналган өлеше – шәһәр һәм авыл җирлекләре урынына «хакимият вертикале» вәкилләре куелачагын, ә муниципаль һәм шәһәр округларында сайлаулар шул ук «вертикаль» законнары буенча үтәчәген дә исәпкә алсак, яңа законның халыкны хакимияттән читләштерү өчен кертелүе инде шик уятмас. Татарстанда аңа мөнәсәбәт, әлбәттә, үзенчәлекле булды. Туган телләр мәсьәләсе хәл ителгәндәге кебек үк, Дәүләт Советы концептуаль планда бу проектны да бәхәсләр ачмыйча гына хуплады. Моны исә «ике дәрәҗәле муниципалитетлар дөньяда бер җирдә дә юк», дип аңлаттылар. Шулайдыр, тик демократик илләрдә бит халык, муниципалитетларны гына түгел, хәтта шериф вә судьяларны да үзе сайлый, ә Россиядә барысы да «вертикаль» буенча билгеләнә. Аерма иң элек менә шунда (ә, нәтиҗә буларак, халыкның тормыш дәрәҗәсендә дә). Рәсми хәбәрләр буенча, Татарстанда иске система әле 2025 елның сентябренә кадәр сакланачак. Ә аннан соң инде яңа закон буенча анда ике шәһәр округы (Казан һәм Яр Чаллы) һәм муниципаль округлар (43 районда, авыл җирлекләре нигезендә) формалаштырылачак. ТР Дәүләт Советы исә әлеге закон проектының 16 мартта Дәүләт Думасында узачак икенче укылышына вак-төяк 13 төзәтмә тәкъдим итү белән генә чикләнде.

Игътибарны проект авторларының, төбәк хакимияте турындагы закон кебек үк, бу проектны да илдә законнарны Конституциягә кертелгән төзәтмәләргә тәңгәл итеп үзгәртү ихтыяҗы белән аңлатуы җәлеп итә. Тик, күренә ки, әлеге проект илдә хакимиятнең төп чыганагы булган халыкны аннан аеруны күздә тота, Конституциянең нигезен какшата. Ә Төп Законга 2020 елда кертелгән төзәтмәләр андый үзгәрешләрне күздә тотмый. Хәлбуки, тәкъдим ителгән закон проекты Россиядәге төп халыкларның Конституциядә беркетелгән хокукларын да исәпкә алмый: алар тупланып яшәгән муниципаль округларда җирле үзидарә теле статусы каралмаган, туган телдә белем алуның да реаль юлы күрсәтелмәгән. Әлбәттә, бу мәсьәләләр иң элек Россия төбәкләрендә (үз тарихи ватаннарында) тупланып яшәгән татар халкына кагыла. Аның милли-мәдәни тәэмин ителеше дә әлегә ачык кала. Кызганыч, Татарстан парламенты бу мөһим мәсьәләләрдә дә төзәтмәләр тәкъдим итү һәм үткәрүне кирәк тапмаган, гәрчә республика Конституциясе андый кайгыртуны күздә тотса да. Мондый шартларда инде кала вә салаларда тупланып яшәгән милләттәшләребезгә бер генә юл кала: халкыбызның сыналган мәхәллә һәм җыен системаларын яңадан торгызу.

Фоат УРАЗАЙ.

Атналык гимназиядә башланды

Муса Җәлил-Илһам Шакиров атналыгы Казанның Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә ике бөек шәхес истәлегенә багышланган театраль-музыкаль кичә белән башланып китте.

Илһам ага Шакировның дөньяның төрле кыйтгаларына таралган татарлар үз итеп һәм яратып «Илһамыбыз» дип йөртте. Татарстанның халык артисты Гөлзада Сафиуллина искәрткәнчә, халык җырчысы Илһам Шакиров үзенең җырлары белән барлык татарларны берләштерде, бер гаиләгә җыйды. Бу уйлар экранда видеоязма аша яңгыраган «Иске карурман» җырын тыңлаганда тагын да ныгый төште.

Илһам Шакировның ярдәмчесе Илһам Хаҗиев та җырчының беркайчан да фонограммага җырламавы турында сөйләде. Гимназия укучылары да үз осталыкларын күрсәтте. Патриот шагыйрь Муса Җәлилнең тормышына һәм сүрелмәс иҗатына багышланган, сәхнә күренешләре белән тулыландырылган әдәби-музыкаль композиция (авторы – Диләрә Фәттахова) гаять тәэсирле иде.

Театраль-музыкаль кичәдә шулай ук Татар балалар музыка мәктәбендә И.Шакиров исемендәге «Кабатланмас моң» I республикакүләм вокаль-инструменталь конкурс үткәрелүе дә искә алынды, дүрт номинациядә узган бәйгедә 300дән артык төрле буын башкаручысы үз осталыкларын күрсәткән.

Сәхнәдә конкурс җиңүчеләре Муса Җәлил шигырьләрен сөйләде, Илһам Шакиров репертуарындагы җырларны башкарды. Илһам ага репертуарындагы «Ай былбылым»ны күмәк җырлау, аның «Әй киң төрки даласы»н башкару да балаларның хәтерендә калгандыр.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Бала сити» полилингваль балалар бакчасы җитәкчесе Альбина Насыйрова, Казан мәгариф идарәсеннән Рәйхана Баһавиева да бай эчтәлекле бәйрәм оештырылуы өчен рәхмәтләрен ирештерде. Ә инде Россия Герое, очучы-космонавт, якташыбыз Сергей Рыжиковның видеоэлемтә аша рус телендә Муса Җәлил шигырен сөйләве кунакларга да, залда утырган балаларга да көтелмәгән зур бүләк булды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Метро станцияләренә исем сайлыйбыз

Казанның рәсми порталында метрополитенның икенче линиясе станцияләренә исемнәр сайлау буенча сораштыру тәмамланды. Берничә көн генә үткәрелгән тавыш бирүдә 5414 кеше катнашты.

Сораштыру нәтиҗәләре буенча, Фучик һәм Зорге урамнары чатындагы метро станциясе өчен катнашучыларның күбесе «ТАССРның 100 еллыгы» исемен, Фучик һәм Завойский урамнары чатындагы метро станциясе өчен «Академия» исемен сайлаган.

Фучик урамы, Нокса авышлыгы белән Ломжа урамы чатындагы метро станциясе өчен тәкъдим ителгән вариантлар арасында иң күп тавышны «Зилант» исеме җыйды, ә «Мега» сәүдә үзәге янындагы метро станциясе өчен «Тулпар» исемен хупладылар.

Сораштыруның беренче этабы былтыр булды – ул вакытта теләүчеләр үз вариантларын тәкъдим итә алды. Аннан соң түгәрәк өстәл үткәрелде, анда аларны экспертлар – туган якны өйрәнүчеләр, архитекторлар, культурологлар һәм башка белгечләр тикшерде. Атамаларның иң популяр вариантлары сораштыруның икенче этабына узды.

Тамашачы тамашасы

Г.Камал театрында беренче тапкыр гадәти булмаган спектакль куелды – анда тамашачы сәхнәдә утырып карася, артистлар тамаша залында рольләрен башкара. Төгәлрәк әйткәндә, роль башкаручылар – артист түгел, үзләре дә тамашачы.

Кастинг аша сайлап алынган тамашачылар унике – унбер хатын-кыз һәм бер ир-ат. Режиссерлар Ксения Шачнева белән Гөлнара Фазлыйәхмәтова ике ай дәвамында алар белән шушы спектакльне иҗат итә. Проектның максаты – татар тамашачысының нинди спектакльләр яратканын белү аша Камал театрының яңа төзеләчәк бинасын, аның мохитен барлыкка китерергә ярдәм итү. Татар театры нәрсә ул, аның киләчәге нинди булырга тиеш, театр татар тормышында нинди урын тота, дигән сорауларга җавап табарга ярдәм итә бу тамаша.

Героиняларның театрга килү тарихлары төрле. Эльвира Рафыйкова, мәсәлән, гүзәл мәхәббәт тарихы күрергә теләп, «Үлеп яратты» спектакленә бара. Әмма Мөхлисә Бубый турындагы бу тамашаның асыл мәгънәсен күп еллар үткәч кенә аңлый. Аңа кадәр ул Камал сәхнәсендә шигърият бәйгесендә катнашырга, һәвәскәр театр белән чыгыш ясарга, бөтен репертуарны карап чыгарга өлгерә. Спектакльдә ул Камал театрының түбәсе төсендәге зәңгәр күлмәктән иде. Татар театры кызның җанына якын була башлаган, аерылгысыз дустына әверелгән, дигән мәгънә салынган күлмәк төсенә. Зәңгәр төс – күкләр төсе дә. Татар театры кызга хыял канатлары куйган, дип тә аңларга була. Иң мөһиме, театр Эльвираны үзгәрткән, тирән фикерләү сәләте биргән.

Зилә Хөсәенова исә актер Эмиль Талипов сурәте төшерелгән футболка кигән. Кызның театрга ни өчен йөрүе шуннан яхшы аңлашыла. Әмма Зилә дә сукырларча гашыйк булучы тилемсә түгел, фикерле кыз. Мәхәббәт темасына тулы бер монолог бәян итте. Татарча үбешүнең асылына төшенәсе килде.

Кем нинди максат белән театрга килсә дә, театр һәрберсен колач җәеп каршы алачак, чөнки тамашачысыз театр булмас иде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

«Мәдәни җомга» газетасына февраль-март айларында 2022 елның II ярты еллыгы өчен ташламалы бәядән язылып куя аласыз.

Татарстанда газетага язылу индексы – П2355. Язгы ыгы-зыгылы вакытка калдырмыйча, бүген үк язылып кую уңайлы да, отышлы да. Безнең белән бергә булыгыз!

1 нче биттә – Кышкы ял. Шагыйрь Газинур Морат уха пешерә. Рөстәм Нуриев фотосы.

Шагыйрь дә, галим дә

Кәрим Тинчурин театрында Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрь, галим Рифат Җамалның 70 яшьлек юбилеена багышлап, «Күңелем сурәләре» дип исемләнгән бик җылы әдәби-музыкаль кичә узды.

Арча районының бәрәкәтле туфрагында дөньяга килгән Рифат Җамал кечкенәдән шигъри җанлы малай булып үссә дә, хезмәт юлын ветеринария тармагы белән бәйлисе итә. Ул бу өлкәдә лаборанттан алып Казан ветеринария институты ректоры кебек мәртәбәле вазифага күтәрелә, ветеринария фәннәре докторы, профессор дәрәҗәсенә ирешә. Аның бу өлкәдәге уңышларын Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты дигән дәрәҗәле исемнәр белән бәялиләр.

Әмма шагыйрьлек үзенекен итә. Гомере буе күңелендә шигъри юллар туып, аларны кәгазьгә төшереп яшәгән Рифат Җамал тора-бара әдәби иҗат белән дә ныклап шөгыльләнә башлый, аның бер-бер артлы шигырь китаплары дөнья күрә. Шагыйрьнең иҗаты исә Шәйхи Маннур һәм Һади Такташ исемендәге әдәби бүләкләргә лаек була. Аның шигырьләре башка шагыйрьләрнекеннән үзенчәлекле фәлсәфи карашы белән аерылып тора.

Әдәби-музыкаль кичә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары,Татарстан президенты хозурындагы татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтовтан юбилярга чәчәкләр тапшыру белән ачылып китте. Бу көнне Рифат Җамалга дәрәҗәле бүләкләр шактый булды. Әйтик, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулла шагыйрьнең күкрәгенә Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиллекнең Тукай медален кадады. Мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин исә бәйрәмдарны Татарстан Президенты Указы нигезендә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән дәрәҗәле исемгә лаек булуын әйтеп зурлады, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илгиз Халиков тапшырган Бөтендөнья татар конгрессы медале дә Рифат Җамалның күкрәген бизәде. Бәйрәмдарны шулай ук Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ленар Гарипов, Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе Алмаз Хисаметдинов, Арча районы башлыгы Илшат Нуриев котладылар.

Кичәдә халкыбызның яраткан җырчылары Алмаз Хәмзин, Мирсәет Сөнгатуллин, Рамил Миндияр, автор-башкаручы Рәсимә Нигъмәтуллина, Фәрит Мирзануров, Арча районы сандугачлары Расих Галимҗанов, Диләрә Хәйдәрҗанова җырлары, "Мирас" бию төркеме чыгышы, Рафинат Сәләховның баянда уйнаган көйләре ямьләндерде. Россиянең атказанган артисты, Буа дәүләт театрының директоры һәм сәнгать җитәкчесе Раил Садриев, Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗанов, шагыйрьләр Рифат Сәләх, Фәнил Гыйләҗев, Тинчурин театры артистлары Гөлназ Нәүмәтова, Илфак Хафизов шагыйрьнең шигырьләрен укыды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Юбилей күргәзмәсе

Түбән Кама шәһәр музеенда Фирдәвис Хановның архитектура эшләре күргәзмәсе ачылды. «Язмышыма рәхмәтлемен» дип аталган экспозиция каланың мактаулы шәхесе Фирдәвис Хановның 70 яшьлегенә һәм шәһәрнең 55 еллыгына багышлана. Россия һәм Татарстанның атказанган архитекторы, бу һөнәргә 44 ел гомерен биргән Ф.Ханов Түбән Кама өчен алтмыштан артык объект булдырган, аларга проектлар әзерләгән, сыннар ясаган. Сәнгатькяр эшләре исемлегендә – Җәмигъ мәчет, шагыйрь әсәрләреннән персонажлар сыннары куелган Габдулла Тукай паркы, «Кояшлы Алан», нефтехимиклар һәм шинчылар скверлары, Н.Лемаев, Е.Королев, М.Җәлил һәйкәлләре, Олы Аты һәм Симәнәй авылларында Бөек Ватан сугышы ветераннарына куелган һәйкәлләр, Ә. Фәсхетдинов музее, Кызыл Чишмә бистәсендәге яр буе һ.б.

Ф.Ханов берничә тапкыр Россиянең иң яхшы архитекторы буларак танылган, Россия баш архитекторлар советы аны «Алтын кентавр» билгесе белән бүләкләгән. Бүләкләр арасында үз вакытында популяр булган «1979 елгы социалистик ярыш җиңүчесе» күкрәк билгесе дә күргәзмәдә игътибарны җәлеп итә.

Күргәзмәдәге зур-зур рәсемнәр арасында җирле газеталарның исемнәре күрсәтелгән кечкенә стенд та урын алган. Ф.Ханов әлеге басмаларның логотипларын эшләгән булган.

Күргәзмә 27 февральгә кадәр эшләячәк.

Алгарыш нигезе – ӘДӘБИ ТЕЛ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Меңъеллык татар әдәби теленең саклануы өчен милли мәгарифнең уңышлы алга баруы мөһим. Хәзер, руслардан башка күп халыкларның телләренеке кебек, татар теленең дә кулланылышы, төрле киртәләргә очрап, кими барганда, хакимиятнең иң әһәмиятле бурычларыннан берсе – кичектермичә, татар мәктәпләренең элекке ролен торгызып, алар эшенең сыйфатын яңа дәрәҗәгә күтәрү. Татар телендәге уку йортларының, барыннан да бигрәк гомуми белем мәктәпләренең, гимназия, лицейларның уңышлы эшләвенә ирешеп кенә татар телен, милли мәдәниятне, матур гореф-гадәтләрне, традицияләрне һәм ахыргы исәптә милләт буларак халыкның үзен дә саклап калырга мөмкин.

ЮНЕСКОның Генераль секретаре мөрәҗәгатендәге "...практик файдасын күрерлек барлык башка оешмаларга бөтен телләргә, бигрәк тә юкка чыгу куркынычы янаган телләргә, индивидуаль һәм коллектив тормышның бөтен очракларында да хөрмәт белән карау, ярдәм итү һәм аларны саклау мөмкинлеге, һәм әдәбиятның көчле гамәлләрен активлаштырырга" дигән сүзләрне безгә, бөтен татарларга һәм татарстанлыларга да туган телебезнең авыр хәлдә булуы уңаеннан чаң сугарга кирәк. Кайбер идеологларның, янәсе, үзеңне татар итеп санау өчен татар телен белү шарт түгел, үзеңне шул халыкныкы итеп тою һәм ислам дине тарафдары булу да җитә, татар теле мәңге яшәячәк дип тәкрарлауларын тыңлап, үзеңне тынычландырырга ярамый.

Милләтләр турындагы теориядән хәбәрдар булу зарур. Анда милләтнең төп атрибуты (билгесе) тел диелә. Шулай ук күренекле фикер ияләренең халык туган теле булганда гына яши, теле югалса, ул үзе дә юкка чыга дигән сүзләренә колак салырга кирәк.

Хакыйкать шул: безнең телебезгә тиз арада гына югалу куркынычы янамаса да, аның сыйфаты, әдәби нормалары җитди бозылып, ул ниндидер бер суррогат (зәгыйфь) телгә әверелергә мөмкин. Бу безнең милләттәшләребезнең шактый күбесенең фәкыйрь, корама телдә сөйләүләрендә, сөйләшүләрендә күренә.

Республика җитәкчеләре, икенчел дәрәҗәдәге, әһәмияте аз чаралар үткәрү белән мавыкмыйча, халкыбызны туган телләреннән яхшы белемнәр белән коралландырсын, аларның үз телләрендә аралашуларын гадәткә кертү чараларын күрсен, милли мәктәпләрнең эшләрен тамырдан яхшыртып, балаларга һәм яшьләргә татар телен укытуның нәтиҗәлелеген арттыруга ирешсен иде.

Татарстан хөкүмәте, татар теленең язмышы барыннан да бигрәк татар мәктәбе ярдәмендә хәл ителәчәген истә тотып, милли уку йортларына иң кирәкле нәрсәләр итеп карарга тиеш. Татар мәктәпләре бөтен яктан да: укыту-матди базасы буенча да, югары квалификацияле укытучылар белән тәэмин ителүе белән дә, укытуның сыйфаты буенча да иң яхшылар булсын. Гамәлдәге татар уку йортларының эшен камилләштерергә һәм яңа, абруйлыларын да булдырырга кирәк. Аларда укыту һәм тәрбия бирүнең дәрәҗәсе алдынгы рус мәктәпләренекеннән калышмаска тиеш. Республиканың һәр район үзәгендә кимендә берәр, ә зур шәһәрләрдә берничә иң яхшы мәктәп ачарга кирәк.

Рус мәктәпләрендә укучыларга, аеруча татар балаларына, татарча укытуны тамырдан яхшырту да – Татарстан Мәгариф министрлыгының иң мөһим бурычы.

Татар уку йортларының эшен яхшырту һәм балаларга татар телен укытуның сыйфатын күтәрү белән шөгыльләнгәндә, республиканың җаваплы хезмәткәрләренә үзәктәге җитәкчеләрнең канәгатьсезлегеннән куркып калырга түгел, үз дәрәҗәләрен саклап, законнар барлык кешеләр тарафыннан да үтәлергә тиеш дип, кыю итеп әйтә белергә кирәк.

Россия Федерациясенең, республикаларның конституцияләре һәм башка законнары буенча барлык гражданнар да туган телләрен өйрәнергә һәм иркен кулланырга, балаларын да үз телләренә өйрәтергә, республика органнары исә милли мәгарифне үзләре теләгәнчә оештырырга хаклы.

● «Макдоналдс» дөньядагы иң табышлы предприятиеләр исемлегендә 20 нче урында тора, аның әйләнеше 20,8 миллиард доллар, еллык кереме 5,8 миллиард доллар тәшкил итә. Фаст-фуд челтәре көненә барлыгы 6 миллион гамбургер ясый, бу секундына 75 данә, дигән сүз. «Хэппи Мил» җыелмасында ел саен 1,5 миллиард уенчык сатыла.

● Җиһандагы һәр сигезенче кеше бу челтәрдә эшләгән, анда ел саен 1 миллион кешене эшкә алалар. «Макдоналдс» челтәрендә көн саен 68 миллион кешегә хезмәт күрсәтелә. АКШта үстерелгән бөтен бәрәңгенең 7 проценты фри кыздыруга китә.

● Бер биг-мак алыр өчен, Һиндстанда гади эшче 6 сәгать эшләргә тиеш. Берәр биг-мак, фри һәм кока-коладан кергән калорияләрне яндыру өчен, 7 сәгать буе туктаусыз йөрергә кирәк. «Макдоналдс»тагы гади персоналның 7 айлык хезмәт хакын ресторанның директорлары 1 сәгатьтә эшли!

КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ тарихы

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «История крымских татар» («Кырым татарлары тарихы») 5 нче фәнни басмасының өченче томы тәкъдим ителде. Бу - Кырым татарларының тарихына багышланган беренче академик басма. Галимнәр «Кырым татарлары тарихы»ның биш томлыгын әзерләүне өченче томнан башлаган.

Кырым татарларының үткәннәре бик катлаулы һәм аларның тарихы галимнәребез тарафыннан иң аз өйрәнелгән һәм чыганакларга сай, моннан тыш төрле начар мифлар, низаглар белән чуарланган тармакларның берсе. Моннан тыш, 1783 елда, Кырым Россия патшабикәсе Екатерина II гаскәре тарафыннан басып алынгач, күп хезмәтләр юк ителгән. Ханнар сараендагы борынгы кулъязмалар, китаплар да таланган, хәтсез өлешен Россия китапханәләренә, музейларына алып киткәннәр. Империя елларында да, Совет хакимлеге елларында да кардәшләребезгә тарихларын өйрәнүгә әлләни мөмкинлекләр булмады, аларга үгисетелгән бала хәлендә яшәргә туры килде. Ә инде 1944 елда совет гаскәрләре Кырымны фашистлардан азат иткәннән соң, Кырым татарлары һәм анда яшәгән караимнәр, хәтта греклар һәм әрмәннәр дә, фашистларга сатылуда гаепләнеп, тарихи ватаннарыннан, гомер иткән йорт-җирләреннән Себер, Урта Азия якларына, Урта Идел буе төбәкләренә сөрелә, аларның яртысы диярлеге күчеш вакытындагы кырыс шартларда – салкыннан, ачлыктан вафат була, бу мәрхүмнәрнең каберләре дә билгесез. Кырымтатарлардан калган йортларга Россия төбәкләрендә яшәүчеләрне китереп урнаштыралар. Шулай итеп демография дә үзгәрә. Кырым исә автономия булу статусын югалта, кырымтатар телендә чыккан китапларга да табу салына.

Реабилитацияләнгәннән соң да, кырымлыларга тиз генә рәхим-шәфкать булмады, бары 1985 елдан соң гына аларга тарихи ватаннарына кайтырга рөхсәт ителде. Хәзер алар, берничә шрифт (гарәп имлясын, латин, Кирилл хәрефләрен) алыштырганнан соң, латин хәрефләре белән укый, яза. Билгеле ки, хәреф алыштырулар да халык файдасына була алмый.

Кырым татарлары тарихын ныклап өйрәнү Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында 2014 елда Кырым гыйльми үзәге булдырылганнан соң, киң колач алып, фәнни хезмәтләр нәшер ителә башлаган. Институт директоры, тарих фәннәре докторы Радик Салихов Кырым фәнни үзәге галимнәренең, академик басмадан тыш, Кырым татарлары тарихы турында дистәләгән фәнни-популяр җыентык әзерләвен әйтте. Томны

тәкъдим итү чарасында белдерелгәнчә, Кырым гыйльми үзәге – хәзерге вакытта тотрыклы фәнни коллектив. Анда тугыз галим Татарстан хисабына эшли. Үзәк галимнәре нигездә Кырым татарлары хакындагы чын дөреслекне халыкка таныту буенча зур эш алып бара. Кырым һәм кырымтатар тарихы турында әзерләп чыгарылган хезмәтләр арасында Исмәгыйль Гаспралы, Усеин Боданинский томлыклары бар. Шулай ук галимнәр «Кырымтатар тарихы, архитектура һәйкәлләре» сериясендә хезмәтләр чыгаруны дәвам итә. Алар Бакчасарай һәм Бакчасарай районына, Акмәчеткә һәм Иске Кырым шәһәренә багышланган. Шул ук вакытта гыйльми үзәк тарихчылары тырышлыгы белән Карасубазар шәһәре турындагы хезмәт, кырымтатар театры, XIX-XX гасыр вакытлы матбугаты, лексикографиясе, Осман Акчокраклы китаплары да укучылар кулына ирешкән. Гыйльми үзәк шулай ук «Крымское историческое обозрение» («Кырым тарихи күзәтүе») исемле фәнни журнал да нәшер итә.

«Кырым татарлары тарихы» басмасының өченче томында XV–XVIII гасырлардагы чор бәян ителә. 1020 биттән торган томда Кырым ханлыгының тышкы сәясәте, аның хәрби төзелеше, идарә системасы, хокукый аспектлар, сәнгать, һөнәрчелек һәм авыл хуҗалыгы, фән, мәгариф һ.б. турында мәкаләләр белән танышырга мөмкин. Хезмәттә, гомумән, фәнни даирәләр, аеруча Кырым татарлары, тарихны яратучылар өчен кызыклы һәм мәгълүматларга бай материал туплап тәкъдим ителә, алар иллюстрацияләр белән баетыла.

Галимнәр томны 2018 елда әзерли башлаган, эш барышында язма, археологик, картографик, иллюстрация чыганаклары файдаланылып, аларны комплексны анализлау нигезендә авторлар Кырым татарлары тарихының бу гасырлардагы төп этапларын реконструкцияләргә тырышкан. Томлыкны төзүдә 48 авторның катнашуы искәртелде. Алар арасында Россия, Белоруссия, АКШ, Румыния, Төркия, Украинадан зур фәнни оешмаларның Кырым ханлыгы тарихының төрле этаплары, нечкәлекләрен белүче галимнәр бар. Тарих институтының Кырым гыйльми үзәге җитәкчесе, басманың җаваплы сәркәтибе, тарих фәннәре кандидаты Эльдар Сейдаметов академик басманы әзерләү, тәҗрибәләре булмаганлыктан, шактый кыен икәнлеге турында сөйләде. Алар эшне 2017 елда семинар уздырудан, күптомлыкның концепциясен, план-проспектын тикшерүдән башлауларын искәртте. 1 том – III-XIII, икенчесе – XIII-XV гасырларны, дүртенчесе – XVIII гасыр ахырыннан XX гасыр башына кадәр, бишенчесе XX-XXI аралыгындагы чорны колачлар дип уйланылган. Хәзер академик басманың бишенче томын әзерләү эше башланган.

«Кырым татарлары тарихы»н III томнан башлауның үз сәбәпләре бар. Академик басманың җаваплы редакторы, тарих фәннәре докторы, Мәскәүнең Шәрык дәүләт музее директорының урынбасары Илья Зайцев биштомлыкны өченчесеннән башлауларының төп сәбәбен XV–XVIII гасырларның, ягъни Кырым ханлыгы чорының кырымтатарлар өчен аерым әһәмияткә ия дәверләр булуы белән аңлатты. Ул заманда Кырым ханлыгы көнчыгыш Европа тарихында да зур роль уйнаган көчле дәүләт булган. Бу – Кырым татарлары этногенезы формалашкан, милли мәдәният, әдәбият һәм сәнгатьнең, архитектура, мәгариф системасы нигезе салынган һәм үсеш алган, ягъни аларны халык буларак таныткан, халыкның үз туган телендә иркен аралашкан чор. «XV–XVIII гасырлар Кырым татарлары хәтерендә алтын дәвер буларак сакланып калган, – диде И.Зайцев. – Әмма Алтын Урда кыйпылчыклары арасында иң озын гомерлесе булган Кырым ханлыгы хаксыз рәвештә тарихчы галимнәрнең игътибарыннан төшеп калган. Кырым ханлыгын бөтен гонаһларда гаепләгәннәр. Объектив һәм тулы тарих ярымутрауда яшәүче бер генә халык телендә дә бәян ителмәгән. Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты дөреслекне таныту буенча зур эш алып бара».

Өченче том төрле ил галимнәренең Кырым ханлыгы тарихына заманча карашын да чагылдыра. И.Зайцев моннан тыш, беренче китапны әзерләгәндә шактый тәҗрибә туплануын да әйтте, шуңа да башкаларын әзерләү җиңелрәк барыр, дигән фикер дә белдерде.

Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков искәртеп үткәнчә, нәрсә генә булса да, Кырым ханлыгы тарихы – татар халкы үткәннәренең аерылгысыз бер өлеше, без – бер дөнья, бер халык. Мондый томлыкларның 30 елга бер генә чыгарылуын исәпкә алсак, хезмәт әле озак еллар дәвамында Кырым татарларына һәм галимнәребезгә хезмәт итәчәк.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Тынгысыз Мидхәт ага

Быел Башкортстанда “Ак калфак” татар хатын-кызлары оешмасы үткәргән “Җырлыйк әле” фестивален тамаша кылырга насыйп булды. Анда шагыйрь һәм композитор Мидхәт Әбделмәнов җитәкчелегендәге “Милли аваз” татар фольклор ансамбле дә катнашты һәм “Кичке уен” күренешен тәкъдим итте. Тел-теш тидергесез чыгыш булды ул. Сиксән яшен тутырып килүче Мидхәт Мәҗит улы Әбделмәнов белән шунда таныштык без.

Мидхәт аганың шәҗәрәсе әнисе Газимә ягыннан затлы нәселгә барып тоташа. Аның картәтисе Усманов эре сәүдәгәр булган. Алыш-биреш эшләрен киң җәелдереп, Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа шәһәрләре арасында тауар әйләнешен булдырган. Әнисе ягыннан нәсел агачында уңышлы эшләүче, дәрәҗәле вазифа башкаручылар бүген дә шактый. Әйтик, хәзерге вакытта Россия Үзәк банкы рәисе Эльвира Нәбиуллина да шушы шәҗәрәдә.

Әмма Бөек Ватан сугышы барган елда Башкортстанның Благовар районы Яңыш авылында дөньяга килгән малайны тормыш иркәләмәгән. Сталинград фронтында һәлак булган әтисен ул бөтенләй хәтерләми. Әнисе Газимә апага, апалары Хәдичә белән Мәхмүдәгә булышырга кирәк. Мидхәт җиде-сигез яшеннән җаваплылыкны үз иңнәренә алырга өйрәнә, җан асрау өчен тормышны җигелеп тартырга, зурларның гына көченнән килә торган барлык авырлыкларны кичерергә туры килә. Кыш көне чана өстерәп урманга утынга барырга да, көтү көтәргә дә, тамак туйдыру хакына иң авыр хезмәтләрне башкарырга да өлгерә. Икмәкне туйганчы ашый башлаганда, ул үсмерлек яшенә җитә. Әмма күргән михнәтләрдән малайның күңеле катыланмый. Ул шигъри күңелле егет булып үсеп җитлегә. Балачактан җыр-моңга һәвәс булса да, күңеленә шигырь юллары килеп, аларны кәгазьгә төшерсә дә, аңа бу елларда белем алу мөмкинлеге табылмый. Балта остасы, тракторчы, слесарь, монтажчы… Аннары, әзрәк аякка баскач, нәселдән килгән белемгә омтылышына да юл ачыла, авылдан китеп, төзелеш буенча белем алып, Урал таулары аръягында, Чиләбедә, Троицкида, Башкортстанның төрле районнарында төзелешләрдә мастер, прораб, монтажчылар башлыгы, участок җитәкчесе булып эшли. Чиләбедә яшәгәндә егет гаилә корырга да өлгерә.

Мидхәт Әбделмәнов, беренче шигыре 25 яшендә үк газетада дөнья күрсә дә, бу елларда әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнә алмый әле. Әмма читтән торып Башкорт дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый. Чын иҗат лаеклы ялга чыккач башлана. “Бу елларда зәвыклы җырлар туды”, – ди ул үзе дә. Озакламый татар дөньясы Мидхәт Әбделмәновны берьюлы шагыйрь дә, композитор да, язган җырларын үзе үк башкаручы да итеп танып өлгерә. Аның шигырьләренә язылган “Ашкына гомер”, “Дуслар” (Радик Юльякшин көйләре), “Исеңдәме?” (Рөстәм Асаев көе), “Хәлең ничек диеп сорама” (Идел Нургалин көе), “Көт сөйгәнем”, “Чулпаным булсаң гына” (Илшат Фатыйхов көе), «Яшьлек вальсы, «Яшь гомер» кебек җырлар Элвин Грей, Бәширә Насыйрова белән Рөстәм Асаев, Ришат Төхвәтуллин, Гөлназ Асаева, Филүс Каһиров, Венера Уразаева-Юльгильдина, Мирабель Сакаева, Илшат Вәлиев һ.б. җырчылар башкаруында аеруча популяр булып китә. Мидхәт ага күп кенә шигырьләренә көйләрне дә үзе иҗат итә. “Яратам мин” (Алмаз Хәсәнов җырлый), “Әнкәем” (Әлфия Әмиханова репертуарында), “Зәңгәр көймә”, “Яшисе килә” (Бәширә Насыйрова башкара) – шундыйлардан.

Мидхәт аганың җырчылар Марат Шәйбәков, Фәнидә Сәфәргалиева, Әнвәр Нургалиев белән дә уртак иҗат җимешләре бар. Аларны тыңлаганда күңелдә иң нечкә хисләр уяна, сагъдәтле хатирәләр яңара. “Җырларымның кешеләрне халкыбыз моңнары кебек дулкынландыруын, халыкчан һәм мәгънәле булуын телим. Кайберләрен кабат-кабат эшлим”, – ди Мидхәт ага.

Ак бәс кунган чәчең
Коеладыр, әнкәй,
Коеладыр, бик еш тарама.
Балам кайтыр диеп,
Матур кулмәк киеп,
Буш юлларга зарыгып карама.

Мидхәт аганың гомерендә бер тапкыр да күрә алмаган әтисен юксынып язган шигырьләре дә бар. М.Әбделмәнов олы вакыйгалар, тантаналар уңаеннан да шигырь-җырлары белән үзенең хисләрен белдерә. Әйтик, Казанда Универсиада барган көннәрдә шигырен дә, көен дә Мидхәт ага иҗат иткән “Универсиадагага дан!” җыры Рөстәм Асаев башкаруында хитка әверелде, аны төрле каналлар, радиолар тәүлек әйләнәсе яңгыратып торды. “Ак калфак” татар хатын-кызлары оешмасына багышлап Люция Вафина шигыренә язган – “Ак калфак”, “Ялкын” журналының юбилее уңаеннан иҗат ителгән – “Ялкын” Татарстан башкаласының 1000 еллыгын билгеләп үткәндә язылган – “Казан” (Рөстәм Асаев башкара), республикабызның 100 еллыгына багышлап иҗат иткән шигыренә язылган “Ватаным Татарстан” җырларында татар халкының гореф-гадәтләре, матур эшләре зурлана. Шунысы сөенечле: Мидхәт аганың җырлары аудио һәм видео дисклар булып дөнья күрә, аны татар-башкорт әдәби һәм сәнгать даирәсендә таныта. Авторның биш аудио, ике видео дискы җыр сөючеләр кулына килеп ирешкән. Аларның һәркайсы дистәдән артык җырдан тора. Гомумән алганда, М.Әбделмәнов 100 дән артык җыр иҗат иткән.

Мидхәт ага шул ук вакытта образларга бай шигырьләр авторы да. Аның “Бүләк”, “Чагыл”, “Соң булса да, уң булсын”, “Җырга ераклы?”, “Ашкынма гомер” дигән шигырь һәм мәкаләләр җыентыклары дөнья күргән.

Тынгы белмәүче иҗатчы, өлкән яшьтә булуына карамастан, активлыгы белән хәйран калдыра. Ул Башкортстан Язучылар берлеге уздырган барлык чараларда катнаша, Казанда үткән “Милләт җыены”на да вәкил булып килә, шул ук вакытта аның “Рамазан” мәгърифәт үзәге аксакаллар берлеге рәисе булуы да мәгълүм. Ул 2018 елда “Милли аваз” татар фольклор ансамблен оештырган.

2021 ел җәендә Туймазы районының “Бабай утары” этнографик музее биләмәсендә үткән “Җырлыйк әле” татар фольклор фестиваль-бәйгесендә Мидхәт ага җитәкчелегендәге “Милли аваз” татар фольклор ансамбле аеруча хәтердә калды. Коллектив “Кичке уен” күренешен тәкъдим итте. Кичке уеннарда, гадәттә, кунак кызы катнашуын өлкәннәр хәтерли әле. Читтән килгән бу гүзәлләргә игътибар да зур булган, гадәттә, аңа авылның иң чая егете күз төшергән. Сәхнәдәге тамашада да шул хәл яңарды. “Ашхабад” халык җыры белән башланган кичке уенда өч төрле халык уены күрсәтелде. Ансамбльнең җитәкчесе М.Әбделмәновның күптән түгел генә иҗат иткән “Ватаным Татарстан” җыры да фестиваль вакытында беренче тапкыр тамашачыга тәкъдим ителде. Ул тамашачы һәм жюри күңеленә аеруча хуш килде. Татар халкының гасырлардан килгән данлы тарихын һәм язмышын чагылдырган шигырь һәм көе дә ватанпәрвәрлек хисләренә бай бу җыр өч тавышка башкарылды. Ансамбль куйган фольклор күренеш фестивальне оештыручылар тарафыннан беренче урын белән бәяләнде. “Җырны хор белән бер яки берничә тавышка башкаруны көйләү катлаулы, осталык, сәләт таләп итә. Безгә бу мәсьәләдә Благовар килене Эльмира Мәэминова ярдәмгә килә. Аңа рәхмәтебез чиксез”, – диде ул. Аңлашыла ки, Мидхәт ага юл йөрү, коллективка кирәк-яраклар алу өчен чыгымнарны үз кесәсеннән чыгарырга туры килә.

Әлбәттә, боларның барысына да гаиләдә тынычлык, сиңа ярдәм итәргә әзер торган җәмәгатең булганда гына өлгерергә мөмкин. Кешелекле, сабыр һәм тыйнак, шул ук вакытта төрттереп алырга да яратучан Мидхәт агага Раббыбыз уңган Хәлиләсен насыйп иткән. Ул исә иренә илһам чыганагы гына түгел, чын кайгыртучысы да, бергәләп уртак шатлыклары – уллары Рөстәмне үстергәннәр. Бүгенге көндә Хәлилә апа – биш вакыт намазын калдырмаучы, Коръән сүрәләрен укучы сөйкемле абыстай. Гомумән, бу йортта динебез кушканча яшәүне гадәт иткәннәр.

Мидхәт ага туган авылы Яңыш турында да бик яратып сөйләде. Ул Октябрь революциясенә кадәр 3 мәхәлләле зур авыл булган. Ә инде 15 еллар элек Яңышта улы Рөстәм һәм дуслары белән мәһабәт мәчет тә төзетеп куюы якташларына да игелекле эшләр кылуда өлге булгандыр. Аңа М.Әбделмәновның сөекле әнисе хөрмәтенә “Газимә” дип исем кушалар. Тынгысыз йөрәкле Мидхәт ага үзенә эшне таба тора. Аллаһ йортының ишек алдын тәртипкә китерү, аны ямьләндерүдә ул башлап йөргән. “Якташлар” проекты кысаларында туган районында хәйрия концертлары куюны да М.Әбделмәнов тәкъдим иткән һәм Языково авылы клубында, район мәдәният сараенда оештырылган хәйрия концертлары оештырып үрнәк күрсәткән. Бу изге гамәлгә районнан чыккан сәнгать осталары да ихлас кушыла. Бәйрәмдә күп кенә җырчылар, музыкант һәм биючеләр катнаша. Алай гына да түгел, тумышы белән шушы районнан булган танылган җырчыбыз Рөстәм Асаев та бу көннәрдә туган ягында сәхнә тота. Концерттан кергән акчалар район үзәгендәге мәчетне төзеп бетерү өчен тотыла һәм мохтаҗларга таратыла. Соңгы елларда Мидхәт ага үзенә тагын бер мәшәкать тапкан, туган авылы Яңышта буа булдыру эшләре белән йөргән.

Мидхәт Әбделмәновны бүген туган телебезнең язмышы борчый. Аны кайбер аналарның балалары белән башка телдә аралашуы кебек күңелсез хәлләр, милли мәктәпләрнең азаюы көендерә. Шигырьләре аша, мәкаләләр, хатлар язып, кулыннан килгәнчә, хәлне үзгәртергә тырыша.

Сөембикә КАШАПОВА.



Кадыйр СИБГАТУЛЛИН

Кешеләрнең сөеп-яратканы Аерыла икән кавышканчы...

(Күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның тууына 80 ел)

МӘХӘББӘТ

Үзең коткар бәла һәм афәттән,
Ярдәмчем бул, ниләр күрсәм дә;
Тик коткара күрмә мәхәббәттән,
Учагында көлгә дунсәм дә.
Н.Арсланов

Без яратмый, җирдә кем яратсын,
чиге бармы матур хисләрнең?
Шашып сөя алсам, яшәп булыр,
мәхәббәтем сүнсә, нишләрмен?!

Йөрәгемә салкын су сипсәләр,
бер көнгә дә, бәлки, чыдамам.
Ярым өчен иң зур океан кичеп,
тере чәчәк алып чыгалам.

Күңел тулса тулсын,
мөлдерәп торсын.
Тамчысына кадәр кадерле.
Без – табигать таҗы,
бөре чыга,
чәчәк чыга
тишеп бәгырьне!
Җаным янып сөйсә, күтәрермен –
бер бәхетем торсын мең газап.
Хисләремне мин коллыкка бирәм,
мәхәббәтем бөек һәм азат.

Әкиятләрдә ул без,
без – поэма.
Мин ул очам шашкын атымда.

...Поэмалар әле язарбыз без
бөек яратулар хакында.

Таһирлар да, Зөһрәләр дә исән,
Мәҗнүннәр дә йөри табынып.
Мәхәббәткә җирем батар иде,
бу йөрәгем китсә ярылып!

АРАУКАРИЯ*

Сокланыпмы, әллә мактаныпмы –
кайтарганнар ерак җирләрдән.
Ләкин алар Кырым туфрагында
әсир булып тамыр җибәргән.

Ылыслары корып-корып төшкән,
үзәкләре кипкән авырып.
Күпме генә кадер итсәләр дә,
китә алмаганнар савыгып.

Араукарияләр арасыннан
берсе генә җанын саклаган.
Йөз ел яшәп хәтта анысы да
бер тапкыр да чәчәк атмаган.

Ышанасы килми:
йөз ел яшәп...
бер бәләкәй куак кадәр ул.
...Безгә түгел,
димәк, агачка да
туган җирсез яшәү хәтәр ул.

*Араукария – чәчәк ата торган зур агач.

* * *

Башак шавы – тәүге бишек җырым,
камыл – түшәк,
болыт – юрганым.
Туган көннән алып бу кырларга
мин битараф һәм чит булмадым.

Әни өйгә кайтып җитә алмый
кырда тапкан мине, камылда.
Ана сөте белән туган туфрак
туган көннән алып канымда.

...Ул тапкан да мине, аңын җуйган:
газаплары бераз бүленгән.
Иген үсә торган туфрак кына
саклап калган, ахры, үлемнән.

Һушын җыеп, бер имезгән мине
буразнадан алып кулына.
Кодрәтләре чиксез булсын дипме,
Кадыйр** исемен кушкан улына.

Үләргә дә риза, дигән әни,
күрә алсам тик бер көлгәнен.
...Көлеп яткан урыннарым исән,
мендәр итеп арыш көлтәсен.

Ул борчыла һаман,
нинди уйлар
бимазалый күңелен ананың?
Бәхетләре тулы булмыймы соң
буразнада туган баланың!

...Ак мендәрдә түгел,
әни мине
тапкан камылларда тәгәрәп.
Шуңа күрә җир үзенә тарта,
буйларыма кадәр тәбәнәк.

**Кадыйр – көчле, көче җитүче (гарәпчә).

ЯЗМЫШ

Еллар буе дәшми тилмерттең дә,
мена хатың ята өстәлемдә:
газапларны бераз киметтең дә,
газапларга газап өстәдең дә.

Кошларның да тала канатлары
берсен-берсе эзләп табышканчы.
Кешеләрнең сөеп-яратканы
аерыла икән кавышканчы.

Бара-бара озын гомер буйлап
һаман ерак, һаман ерак китә.
Яшьлегеңдә калган ярын уйлап
гомер итә һаман – гомер үтә.

Тыйнак кына кайчак күрешәләр –
чит кешеләр диеп уйлап була.

Бер елга бер ялгыш үбешәләр
бер-береннән оялып,
урлап кына.

Үзләре дә кайчак аңламыйлар,
әллә нинди чиргә сабыштыра.
Ике елга бер хат алгалыйлар,
күзләрендә тере сагыш тора.

Ялгышалар куркып ялгышлыктан
ялгышмаска вакыт бар чакларда.
Интегәләр авыр ялгызлыктан
загс язып биргән кочакларда.

АВЫЛ УРЫНЫ

Урамнары әле беленеп тора,
нигез саен – чокыр, багана.

Шау чәчәкле алмагачын күреп
килеп кердем үтеп барганда.
Арба эзен күмгән яшел чирәм,
бака тавышлары сазлыкта.
Киртәләрен баскан алабута,
авып ята черек казыклар.
Инде быел буылмаган инеш,
чишмәләре кипкән, саеккан.
Буш нигезнең каены ботагында
йорт җиткереп кергән саескан.
Сүтсәң, бәлки, тузан гына калыр,
исән килеш әле йорт әрәм.
Тәрәзен дә каплап матышмаган,
ташлап киткән икән бу адәм.

Соңгы йортның инде хуҗасы юк,
кошлар торыр,
алар талымсыз.
Бу авылда туып-үскән кеше
калмас микән туган авылсыз?
Бабалары ята шушы җирдә,
кайтыр әле,
карар,
кадерләр...
Китә алмый ияреп кеше артыннан
туган нигез белән каберләр.
Туган илдә урын иркен безнең,
кая барсаң – шунда хуҗа син.
Бәхетеңә таба китә кеше,
ияреп бармый арттан нужасы.

Бик кирәккә күрә китәләрдер,
ялгыз язмышлардан котылып.
Киткәннәрнең үткәннәре генә
югалмасын иде онытылып.
Ни әйтсәң дә, бераз ямансурак
нигезеңдә хуҗа калмагач.
Ак чәчәген коя-коя елый
авыл урынында алмагач...

КӨЗГЕ ЯЗ

Мин ышандым кабат тууларга,
яшәү кирәк, яңарулар кирәк.
Охшамыйлар кайчак еллар елга –
безнең гомер яңаруда, димәк.

Елларның да була төрле чагы,
охшамасын, әйдә охшамасын.

Гел көлеп тә,
гел елап та тормый,
табигать ул белә үз чамасын.

Миңа кара, кеше, дигән кебек,
төзәт, дигән кебек, ялгышыңны,
көне,
ае,
елы белән синең
ул искәртеп куя язмышыңны.

Бу язларым,
бу көзләрем диеп,
гомереңне ничек аерасың?
Шәйләп булмый кайчак,
шәйләп булмый
язлар белән көзләр аермасын.

Көзләр көткән идек – язлар килде,
еллар якты һаман,
көннәр якты.

Бакчаларда әнә алмагачлар
икенче кат быел чәчәк атты...

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫ ЮКСЫНУ

Шагыйрь үлми дигән хакыйкать бар.
Үлми шагыйрь,
үлми икән шигырь җирдә.
Тик шулай да
мәңге сагынып өчен
бер шагыйрьнең бер үлеме җитә.

Шигырең исән.
Мәңге исән булыр.
Язып киттең бугай йөрәкләргә.
Синең шигыреңне кулга алам,
тормыш ваклыклары йөдәткәндә.
Шулай булыр:
йөзләр,
меңнәр укыр.
Исемең яшәр һаман,
яшәр даның.
Халык йөрәгендә,
шигърияттә
балкып торыр һаман синең җаның.
Шагыйрә дип телгә алган чакта
шигырьләрең сөйли –
исән-саулар.
Күз аллары бераз томалана,
«Нинди иде ул?» дип сорасалар.
Юатырлык җырың – моңың калды,
кешеләргә теләп исән-саулык.
Тик барыбер сыкрый минем йөрәк,
«Саҗидәнең кабере...» дисә халык.
Шагыйрь үлми.
Дөрес, кеше үлә.
Исән дә син бүген,
түгел дә син.
Киләчәктә әле синең гомер
һәм җитмисең безгә бүгенгә син.
Үлемсез син
вакыт,
илең өчен.
Безнең белән калдың бездән китеп.
Тик барыбер үлемсезләрне дә
бик күрәсе килә исән итеп!

Ниһаять, Красноярск краеның дәүләт архивыннан үзем сораткан тарихи документларның күчермәсен ала алдым, ә аларга кимендә 140 ел! Хәер, үзем дә бу чыганакларга озак килдем, әле 2008-2009 елларда ук «Казан утлары» журналында Тәфкил Вафинның «Мәкруһлар» дип аталган язмасын укып тетрәнсәм дә, бу темага тиз генә тотына алмадым. Тәфкил аганың бу язмасын, рус теленә дә тәрҗемә итеп, 2011 елда ике телдә бастырып чыгардык. Тәфкил абый бу китапны күреп калды, аның белән Лаешта берничә тапкыр очраштым. Ул вафаты алдыннан бабасына каршы ачылган «Эш»нең күчермәсен миңа биреп калдырды.

Дин өчен сөрелгән

1867-1868 елларда, чукынмаган өчен, Казан губернасыннан Себергә - Турухан краена сөрелгән татарлар турында Тәфкил абый күтәргән тема бик җитди иде. Тәфкил абый язуынча, алар 45-47 кеше була, хатыннары артларыннан Себергә җәяү чыгып китә... Иман өчен Себер киткән бу татарлар элеккеге Зөя, Тәтеш, Цивиль өязләреннән була, бу төбәк хәзерге Апас, Кайбыч, Яшел Үзән, Тәтеш, Кама Тамагы районнарына карый.

Тәфкил ага Татарстан архивларыннан ярты гасырга якын үзенең сөргенгә сөрелгән бабасын эзли, әмма чиркәү кенәгәләрендә, рәсми чыганакта бу татарлар «чукындырылган» урыс исемнәре белән булганлыктан, озак таба алмый. Ниһаять, Татарстан Милли архивында аның кулына 1867 елгы «Дело канцелярии начальника Казанской губернии. Стол гражданский. Об отпадении от православия в магометанство крещенных татар деревни Азбаба Ивана Петрова, Антона Иванова, Николая Никитина и деревни Янгильдиной Василия Иванова и крестьянина дер. Чутеевой Цивильского уезда Махмута Мергашова» дип аталган «Эш» килеп керә (ТР МА.Ф.1, тасвирлама 3, саклау берәмлеге 228.) Василий Иванов дигәннәре Тәфкил абыйның сөргенгә сөрелгән бабасы Мөхәммәтсабит бине Шәрәфетдин булып чыга... Аны керәшен татарларын яңадан исламга кайтырга өндәүче, иманны саклап калу өчен иң каты көрәшче, дип табалар һәм гомерлеккә илдән сөрәләр.

Бу татарларга каршы җинаять эше ачыла, әмма халыкның күтәрелүеннән куркып, Казан губернаторы аларны хөкем итәргә курка, бу тоткыннарны, бишәр-бишәр кеше туплап, судсыз-нисез Себергә сөрәләр. Бу хәл 1867 елның язында башлана, җәй буе дәвам итә, Тәфкил абыйның бабасы Мөхәммәтсабит унбер кешелек этапка эләгә. Аның 17 яшьлек икенче хатыны Миңлегөл авырлы була, ул да, башка каторжан хатыннары белән, ире артыннан озын юлга кузгала. Мөхәммәтсабитның дүрт балалы өлкән хатыны авылда кала...

«Бурлаклар сөйрәгән баржа Пермь шәһәренә килеп туктагач, татар хатыннары, баржадан төшеп, бер караңгыдан икенче

караңгыга кадәр җәяүләп, Тобол шәһәренә таба атлый. Үзләре белән алган киемнәре тузып, ертылып бетә. Себер татарлары яшәгән берничә авыл аша узганда халык ярдәм күрсәтә, кием-салым, ямаулыкка үзләре тукыган киндер кисәкләре, чабата бирә... Тоболдан Көнчыгыш Себернең Турухан краена урнашкан Енисей бистәсенә таба арып-талып атлыйлар... Ниһаять, зур газаплар белән билгеләнгән урынга килеп җитәләр.» (Тафкил Вафин. Отпавшие, или насильственное крещение татар. – Казань, 2011, 158 б.)

Тәфкил абый язуынча, ирләре хатыннарына караганда бераз алданрак килеп җиткән була, алар Енисейскида очрашып, бергә яши башлый. Бер караганда, сөргендәгеләргә бу рөхсәт ителергә тиеш түгел, әмма гаиләләре белән кушылгач, тоткыннарга бергә яшәргә рөхсәт бирәләр. Мин шундый ук хәл белән Сахалин архивларында таныштым, Зур җирдән каторжаннарның хатыннары килгәч, аларны төрмәдән поселениегә

таба, аңа Хәлиулла, дип исем кушалар. Аннан соң Мөхәммәтсабит белән Миңлегөлнең сөргендә тагын ике баласы туа. Мөхәммәтсабитның туган илдә, Янгилде авылында, этисеннән өч яшендә калган улы Мөхәммәтвафа, 1884 елда аны эзләп, Себергә килеп чыга. Әтисе башта аны танымый, аннан буй җиткән улын үз янында калырга өнди, әмма егет Себердә калмый, туган якларына кайтып китә. Бу – Тәфкил абый Вафинның әтисенең әтисе, ягъни, бабасы була. Ә Мөхәммәтсабит бабай Енисейск каласында, «поселение» сөргендә 36 ел яши, 1903 елда гына бакыйлыкка күчә. Ул үзе дә, аның белән бергә сөрелгәннәр дә беркайчан да туган якларына кайта алмый, чөнки аларга торган җирләрен ташлап китү тыела. Алар гаиләләре белән, мал-туар тотып, үзләре салып чыккан өйләрдә яши, әмма алар барыбер тоткын исәпләнә.

Тәфкил абыйның язганнарыннан күренгәнчә, бары тик Салтыган авылы мулласы Таҗетдин Мөхәммәдьяров кына хатынына чыгарганнар, һәм гаилә бергә яши башлаган. Енисейскида да шулай: дин өчен сөрелгән татарлар гаиләләре белән кушылгач, төрмәдән поселениегә чыгарылган, әмма алар барыбер ныклы күзәтү астында яшәгән һәм торган җирләреннән башка урынга күчә алмаган. Илгә кайту турында инде сүз дә була алмый, чөнки алар гомерлек сөргенгә сөрелгән була…

Ире хакына авырлы килеш бөтен Себерне җәяүләп үткән Миңлегөл октябрь аенда ир бала авылдан китәргә рөхсәт бирми. Ул сөргендә яңадан өйләнгәнме-юкмы – билгесез. Аның сөргендә дә якташы Габделлатыйф Алкин белән элемтәдә торуы турында хәбәрләр бар. Бу төбәк керәшеннәрен исламга кайтырга өндәүчеләрнең башлыгы саналган Иске Чәчкаб авылы имамы Габделлатыйф Алкин да башкалардан аерым, ялгыз сөрелә. Аны, ярдәм сорап, төрек солтанына хат язуда һәм Төркиягә ике илче җибәрүдә, 1721 керәшенне яңадан исламга кайтаруда гаепләр. Казан губернаторы Зөя полиция башлыгына 1867 елның маенда шундый боерык бирә:

«Христиан диненнән мөселманлыкка кайтуда гаепле итеп, Габделлатыйф Алкинны, халык арасында хурлыкка төшереп, бөтен телен ачмаслык итеп, керәшеннәрнең каршылыгын тәмам бетереп зур җыен үткәргәннән соң, Турухан ягына олактыру өчен Казанга озатыгыз.»

Шулай эшлиләр дә. Габделлатыйф хәзрәтне, аяк-куллары богауланган хәлдә, барабаннар кагып, Зөя каласы буйлап йөртәләр. Аны атлы казаклар, солдатлар озата бара. Бу хәлләрне карап торырга тирә-як авыллардан муллаларны, керәшеннәрне, мәкруһларны китерәләр. Алар алдында полиция башлыгы, төрмә хуҗасы чыгыш ясый, әгәр татар керәшеннәре яңадан исламга кайтырга омтыла икән, аларны да Алкин язмышы көтәсен кисәтә.

Габделлатыйф Алкинны, судсыз-нисез, 1867 елның маенда Турухан краена сөрәләр. Ул бу гаделсезлек турында 1871 елда хәтта императорның үзенә хат яза, әмма аңа туган якларына кайтырга рөхсәт бирмиләр. «Керәшеннәрнең күпләп яңадан исламга кайтуында ул гына гаепле. Аны кайтару мөселманлыкка кайтуны тагын да көчәйтәчәк», диләр. Габделлатыйф хәзрәтнең алдагы язмышы билгесез. Алай да, алга китеп шуны әйтәсем килә, 2011 елның ноябрь ахырында мин Кайбыч районының Иске Чәчкаб авылында булдым һәм Габделлатыйф Алкинның нәсел дәвамчылары белән очраштым. Рива абый Алкин турыдан-туры аның монда калган нәсел дәвамчысы, бу нәсел Бикчура ханга барып тоташа. Рива абыйның улы Ленар әле 2007 елларда ук ерак бабасы Габделлатыйфның язмышын ачыклау өчен Красноярск крае архивына мөрәҗәгать иткән. Аннан килгән җавaптан күренгәнчә, 1872 елда Габделлатыйф Алкин Енисейск губернасының Ялан волостена китерелгән һәм Гәр авылына урнаштырылган. Документында аны кайда һәм нәрсә өчен хөкем ителүе күрсәтелмәгән була, чөнки ул сөргенгә судсыз сөрелә бит! 1881 елда Абдул Алкинга (шулай язылган) 66 яшь була, ул «поселение»гә хатыны белән килә. Ягъни, 1871 елда, императорга язган хатыннан соң да туган якларына кайтарылмагач, ул җирле татар хатын-кыз белән никахлашып, гаилә кора һәм «поселение»гә чыгуга ирешә. Аның турыда хәзергә башка мәгълүмат юк...

Салтыган авылы мулласы Таҗетдин хәзрәтне дә шулай мәсхәрәләп сөрәләр, имеш, ул мәкруһларны исламда калырга өндәгән, аларга мәчеттә намаз укырга рөхсәт биргән, христианнардан көлгән... 1867 елның гает намазыннан соң, июль аенда аны кулга алалар. Бу хәлне күрү өчен Салтыганга тирә-күрше татар авылларыннан керәшеннәрне, старосталарны куып китерәләр, качмасыннар өчен, аларны атлы гаскәр саклый. Кул-аяклары богауланган Таҗетдин мулланы халык каршына өстерәп чыгаралар, ул чалмадан, уң кулында Коръән, сулында мәчет таягы була. Урыс исправнигы аның кулыннан Коръәнне белән таягын тартып ала, аларны чокырга томырырга омтыла, әмма халыкның урман кебек гүләвеннән, ярсуыннан куркып, аларны Таҗетдин хәзрәтнең хатынына бирә. Мәкруһ татарларның башларыннан түбәтәйләрен йолкып җиргә бәрәләр, кайберләре куркудан түбәтәен үзе үк салып ташлый, чөнки ул мөселманлык билгесе була. Татар мулласын мыскыл итү мәрәсимендә гаскәриләр, поплар, хөкүмәт кешеләре катнаша...

«Мөхәммәдьяров Таҗетдинне кулга алуны «с большой огласки» дигән, губернатор тарафыннан куелган боерыч җиренә җиткереп уздырыла, – дип яза Тәфкил ага Вафин. – Кыйнаулар, елаулар, атларның, кеше өстенә басмас өчен, хуҗаларына буйсынмыйча кешнәүләре, камчы чыжлаган тавышлар барысы да бергә кушылып, мәшхәр көнен хәтерләтә иде. Таҗетдин мулланың кулларына, аякларына тимерне кыздырып богау салганда Салтыган авылына

татарлар





куылып китерелгән татарлар күз яшьләрен тыя алмыйча елады. Исправник командасы Мөхәммәдъяровны кулга алу белән бергә мәкруһларны кабат чукындыру эшен алып барырга тиеш була. Гаскәриләр белән чорнап алган берничә кешене (мәкруһны) чукындыра алмыйлар. Мәкруһларны (отпавшийларны) кабат чукындыра алмагач, солдатлар аларның башларыннан түбәтәйләрне тартып алып, җиргә салып таптый. Куркуга төшкән кайбер мәкруһлар үз түбәтәйләрен үзләре үк салып таптый, моны күргән чиркәү руханилары, урыс хөкүмәте чиновниклары бигрәк тә канәгать кала.» (Кульъязмадан өзек.)

Салтыган авылында бүген дин өчен аяк-куллары богауланып, гомерлеккә Себергә сөрелгән Таҗетдин мулланы хәтерлиләрме икән? Югыйсә, ислам дinduced диненең татарлар арасында мең елдан артык яшәвендә менә шундый фидакарьләрнең дә өлеше зур бит. Дин-ислам хакына аяк-кулларына богау киеп, мәңге кайтмаска Себерләргә сөрелеп, алар саклап калды динебезне һәм милләтебезне! Моны без беркайчан да онытмаска тиеш!

Шулай итеп, моннан 150 ел элек чукынмаган өчен Туруханкраена сөрелгән татарларның нибары икесенең генә Татарстанда нәсел дәвамчылары бар – Тәфкил абый Вафин һәм Алкиннар. Калган кырык бишенең нәсел дәвамчылары кайда? Гомумән, аларның язмышы ничек? Беркайда, бернәрсә юк – тарихи документлар да, әдәби әсәрләр дә, хатирәләр дә... Югыйсә, дин-ислам өчен, мөселман-татар булып калу өчен шушы кадәр авырлыклар, газаплар күргән кешеләр бит алар! Узган көз Енисейск шәһәренә барып, аларның эзләрен табарга тырышып карадым. Унбиш меңләп кеше яшәгән кечкенә генә калада биш йөзгә якын татар бар икән. Аларның күпчелеге йә узган гасыр башында, Столыпин реформалары сәбәпле, ихтыяри-мәҗбүри Себергә күчкән яки Сталин чорында сөрелгән татарларның нәсел дәвамчылары булып чыкты. Мин эзләгән татарларның нәсел дәвамчылары очрамады...

Өметем шәһәрнең татар зиратына һәм архивларда иде, әмма анда да берни тапмадым. Зираттагы гарәп язулы ташлар октябрь инкыйлабыннан соң юк ителгән, ә җирле архивта бары тик соңгы йөз елдагы документлар гына саклана. Әлбәттә, сөргенгә сөрелгән татарлар менә шушы татар зиратында ята, ләкин ташлары да, исемнәре дә юк... Әмма Енисейскига килүем барыбер бушка китмәде – зиратның намаз йортында бик күп борынгы китаплар, кулъязмалар таптым, бу хакта Казан галимнәренә дә хәбәр иттем, алар да анда барачак, бу кыйммәтле ядкәрләрне өйрәнәчәк. Шулай ук шәһәргә ямь биреп торучы Татар мәчетендә булдым, аның тарихы белән таныштым, шушы туфракларда ятучы милләттәшләрем рухына дога кылдым...

Бу Татар мәчете күп нәрсәгә күзләремне ачты, чөнки аны нәкъ менә сөргенгә сөрелгән татарлар салган булырга тиеш иде. Дөрес, аның рәсми ачылышы 1905 елга туры килә, әмма аны төзү өчен рөхсәт сорап татарлар инде 1881-1883 елларда ук йөри башлый, 1892 елда рәсми рөхсәт алалар, бу хакта кайбер мәгълүматлар сакланган, аны Енисейск музее архивында таптым. Мәчет кызыл кирпечтән, Казандагы Сөембикә манарасына охшатып, манарасы берничә яруслы итеп эшләнгән, дивардагы тактага исеме Татар мәчете, дип язылган, 1892 елда салынганлыгы әйтелгән. Дата төрлелегенә дә аптырарга кирәкми, чөнки мәчет сала башлау һәм башкарып чыгу, зур каршылыклар белән, берничә этапта барган. Тәфкил абый язуынча, Енисейскида әле бу таш мәчеткә кадәр агач мәчет тә булган, анысын да сөргенгә сөрелгән татарлар салган!

«1871 елның кышында бистә татарлары өч бурадан мәчет өлгертәләр, - дип яза ул. – Тагын ике-өч елдан ул мәчет манаралы була. Ислам җәмгыяте дә төзиләр». Тәфкил абыйның китабына кермәгән кулъязмасыннан күренгәнчә, мәчеткә мулла итеп Мөхәммәтсабит белән бергә сөргенгә сөрелгән этапташы, Себердәге күршесе Хәкимулла Талипов сайлана. Рәсми документларда Николай Никитин дип күрсәтелгән Хәкимулла мулла турында өяз исправниклары губернаторга хәбәр итә. Енисейскига шундук урыс миссионерлары килеп җитә, кәгазьдә христиан дип язылган тоткын татарларны үзләренчә «эшкәртә» башлыйлар. Әмма дин өчен Себер киткән татарларның кемлеген белгәч, тизрәк китү ягын карыйлар, аларны мәчет манарасыннан яңгыраган азан тавышы озатып кала...

Рәсми документларда, җирле матбугатта Енисейск мәчетенең салыну еллары да, имамнары да төрлечә күрсәтелгән. Красноярск крае мөселманнарының дини идарәсе матбугат органы булган «PROИслам» газетасында язылганча, элегрәк салынган агач мәчет – гыйбадәт йорты намаз укучыларны сыйдыра алмый башлагач, 1881 елны мөселманнар җыены яңа Җамигъ мәчет салу турында карар кабул итә. Башта бу салынып яткан мәчетнең имамы Казан губернасыннан Әхмәтсафа Таҗетдинов була, ул үлгәч, 1895 елда аның энесе Хуҗәәскәр сайлана, аннан инде Тубыл губернасы тумасы, бохаралы Корычев Абдулкәрим Рәхмәтулла улы раслана. Соңгысы Мәккәдә дини белем алган була, аны Томск мәдрәсәсендә укыткан җиреннән Енисейск мөселманнары үзләре чакыртып ала. Таш мәчет исә Түбән Новгород губернасыннан Бикчәнтәй Бизәнтәев (Бакиев) акчасына салына, ул вафаты алдыннан мәчет төзелешенә 4 мең сум акчасын васыять итеп калдырган була. Калган акчаны халык бирә. (PROИслам, 2017, № 1)

Әлбәттә, мәчет булган җирдә мәдрәсә дә булмыйча калмый. Һәм бу бит сөргендә! Урыс арасында, кара урман эчендә... Бернигә дә карамый, тоткын татарлар балаларына дини белем бирергә уйлый һәм ирешә. 1885 елда инде Енисейскида татарлар мәчет каршында үз акчаларына мәдрәсә ача, анда 40 малай укый, аларга белемне имам Әхмәтсафа хәзрәт Таҗетдинов үзе бирә. «В «Краткой летописи Енисейского уезда и Туруханского края» А.И.Кытманова за 1885 г. отмечено, что «...разрешено магометанскому имаму Ахмет-Сафе Тазетдинову открыть школу для обучения в медресе детей арабской, бухарской и татарской грамоте и Корану.» (Татары. 100 лет на берегах Енисея. Земля, ставшая судьбой. – Красноярск, 2018, стр. 17.)

Кемнәр соң ул – шушы хәлдә дә дин-иман турында кайгырткан, бу эшләрне башлап йөргән һәм башкарып чыккан кешеләр? Алар документларда теркәлеп калганмы? Калса, кайда саклана? Һәм шушы мизгелдән Красноярск дәүләт архивы белән эшем башланды.

Башта мин «Тематический перечень документов: «Мусульманские народы на территории Енисейской губернии – Красноярского края», дип аталган исемлек таптым, ул 1808 елдан башлана, 2006 ел белән тәмамлана. Бу исемлектә 414 эш теркәлгән, Енисейскига караганнары да бар. Әмма исемлек – ул әле чыганак үзе дигән сүз түгел, 140-150 еллык бу документларны архив киштәләреннән эзләп табарга кирәк! Себергә соңгы сәфәремдә төп игътибарымны Енисейск шәһәренә бирдем, Красноярскида аз вакытка тукталдым. Ә мине кызыксындырган документлар барысы да Красноярск дәүләт архивында булып чыкты. Әмма алар артыннан кат-кат Себергә дә чыгып китеп булмый. Һәм заман мөмкинлекләрен файдаланып, интернет аша эшләп карарга булдым.

Иң башта архивның рәсми сайтында шәхси кабинетымны ачып, теркәлдем. Аннан үземә кирәкле документларны эзли башладым. Әмма ул чорның мин эзләгән документлары цифрлаштырылмаган булып чыкты, ягъни, электрон варианты юк. Инде бер генә юл кала – аларның электрон күчермә-копияләрен алырга. Архив хисабына законлы рәвештә акча күчереп, моны да эшләп була икән. Акча түләп, үземне кызыксындырган 4 эшкә заказ бирдем, менә алар:

5 октября 1884. Общественный приговор мусульманского общества города Енисейска о строительстве соборной мечети. Ф.595. Оп.2. Д.1143. ЛЛ.10-11об, 16-18.

7 ноября 1888. Список прихожан Енисейского магометанского молитвенного дома, постоянно проживающих в городе Енисейске. Ф.595. Оп.2. Д.1143. ЛЛ.32-35.

1891. Список мещан города Енисейска, крестьян и ссыльнопоселенцев Енисейского округа и Туруханского края, являвшихся прихожанами Енисейского магометанского молитвенного дома. Ф.595. Оп.2. Д.1143. ЛЛ.62-63об.

1891. Список прихожан Енисейского магометанского молитвенного дома, проживавших в городе Енисейске в течении последних 5 - 25 лет. Ф.595. Оп.2. Д.1143. ЛЛ.49-52об.

Һәм могҗиза – ике атнадан бу тарихи документларның 28 бит күчермәсен алдым! Менә ул – 1884 елда Енисейскидагы мөселман җәмгыятенең Җәмигъ мәчет салырга дигән карары; 1888 елда даими рәвештә Енисейск шәһәрендә яшәүче мөселманнарның исемлеге; 1891 елгы инде киңәйтелгән исемлек – анда Енисейскидагы гыйбадәт йортына (агач мәчеткә) йөрүче, Енисейск округында һәм Турухан краенда яшәүче мещан, крестьян һәм сөргендәге «поселенецлар» теркәлгән; һәм шул ук елда тагы бер исемлек – соңгы 5-25 елда Енисейскида яшәгән, мәчеткә йөргәннәрнең исемлеге. Бу – мөселманнар турында йөзләгән «эш»тән нибары дүртесе генә әле! Күрәсез, ул вакытта да мөселманнар өстеннән күзәтү нык булган, аларның һәрберсе исәптә торган, һәр адымнары теркәлеп барган...

(Дәвамы киләсе санда).

Фәүзия БӘЙРӘМОВА,
язучы, тарих фәннәре кандидаты.

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ

Спрут заманы

(Дәвамы. Башы 5 нче санда).

Сызгырып утыру белән кайнарланган Гвидо тәнәфестә сикереп торды:

– Артур, утырып тор, мин «Бенфика» егетләре янына төшеп менәм, вәгъдә биргән идем. Алар бүген төнлә кайтып китә, ике көннән Лизбонда мөһим календарь уены. – Ул малайларча йөгереп кенә, аска төшеп китте, аларның урыннары ике команданың да чишенү-киенү бүлмәләре өстендә генә иде.

Шул чагында Шубаринны борчуга салган сәер бер очрашу булды. «Рица»да шәпләп ашап-эчкәннән соң, аның тамагы кипкән иде, ул чыгу юлында йөрүче сатучыдан бер шешә минераль су алып бирүләрен сорады. Француз суы «Перрье»не аңа таба килгән бер ир кеше китереп бирде. Суны биргәч, ул рөхсәтсез-нисез генә, аның янәшәсенә, Гвидо урынына утырды һәм кинәт кенә саф үзбәкчә:

– Хәерле көн, Артур Александрович! Мюнхенда ничек яшәлә соң? Андый-мондый борчуларыгыз юкмы? – дип сорады.

Гадәттәге үз-үзен тота белүе ярады, Шубарин, сүзсез-нисез генә суын эчеп бетерде дә, үзбәкчә сөйләшә торган сәер кешегә борылып карады. Тегесе кырык яшьләрдәге ир, модалы булса да, капчыксыманрак эленеп торган костюмнан, кыйммәтле һәм кычкырып торган галстук та таккан, күрәсең, анысы Кайзенштрасседагы берәр француз кибетеннән алынгандыр, сөйләшүе һәм тышкы төс-кыяфәте белән Ташкент кешесенә бик тә охшаган үзе. Мәскәү яки Ленинградта ышанып шулай дип әйтеп булыр иде, әмма Мюнхенда, җитмәсә әле стадионның иң кыйммәтле урыннарында якташыңны очрату – гайре табигый хәл.

Артур Александровичның күзе әңгәмәдәшенең кулына төште: тегенең бармакларындагы эре бриллиантлары, – аларны бездә гади генә «болванкалар» дип тә йөртәләр, – үзен башы-аягы белән «безнең кеше» икәнен, беләзегеннән, бетерергә тырышып та бетерә алмаган татуировкасы утырып чыкканлыгын дәлилли иде.

Шубаринның каршында утыручы бу кеше безнең илчелек яки консуллыктан, йә булмаса башка оешмадан, яки футбол буенча кубок уены финалы турында язучы берәр журналисттыр дигән уйлары шундук юкка чыкты. Шубарин бу ябык йөзле, нечкә генә мыеклы, йөгерек күзле кешене, күпме генә тырышса да, исенә төшерә алмады. Ә бит теге, никадәр затлы-шәп киенсә дә, үзенең күптәнге җинаятьче, берничә кат утырып чыкканлыгын яшерә алмый иде.

Шубарин җинаятьчеләр дөньясын яхшы белә-таный һәм беркайчан да ялгышмый иде. Шуңа күрә:

– Рәхмәт. Минем бер мәшәкатем дә юк. Дөрес, Ташкентымны сагынам, – дип, сүзне тәмамларга ашыкты. Чөнки хәзер Гвидо килеп чыкса, бу көтелмәгән якташның кем икәнлеген абайларга мөмкин иде. Ә банк эшләре белән танышырга теләгән кеше мондый җинаятьчеләр белән аралашырга тиеш түгеллеге көн кебек ачык – үзенә ниндидер тап төшергән банк ул инде – нонсенс, ягъни булмастай хәл.

– Әйе, без сезнең Германиядә эшләрегез әйбәт барганын белеп торабыз, сезнең белән бик дәрәҗәле кешеләр кызыксына, сез, немецләрдән башка да, шактый атаклы эшмәкәрләрнең ышанычын казангансыз. Мистер Лежава да сезнең банкка акча салырга әзер шикелле.

– Без әле ул хакта сөйләшеп өлгермәдек, – дип сүзне кисәргә ашыкты Шубарин. Аның бу кешедән тизрәк котыласы килә иде.

Тегесе, вакыт икесе өчен дә бик кысан икәнен чамалап, дәвам итте:

– Сез мөстәкыйль рәвештә һәм уңышлы итеп Европа банк системасына тамыр җәеп киләсез. Сезнең шикелле бу очракта кем булдыра алыр икән, ай-һай!. Беренчелек сезнеке! Шуның өстәвенә, сезнең, Лежава кебек, көнбатыш бизнесында дәрәҗә тоткан дус-танышларыгыз да юк түгел. Боларның һәммәсе дә бирелдә уңыш казанган очракта искә алынмый калмастыр.

Артур Александрович, теге адәмнең алдан өйрәтелгән сүзләр сөйләвен аңлап алгач, бүлдермәскә булды – вакыйгаларны аңлап бетерергә кирәк иде.

Тегесенең артык тырышуданмы, маңгай-муеннары тирләп чыкты, әйтәсе сүзләре онытылып бетмәгәе дип, ул аларны тезәргә ашыкты.

– Сез аңлыйсыздыр, хәзерге интеграция вакытында Европада зур акчаларны «юу-чистарту» һаман да кыенлаша бара, моның өчен шактый зур бәяләр дә түләргә туры килә. Шуның өстенә, Англия һәм Американың эре банкларында булып узган скандал-шау-шулардан соң, сезне минем немец дусларым белән хезмәттәшлек итәргә үзе үк этәрә шикелле. Банк эшләре безнең өчен яңа әле, шуңа күрә, тикшереп-нитеп тормастан, әле кем тикшерсен, диген, акчасы килә икән – хуш! Үзебез дә һәр тикшерүчене танып беләбез, дөресрәге, кайсысына күпме түләргә кирәклеген белә идек, ә инде килешергә теләмәгәннерне хәл итү – безнең кайгы-хәсрәт... Безгә абруй-дәрәҗәле банк кирәк, немец дусларым аңа сез сөйләшкән кешеләрнең барысыннан да күп мәртәбәләр артык капитал салырга әзер. Сез мине аңлыйсыздыр дип уйлыйм? – дип сорады таныш түгел кеше, озак дәшми торган Артур Александровичның сынаулы карашыннан югала төшеп.

– Бик аңлыйм, – дип кыска гына җавап бирде Шубарин. Безнең илдә фахишәлек белән җинаятьчелек кенә халыкара дәрәҗәдә, дигән раславына тагын бер мәртәбә исбатлау алды ул. Менә алар халыкара мәйданда да беренчеләрдән пәйда булды: башкалар суверенитет дип лаф органда, болар үзләренең «агач» акчаларын валютага әйләндереп куячак, үзләренең чит илдәге коллегаларыннан аны «юып» биргән өчен башка җирләрдәгедән бер дә ким сыдырмаслар, юкка гына алар Россиядәге аз процентларга исәп тотмый...

– Немец коллегаларым сезгә һәркайсы йөз мең маркалык биш чек язды, аларны үзегезнең эшегез өчен файдаланыгыз...

– Мин сезне тулысынча аңладым, – дип теге адәмне бүлдерде Шубарин. – Миңа акча кирәкми, мин аны дусларымнан да алып тора алам, әйтик, мистер Лежавадан. Ә инде банкка килгәндә, без атылмаган аю тиресен бүлеп маташабыз шикелле. Бу хакта соңрак, Ташкентка кайткач сөйләшербез...

Әңгәмәдәшнең нәфрәте кайнап торса да, ул тыныч сөйли. Бу көтелмәгән кешене модалы галстугыннан тотып, гырылдый башлаганчы, умырткалары шытырдаганчы буасы килә иде. Ләкин мондый әдәмчекне алай гына эләктерә алмассың – артында кемнәр тора икән, шуны тәгаен генә белергә кирәк.

Кунак, күрәсең, мондый сөйләшүгә дә әзер иде, аның икенче запас варианты да бар икән.

– Юкка гына сез чеклардан баш тартасыз, алар ихластан иде, ярты миллион марка – акча ул. Ә Ташкентта, сезне хафага салып булса да әйтим инде, анда зур үзгәрешләр... Үзәк Комитеттагы дустыгыз Сухроб Ходжаев хәзер «Матросская тишина» төрмәсендә. Прокурор Камалов сезнең Югары судтагы икенче таянычыгыз Хашимовның да койрыгына баскан шикелле. Сезгә дустанә булган Аксай ханы Акмал төрмәдә; Заркент өлкә комитеты секретаре сезнең беренче ышанычлы кешегез Әнвәр Абидович Тилләходжаев унбиш елга хөкем ителгән. Ә без үзгәртеп кору дип йөртә торган хәзерге заманда, Артур Александрович, сез яңа дуслар таба алмадыгыз. Сез тирә-якка җирәнеп карадыгыз, сезгә һәммәсе дә нувориш байлар, бер сәгатьлек кенә хәлифләр булып тоелды, ә юкка гына... Хәзер сез Ташкентта беркемгә дә таяна алмыйсыз... Бары тик без генә сезнең талантыгызны тиешенчә бәяли алабыз. Сез банкир булырга хыялланган идегез, булыгыз соң, ярдәм итәрбез, булышырбыз, якларбыз...

Кунак кинәт кенә урыныннан күтәрелде, ашыгып саубуллашты да, җир астына төшеп киткәндәй, юкка чыкты. Баскычтан, үз урынын эзли-эзли, мистер Лежава менеп килә иде.

* * *

...Хан Акмалны кулга алганнан соң, Аксай тынып калды, үз кабыгына бикләнде. Акмал Ариповтан тыш, төбәктә котырынган аның якыннарыннан тагын берничә кешене дә алдылар. Аксай халкы, ниһаять, бу үзгәртеп кору белән безгә дә көн килер дип, шатланып бетә алмады. Әмма ай арты айлар үтә торды, ә яхшырак мул-имин тормыш Аксайда күренмәде. Киресенчә, начарлана гына барды.

Әгәр баштарак халык урамнарда, чәйханәләрдә, туй мәҗлесләрендә Акмал хан кул астында озак еллар яшәгәндә күңелләрендә җыелган ризасызлыкны чыгарып түксә, хәзер хәл бөтенләй үзгәрде. Гади халык яңадан җиргә генә карап йөри башлады: Акмалның кайтып төшүе чынбарлыкка әйләнде, бу бигрәк тә аңа тәлинкә тотучыларның кыяфәтендә үк чагыла иде. Алар башларын горур чөеп, яңадан яный башлады: туктагыз әле, менә Хуҗа кайтыр, ул сезгә хәбәрдарлыкны да, үзгәртеп коруны да, фикерләр төрлелеген дә, демократияне дә күрсәтер, диделәр...

Аксай халкы Фирганә вакыйгаларында мәсхет төрекләренә каршы оештырылган һөҗүмнәрдән соң бигрәк тә пошаманга төшеп калды.

Гел актан киенеп, тын гына йөри торган намаз карты, Акмал Ариповның остазы Сабир-бобоның яңадан күңеле күтәрелеп китте. Россиядә христиан диненең мең еллыгын бәйрәм итү уңаеннан хөкүмәт баштa христианнарга, аннары мөселманнарга да түземлерәк карый башлады. Күп еллардан соң Мәккәгә хаҗ кылырга баручыларны мөселман диния нәзарәте сайлап алды. Кәгъбәдәге изге ташка табынып кайту өчен Сабир-бобо да хаҗга җыенды. Ул хәтта күңеленнән генә уйлап та куйды: әгәр дә аны изге Мәккә белән Мәдинә калаларына кертсәләр, анда берәр кара бәрәнне корбан чалырга рөхсәт итсәләр, димәк Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән Сабир-бобо үзе үтергән бертуганының улы – хыянәтче Мәхмүт өчен Ходай аны ярлыкаган дигән сүз булачак.

Сабир-бобо Согыд Гарәбстанына хаҗ кылырга хәтта ике тапкыр барып кайтты, хәзер инде ул бертуганының улы оҗмахка керәчәк дип чын күңеленнән ышана. Хаҗдан беренче кайтуга ук ул якташларына Аксайда мәчет салдыру өчен зур сумма акча бирәчәген дә белдерде.

Надан дехканнарны иң гаҗәпләндергәне Сабир-бобоның мәчет салырга сайлаган урыны булды. Мәчетне Аксайның Кызыл мәйданында Ленинга куелган мәһабәт һәйкәл каршында ук сала башладылар, Даһи юлбашчының алга сузган кулы беркая да күрсәтми икән.

(Дәвамы бар).

Гомер юртагы кыйбласын белеп чаба

Язучы Рәфкать Кәрамигә 80 яшь

Халкыбыз күңеленә җыр булып, моң булып кергән Сарман төбәге. Илһамнары, Зөһрәләре генә ни тора. Тик шунысы да бар, җырмоң ул әдәп, әдәбият булган җирдә яралмыймы икән?! Сарманнарның гына түгел, татар әдәбиятының горурлыгы, йөзек кашы булган Кларалары, Дамирлары, Фәритләре, Рәфкатьләре генә дә ни тора.

Сугыштан соңгы тормыш авырлыгын һәм тыныч тормышның кадерен белгән буын арасында үсеп чыныгу алган Рәфкать Кәрами татар әдәбиятында үз сүзен 1960 елларда ишеттерә башлый. Язганнарында сарманлыларга хас үткенлек, җорлык һәм эчке моң саркып торган яшь Кәрамине язучылар да, укучылар да җылы кабул итә. Яшь булса да, Рәфкать Кәрами әдәбиятка төрле катлам эшчеләренең тормышын белеп килә.

Рәфкать Кәрами (Рәфкать Кәраметдин улы Кәрамиев) 1942 елның 18 февралендә Сарман районы Рангазар авылында туа. Авылда җидееллык мәктәпне, 1959 елда Алабуга мәдәният-агарту техникумын тәмамлагач, берникадәр вакыт район мәдәният йортында баянчы, аннан Түбән Әхмәт авылында клуб мөдире булып эшли. Җырга-моңга бай егет кешенең күңел халәтен мәдәни даирәдә ныграк тоемларга өйрәнә. Бар нәрсәгә игътибарлы, күргән-белгәнен күңел түренә салып куя торган егет әлеге тормыш чынбарлыгын алга таба үз әсәрләрендә шактый киң һәм урынлы куллана.

Нечкә күңелле, әмма практик фикер йөртә торган егет җырлап-биеп кенә тормыш арбасын тартып бару мөмкин түгелен тиз төшенә. Бу – Татарстанның «кара алтын»ы белән илне шаулаткан чоры. Беләгендә көч ташып торган егәрле егет Әлмәт якларына юл ала. Әлмәт Рәфкатьне колач җәеп каршы ала. Ул производствода, Чупай таш карьерында башта рәссам-бизәүче, гади эшче, электрик һәм машинист ярдәмчесе булып эшли, аннары «Әлмәтбурнефть» трестының 1нче энерго-хуҗалыгы конторасында (КЭХ-1) хезмәтен дәвам иттерә. Шул эшеннән армия сафларына алынып, өч ел Хәрби диңгез флотының яр буе гаскәрләрендә хезмәт итә.

1964-1977 елларда Р.Кәрамиев Казанда оргсинтез заводын коруда катнаша, әүвәл электрик булып эшли, соңыннан «Казанхимстрой» трестының 5 нче төзү идарәсендә профком рәисе була. 1970 елда ул, төп хезмәтеннән аерылмыйча укып, Казан дәүләт университетының тарих бүлеген тәмамлый.

Боларның барысы да Г.Исхакый премиясе лауреаты Рәфкать Кәраминең 2018 елда «Ак бүре» нәшриятында дөнья күргән «Олы юл да сикәлтәле» трилогиясендә чагылыш тапкан. Роман-трилогия «Солдат шулпасы», «Сөеп туймас чакларың», «Кая чабасың, гомер юртагы?» исемле өч китаптан тора. Әлеге трилогия автобиографик әсәргә якын. Язучының тәрҗемәи хәлен белгән укучы әсәрдәге төп герой Габделнурның прототибы Рәфкать Кәрами үзе булуына чын-чынлап ышана.

Автор хезмәт кешесенең тормышын яхшы белә. Тормышның ул «бизәкләре» аңа ят түгел. Күбесе авторның үз җилкәсе аша уздырылган. Шуңа да Р.Кәрами һәр эш-процессны, геройларының күңел кичерешләрен бөртекләп, тәфсилләп бирә. Укучы аңында тулы канлы картина тудыра. Һәр вакыйга язучының үз җаны аша уздырылган. Кешеләр арасындагы киеренке мөнәсәбәтләр, ихлас аралашу гадилеге, табигыйлеге белән укучыны үз артыннан ияртә. 1960 елларда күпмилләтле Россия халыклары әдәбиятына хас социалистик реализм методы кысаларында иҗат итә башлаган Р.Кәрами бүген дә, яхшы мәгънәдә, үз кыйбласына тугры калган язучыларның берсе һәм сирәге. Чөнки бүгенге чор әдәбияты хезмәт кешесе темасыннан читләште. Игътибарны чәч-баш ясаучы, йон йолкучыларга юнәлтте кебек. Бәхетне җиңел юл белән табучыларны, эшләмичә ашаучыларны герой үз итмәсә дә, физик көч түгеп, гадел хезмәт итүчеләр «яңа формат»тан төшеп калды. Р.Кәрами әсәрләре исә,чын мәгънәсендә хезмәт кешесен, аның ярата, кайгыра, шатлана белә торган җанын ачуга корылган. Авторның геройлары һәрвакыт хәрәкәттә. Аның әсәрләренә динамика хас. Гомумән, Р.Кәраминең әлеге өч китабын нindiдер «...изм» кысаларына кертү кирәк тә түгелдер. Чөнки ул язган әсәрләрдә «дошман эзләү», акка, карага бүлү юк. Анда бары тик хезмәт, әдәп һәм әдәпсезлек, әхлак һәм әхлаксызлык, ярату, кичерү, яшисе килү генә булырга мөмкин. Р.Кәрами – шундый язучы, ул кысадан да чыкмый, шул ук вакытта кысага да керми. Аның үз «кысасы» бар. Совет чоры булсынмы, үзгәртеп корумы – аның өчен эш-хезмәт беренче урында булды. «Эшләп ашау» - аның төп девизы. Ә эшли белгән кешенең җанында пычрак, күңелендә кер булмый. Ул башкаларга да шуны тели, башкаларда шуны күрә. «Кая чабасың, гомер юртагы?» әсәрендә Габделнур үзенең башына сугып акчасын талап киткән шәһәр бандитын да акларга сәбәп эзли.

Р.Кәраминең теле бик үзенчәлекле. Анда әллә нинди купшылык та юк. Ул үзенең гадилеге белән алдыра. Трилогия башыннан ахырына кадәр «безнең як теле» белән язылган. Монда Казан артына, Тау якларына хас чәчәклечуклы, бизәкле тел түгел. Кәрами теленә табигыйлек хас. Ышкы тидермичә, балта белән дә осталарча, чын сәнгать әсәре кебек ясалган корал кебек.

« – Әни, исәнме!

– Исәнме, улым! И-и, балакаем, кайттыңмы?!

Габделнур тартынып кына әнисен кочаклагандай итте. Кайбер халыкларда кабул ителгәнчә лач-лоч үбешүне әйткән дә юк, хәтта кочаклавы да аркасыннан кагу гына иде. Кечкенәдән үк төчеләнүгә өйрәнмәгән, күнекмәгән бала да, аларны шулай тәрбия кылган ана да беренче карашка салкынча, корырак исәнләште кебек тоелырга мөмкин иде.»

Әсәрләрдә кулланылган халык җырларындагы әдәп кысаларына сыеп бетмәгән сүзләр, эшче ир-атларның кызлар белән аралашкандагы тупас сөйләм дә урынлы килеп керә. Һәм тормыш чынбарлыгын тулырак ачып җибәрә. Егет белән кыз, ир белән хатын арасындагы интим хисләр, мөнәсәбәтләр дә кысадан чыкмыйча әдәп белән сурәтләнгән. Әлеге эпизодлар бу хисләрнең барлык кешегә дә хас булуын, тик чама һәм акыл хисе белән идарә итәргә кирәклеген искәртә.

Автор – рәссам-натуралист. Ул зур полотнога нечкә пумаласын төрле төсле буяуларга манып, төсләрне еш төрләндереп яза. Киң колач белән гомумиләштерүләр сирәк. Вакыйгалар чагылган гомуми фонда вак детальләрнең һәркайсы үз урынында. Габделнур солдатның туган йортындагы күзәтүләре Рәфкать җаны аша тасвирланган. Әнисе Гөлзифа түтинең киеме, өйдәге җиһазлар, әбисенең сугу станогы, паласлары, үзара сөйләшүләре шулкадәр гади һәм табигый бирелгән.

Авыл тормышын тасвирлагандагы төгәллек шәһәр мохитен сурәтләгәндә дә, производстводагы хезмәт барышын күрсәткәндә дә дәвам итә. Төрле һөнәр ияләренең хезмәтләре артык вакламыйча, ләкин дөреслеккә һич хилафлык китермичә язылган.

Әйе, күләме ягыннан Р.Кәрами әсәрләре шактый саллы. Бүгенге мобиль заманда укучы өчен шул ягы белән кыенлык та тудырырга мөмкин. Ләкин аңлы, акыллы укучы өчен аның әсәрләре табигыйлыгы, чынлыгы, кешеләрнең хис-кичерешләрен оста бирә белүе белән кадерле. Татар әдәбияты тарихы өчен исә, тәфсилләп язылган тарихи мәгълүматлары белән кыйммәт. Бу урында әдәбият галиме Д.Заһидуллина фикере белән килешми мөмкин түгел. «Р.Кәрами иҗатына хас, аның әсәрләрен интеллектуальлеккә юнәлткән тагын бер сыйфатны аерып күрсәтергә кирәк: ул әсәрләрнең тарихи, мәдәни-тарихи мәгълүматлар белән урынлы һәм отышлы баетыла баруы. Үзе тарихчы белгечлеге алган язучы күп белә, укучысын да җае чыккан саен дөнья тарихына, рәсем яки музыка сәнгатенә, аерым шәхесләр биографиясенә, географик урыннарга нисбәтле кызыклы мәгълүматлар белән таныштыра. Мондый урыннар ят ямаулык түгел, алар әсәр тукымасына бик табигый урнашып, укучы игътибарын җыйнап тора», – дип язды ул. Әйе, роман-трилогия тарих белән матур әдәбиятның синтезы кебек. Автор нәкъ тиешле, кирәк урында төгәл итеп тарихи мәгълүмат бирә. Кайбер урыннарда алар белешмә рәвешендә җәяләр эчендә китерелә.

Гомумән, Р.Кәраминең әлеге трилогиясе Россия тарихы эченә кергән татар язмышын колачлаган әсәр. Гади авыл малае Габделнур язмышы аша тулы бер тарих сурәтләнгән. Сугыштан соңгы авыр тормыш, социализм, ерактан күренгән «коммунизм кыры», Әфган илендә интернациональ «бурыч», үзгәртеп кору, «прихватизация» – боларның һәркайсына Р.Кәраминең үз бәясе бар. Автор яшәү мәгънәсе, гомер, тормыш кебек сорауларга җавап эзли. Эзли һәм таба.

Беренче китапта солдатлар сүз иярә сүз чыгып дин турында сөйләшеп китә. Пионер, комсомол сафларында тәрбияләнсәләр дә, һәркайсы ата-баба диненнән хәбәрдар һәм һәркайсы эчтән генә белгәннәрен укый. Динне уен-көлкегә әйләндерү берәүгә ошамый. Гадәттә, җыр нинди нотадан башланса, шуның белән тәмамлана. Әсәр ахырында Габделнур Хаҗ сәфәренә китеп баручы Солтангир Габсалихович белән очраша.

Әйе, дөнья үзгәрде, шулай да юлыбыз уңар. Гомер бит ул син үтәсе озын юл. Рангазарның тар сукмагыннан озын юлга кузгалган Рәфкать ага Кәрами сөрлекмичә, адашмыйча чын кеше, чын язучы исемен горур йөрткән хәлдә алга бара.

Рәфкать ШАҺИЕВ,
язучы, филология фәннәре кандидаты.

Мәдәни җомга
18 февраль
№6, 2022

Чын рәссамнар сирәгәя барган заманда да саф иҗатка тугры калган шәхесләребез бар. Шуларның берсе – Рөстәм Хуҗин. Егетнең зыялылыгы, хезмәт сөючәнлеге, киң фикер йөртә белүе, караңгы заманда да яхшыга ышанып яшәве таң калдыра. Бу юлы сүз Р.Хуҗинның Ә.Мәҗитов исемендәге картиналар галереясында ачылган шәхси күргәзмәсе турында.

Кояш баешы да кабатланмый



Экспозициядә йөз илледәп картина урын алган. Аның бер үк вакытта Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында да күргәзмәсе уза. Биредә рәссамның тарихи картиналары урын алган. Университеттан экспозиция Халыклар дуслыгы йортына күченәчәк. Мәҗитов галереясында исә Р.Хуҗинның портрет, пейзаж, натюрмортларын күрергә мөмкин. Соңгы елларда халыкта бу жанрларга карата хөрмәт кимеде кебек, чөнки бер иш рәссамнар өчен ул акча эшләү чарасы гына булып калды, сыйфаты нык төште. Әмма чын пейзаж, натюрморт иҗат итүе бик авыр. Портрет турында исә әйткән дә юк. Безнең геройбыз Рөстәм исә – нәкъ менә портрет остасы. Мәскәүдә сәнгать академиясен тәмамлаганнан соң да ул, калып, тагын өч-дүрт ел портрет серләренә төшенә. Рөстәмне башка рәссамнардан акварель буявына мәхәббәте дә аерып тора. Зурзур картиналарны да ул күпчелек нәзберек акварель белән иҗат итә.

Соңгы елларда төрле күргәзмәләрдә булырга туры килде. Арзанлы рамнарга утыртылган шәп картиналарны күреп җан елый иде. Р.Хуҗин күргәзмәсендә исә эчтәлектә генә түгел, бизәлеш ягыннан да затлылык күзгә ташлана. Рөстәм тамашачылары белән һәрвакыт бик теләп, җиңел аралаша. Затлы рамнарны күреп, тел шартлатучыларга шундук җавап та бирде. «Рам матурлык өчен генә түгел, ул тамашачыга картина эченә «үтеп керергә» ярдәм итә торган портал кебек зур әһәмияткә ия, шуңа күрә аның сурәткә туры килүе мөһим. Картиналарны бизәү – үзе аерым сәнгать», – ди. Адәм баласы акчага табынып яшәгән заманда рәссамның чын сәнгатькә тугры кала алуы, дәрәҗәсен төшермәве дә гаҗәп тоелгандыр. Юкса күргәзмәдә бу хакта сүз кузгалтмаслар иде. «Рәсем сәнгате җәмгыятьнең, кеше күңеленең халәтен чагылдыра, шуңа күрә бу заманда аның очсызланып калуы табигый, - дип бу хакта фикерләре белән уртаклашты автор. - Картина рәсемнән һәм төстән тора. Рәсем – сүз булса, төс – музыка. Музыка сүзләргә ятса, матур җыр барлыкка килә. Ни өчен бүген дөньяны арзанлы, затсыз җырлар басты? Чөнки сүзнең кадере бетте, моң юкка чыкты. Рәсем сәнгате белән дә шул ук хәл. Тирә-юньгә карасак, һәр предметка, күренешкә рәссам һөнәренең өлеше кергәнен күрәбез. Шулай булгач, үзебезгә тырышырга кирәк. Художник исемен горур йөртү, чын сәнгатьнең дәрәҗәсен төшерми саклау сорала».

Р.Хуҗин үзе ун рәссам кебек иҗат итә. Пленэрлардан, арт-галереялардан кайтып керми. Анда яңа кешеләр белән таныша. Күңеленә илһам, дәрт туплап кайта. Аеруча үзе туып-үскән Урал якларын ярата. Бу экспозициядә дә Урал күренешләре байтак иде. «Чын рәсем сәнгатен Уралга баргач кына аңлап ачтым. Чын төс-буяулар ташлар төсендә була, дип өйрәттеләр безне академиядә укыганда. Екатеринбургта ташлар музеенда булып кайтканнан соң, бу сүзләрнең хаклыгына ышандым. Юкка гына элгәре заманнарда рәссамнар буяуларны таш ышкып барлыкка китермәгән икән», – дип иҗатының кайбер нечкәлекләре турында сөйли.

Күргәзмәдә тагын бер мөһим нәрсәгә игътибар итмичә мөмкин түгел. Пейзаж, портрет, натюрморт булсын, һәр картина оптимистик рух белән сугарылган. Ак яулыклы, тулышкан битле авыл апалары, чана шуучы балалар, авыл ызбасы янында өелеп яткан утын пүләннәре, яңа гына җирне төртеп чыккан сыек яшел чирәм аркылы рәссам тамашачыга тормышның гүзәллеген күрсәтергә тели. «Рәссамның максаты дөньяның матурлыгын искәртеп, адәм баласын Аллаһка якынайту, чөнки Аллаһ – матур һәм гүзәллекне сөя. Бигрәк тә бу шомлы, кыйбласыз заманда рәссам халкы халыкны матурлык тирәсендә туплау өчен тырышырга тиеш», – дип Р. Хуҗин рәсем сәнгатенең асылын аңлатты.

«Шушы матурлыкны санга сукмыйча, бераүләр Малевичның «Кара квадрат»ына табына», дип тамашачылардан берәү әрнү белән әйтеп куйды. «Рәсем сәнгате ике төргә аерыла, минемчә, берсендә – рәссамнар Дали, Малевич, Пикассо кебек, үзләрен күпертеп күрсәтергә теләсә, икенче берәүләр, киресенчә, үзләрен онытып, матурлыкны арттыра», – дип бу җәһәттән уйлары белән уртаклашты автор. «Тормыш-чынбарлыкны ничек бар шулай сурәтләүдән туеп, кабатланасы килмичә, рәссамнар абстракт сәнгатькә табан ялтыраткан дип әйтәләр ич», - дип тагын берәү төпченәсе итте. «Җир йөзендә бер таң да, бер кояш баешы да кабатланмый. Дөньяда бармакларындагы сырлар бер-берсенә охшаган ике кешене таба алмаячаксыз. Шулай булгач, реалистик картиналар иҗат итүче рәссам да кабатлана алмый», - дигән җавап белән бу мәсьәләгә ачыклык кертелде.

Моннан берничә ел элек Татарстан рәссамнары Кытайга барырга чакыру ала, әмма Мәдәният министрлыгыбыз юл акчасын түләүдән баш тарта. Р.Хуҗин үзе акча юнәтеп кояш чыккан тарафка юл тота. Унбиш көн эчендә дүрт шәһәрдә булалар, икесендә күргәзмә оештыралар. Рөстәм шуннан егерме ике картина иҗат итеп кайта. Санкт-Петербург, Төмәннән килгән өлкән яшьтәге рәссамнар Рөстәмнең җитезлегенә шакката. Бер иш Кытай күренешләрен бу экспозициядә дә күрергә мөмкин иде. «Европага ияреп, үзегезнең борынгы сәнгатегезне онытта күрмәгез», – дип кытайларга акыл да өйрәтә әле. Анда реалистик сәнгатьне бик хөрмәт итәләр, теше-тырнаклары белән ябышып укыйлар, өйрәнәләр, ди. Р.Хуҗинга да калып академиядә укытырга тәкъдим иткәннәр. Тик Рөстәм туган якка береккән. Аның хыялы - милли тарихыбызны чагылдыру. Мәскәүдә сәнгать академиясен «XIII гасыр Болгар каласында зур базар» картинасы белән тәмамлап чыга. Л.Хәсьянованың портрет остаханәсен тәмамлаганда, диплом эше буларак, «Мулла портреты»н тәкъдим итә. Аннан кайткач, «922 елда Болгарда Ислам динен кабул итүләре», «Х гасыр Болгар каласында Ага-базар», «Болгар өчен көрәштә иман белән!» һ.б. картиналарын иҗат итә. Шулай булгач кытайларга тәтемәячәк инде ул.

«Рәссам, пленэрларга чыгып, этюдлар иҗат итүдән туктарга тиеш түгел», ди Р.Хуҗин. Үзе ул пленэрларда бер көнне өчәр картина ясый. Әле бу экспозициядә дә бер минутны бушка уздырмыйча, тамашачыларны җәлеп итү, кызыксынуларын уяту өчен һәр көн саен килеп, натюрмортлар төшерә. Бу күргәзмә Рөстәмнең иҗатында меңләгән этюдлары арасында бер рәсем генә кебек. Киләчәктә егетне зур киләчәк көтә!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

«УТНЫҢ ЙӨРӘК ТИБЕШЕН ИШЕТӘМ»

Тимерчеләр династиясенең лаеклы вәкиле – Ренат Нуретдинов үз эшендәге иң катлаулы хезмәтләргә дә теләп алына. 34 яшьлек Ренат – дүртенче буын тимерче!

Р. Нуретдинов Караганданың Таттимбет исемендәге сәнгать колледжын тәмамлаган. «Башта рәссамлыкка өйрәндем, аннары скульптура бүлегенә күчтем. Династия геннары барыбер үзенә тартты», – ди Ренат Наил улы. Ул үзен металл буенча скульптор дип атый. Әмма аның сөйләгәннәрен тыңлаганда, Ренат бер дигән рәссам да, язучы да була алыр иде дип уйлыйсың. «Карагыз әле, нинди төсләр уены! – ди ул чираттагы яңа эшләнмәсенә күз төшереп. – Камиллек тудыру – минем шөгылем. Монда төсләр уенының металлны бозмавы гына мөһим. Төрлечә тәҗрибә ясарга да яратам, ниндидер өр-яңа һәм камил әйбер иҗат итү бик рәхәт. Миңа эскизлар, концептуаль фотолар алып киләләр һәм, әгәр аларда яңа төрдәге формалар булса, сөенәм генә. Заманча каминнар читенә декоратив бизәкләр еш ясарга туры килә, алар бик җиңел дә һәм шул ук вакытта чыдам да булырга тиеш... Чын оста алдында киртәләр юк. Гадәти булмаган иҗади чишелешләр – ул тәҗрибәмдәге яңа җиңүләр генә булачак бит. Һәм, билгеле инде, тимерче хезмәте өчен арзан түләү юк».

Ренат башкалабыз кунакханәләре өчен дә тимер бизәкләр ясый. Әйтик, бер кунакханә бакчасындагы аккошлы эскәмияләр аның алтын куллары белән Бөекбританиянең XIX гасыр эскәмияләре өлгеләре буенча ясалган. Күптән түгел «Ирек» мәчете территориясендә гарәп язмалы эскәмияләр урнаштырылган. Җилгә каршы баручы сәяхәтчеләргә охшаган мифик кош сыннары, зур яктырткычлар ясалган... Мондый сыннарны ясаганда, тимерче инде эретеп ябыштыручы да, сыннарга «борынгылык» төсмерләрен өстәү өчен кислоталар кулланучы химик та, буяучы да була. «Каберләргә истәлек такталары ясауда да катнашырга туры килә, – ди әңгәмәдәшем. Һәм фәлсәфи нәтиҗә ясый. – Вафат булганнар истәлеген саклауга үз өлешеңне кертү – яхшы гамәл ул. Үлгәннәр тереләргә караганда да рәхмәтлерәк».

Ренат Нуретдинов иҗатында хайваннар дөньясына да еш мөрәҗәгать итә. 17 ел эчендә иҗат иткән бөркет сыннары гына да утызга тулган. «Торналар да ясадым. Карагыз әле, боларының канат җилпешләре дүрт метр диярлек! Хөр бөркетләрне нык яратам. Бу күк патшалары сыннары уңышлы килеп чыксын өчен, аларның яшәү рәвешләрен, анатомиясен өйрәндем. Пошилар да коярга яратам. Башка җанвар анатомиясен өйрәнү дә мавыктыргыч. Бу нисбәттән Аллаһы Тәгаләнең бөеклегенә һәрдаим сокланам! Иҗат процессын догалар укып башлыйм. Сыннарга җан өрү, үз җаныңның бер кисәге белән бүлешү ниндидер илаһи мизгелләрсез бармый! Сынны заказчыга тапшырган шул минутларда, беләсезме, һәрчак моңсу... Әйтерсең аңа үз балаңны тапшырасың... Менә шул инде ул иҗат газабы».

Ренатның ничек тимерче-скульптор булып китүен сорашам. «Әтием ягы нәселендә – шахтерлар династиясе. 2009 елда кайгы килде, 35 ел чамасы шахтер булып эшләгән әтием нибары 59 яшендә вафат булды. Берничә ай буе бик кайгырып йөрдем. Бераздан әтием каберенә истәлек-һәйкәл урнаштырырга тиешлегемне аңладым. Әтием атказанган шахтер иде һәм Шахтер даны билгесенең тулы кавалеры иде! Шуңа күрә башта күмер кисәге ясап, аннары аңа ике чүкечле, бишпочмаклы Шахтер даны билгесен уярга булдым. Дүрт айдан истәлек-һәйкәл әзер булды, чардуганны да үзем эшләдем. Урнаштырган көнне үк әтием төшкә керде. «Мин килдем һәм барысын да күрдем! Миңа ошады! Рәхмәт сиңа!» – диде ул. Иртән бурычымны үтәгәндәй шатланып уяндым. Шул көннән башлап тормышым кинәт кенә яхшыга таба үзгәрә башлады».

Ренат Нуретдинов иҗатта әнисе нәселендәге бабасының әтисе Җәләлетдин Ялаловка охшаш. Ул Чебакса авылында гомер кичергән. Заманында Чебаксада исә тиңсез тимерчелек төре барлыкка килгән, ул тимерчелек башкаласы да булган.

Ренатка да иҗади тормышында кызыклы эшләр башкарырга туры килә. Мәсәлән, төрле металл кисәкләрен шар итеп ябыштырып, батискаф ясап куйган. Аңа диңгез йолдызы да беркетелгән, матур итеп буялган... Батискафны озак еллар океан-диңгезләр гизгән капитанга бүләк иткәннәр. Р. Нуретдинов иҗатында Бөек Ватан сугышы каһарманнарына багышланган мемориаллар да бар.

«Г.Тукай Кырлайда Сәгъди абзыйда уллыкта булган. Шагыйрь юбилее уңаеннан, 2016 елны Яңа Кырлайда әдәби-скульптуралы парк ачылган иде, шунда Сәгъди абзый һәм кечкенә Тукай сыннарын, ул язган әкият персонажларын металлдан ясауга үз өлешемне керттем», – ди Ренат. Ул башкарган игелекле эшләрнең кайберләре Казанның борынгы архитектурасын тернәкләндерү белән дә бәйле. «Том Сойер Фест» проекты кысаларында борынгы агач йортларның тимер бизәкләрен, кәрнизләрен реставрацияләү эшләрендә дә катнаша ул. «Туган шәһәремнең борынгы тарихы өчен ут янам, бу идеяне хуплаучы дусларым да бар. Казанның тарихи йөзен саклап калырга тырышучы команда составында мин. Һөнәри тимерчеләр өчен бу – вөҗдан сүзе. Миңа, тимерчеләр нәселе вәкиле буларак, Казанның үз тарихи архитектурасы һәм аның күркәм йөзе саклану мөһим!» «Казан буйлап йөргәндә, үз хезмәтләремне оныкларыма гына түгел, оныкчыкларыма да күрсәтергә насыйп булсын», – ди тимерче оста.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Көндәлек тормышында һәр кеше үзен бар яктан да камил дип уйлый. Мәгълүмат чаралары, төрледән-төрле китаплар рус һәм европалыларны башка халыкларга, бигрәк тә христиан динендә булмаганнарга караганда өстен итеп тасвирлый. Мәсәлән, Африка, Азия халыкларын икенче сортлы итеп сурәтлиләр. Күп вакыт кухня сөйләшүләрендә «черномазый», «чурка»дан ары китеш юк. Ләкин берәр халыкның тарихы, көнкүреше, аның гореф-гадәтләре белән таныша башласаң, үзең өчен кызыклы хәлләргә тап буласың.

ӘФГАН

Миңа үткән гасырның 70-80 нче елларында берничә тапкыр Урта Азиядә, ә 1981-1983 елларда Әфганстанда булырга туры килде. Анда Урта Азия халыкларының көнкүрешен, комлы далаларда җир эшкәртеп җиләк-җимеш, иген үстерүләрен, терлек асрауларын, авыр табигать шартларына да җайлашып, тулы тормыш белән яшәргә омтылуларын күрдем. Әфган дәүләте халыкларының нинди милләттән булуына карамастан, искитмәле хезмәт сөючән халык икәненә гаҗәпләндем. Һәр атна булып торган ком бураны астында, далада һәм ком чүлендә, текә таулардан агып килә торган кечкенә елга суларын максималь рәвештә барлык җир кишәрлекләренә җиткерерлек итеп файдалана белү – үзе бер могҗиза! Шулай ук үзләренең йорт-җирләрен кышкы 20 градуслы салкыннарда да, җәйге 60 градуслы эсседә дә яшәрлек итеп оештыра белү, ком чүлләрендә 40 метр тирәнлектә коелар казып су табу, шулай ук аларның эшчән, тәвәккәл халык икәнен күрсәтә. Һәм бу барлык эшләр дә фәкать кул көче белән генә эшләнелә. Сүз уңаеннан әйтеп үтү кирәк, XVIII гасыр уртасына кадәр Әфганстан дәүләте хәзерге Төркмәнстан, Үзбәкстан, Таҗикстан җирләренә дә җәелгән булган. Әле бу «ачышлар» халыкның яшәешендәге тышкы күренешләре генә. Аны әчке яктан да белер әчен бик күп кеше белән аралашырга, сораштырырга, бик дикъкать белән кызыксынырга кирәк. Тарихтан белүебезчә, бу җирләрдә шагыйрь һәм галим, философ, күренекле табиб Ибн-Сина (Авиценна) яшәгән. Аның медицина өлкәсендәге хезмәтләре егерменче йөз башына кадәр бар дөнья табибләре өчен төп чыганак булып хезмәт итте. Бу җирләрдә үзенең кабатланмас шигырьләрен Фирдәүси иҗат иткән. Ул әле хәзер дә дөньякүләм шагыйрьләр рәтендә хөрмәтле урын били. Безнең өчен, татар милләте өчен әһәмиятлесе – Әфганстанның Газни шәһәрендә якташыбыз Хуҗа Әхмәт Болгари Әфган дәүләтенең солтаны Мәхмүд Газниның шәхси табибе вазифасында хезмәт итеп, болгар-татар халкын бар дөньяга таныткан. Бу хәл Хуҗа Әхмәт Болгариның үз заманында даны еракларга таралган галим икәнен дәлилли. 1971 елда бу бөек галимнең зиратына мавзолей төзелде. Безгә ул «Болгар тарихы», «Болгарда фән», «Болгарда философия» хезмәтләрен язып калдырган.

● Калаш гаиләсе.

Мин үзем Талукан шәһәреннән Файзобад шәһәренә барганда ак йөзле, бераз сипкелле, кызгылт-сары чәчле яшь әфган солдатын очраттым. Аптырап аның нинди милләттән булуын сорагач, янәшәдәге иптәшләре: «Аның этисе москаль!» - дип бармак төртеп көлеште (Күп җирләрдә русларны «москаль» дип атыйлар). Ә, ул миңа үзенең халкын Искәндәр патша армиясеннән калган дип аңлатты. Урта Азия җирләрендә ак тәнле кешеләр сирәк очрый. Хәтта мин Кондыз шәһәрендә очраткан, 1930 елларда СССРдан качып киткән рус милләте кешесе дә урамда очраган башка әфганлылардан аерылмый иде. (Ул үзләренең Рязань өлкәсеннән, НКВД эзәрлекләвеннән качып килүләрен генә сөйли алды, аннары намазга ашыкты). Бик күп кеше белән аралашкач, мин мондый ак тәнле «москаль»ләрнең Әфганстанның төньяк-көнчыгыш өлешендә яшәвен ачыкладым. Кайчандыр бу өлкәне Кәферстан, Нуристан җирләре дип атаганнар. Аларны икенче төрле калашлар дип тә атыйлар икән. Калашлар биек Гиндукуш таулары арасында, Читрол елгасы ярлары буендагы Кунар провинциясендә, Гиндукуш тавының көньягында яши. Аларны ак тәнле әфганлы дип атыйлар. Туган телләре һинд-иран төркеменә керә торган дар группасы. Хәзер бу төркемдә 6 меңләп кеше исәпләнә икән. Калашлар мондагы халыклар белән бергә ислам динен XIX гасырда гына кабул иткән. Шул ук вакытта үзләренең гореф-гадәтләрен дә саклап калганнар. Шул традицияләрнең берничәсен укучыларга җиткерәм:

Балалар. Бала туарга ярты ел алдан, булачак әти кешене «декрет» отпускасына җибәрәләр. Кәферстан борынгы ефәк юлы өстенә урнашкан. Монда яшәүче халык нигездә юлаучыларны, сәүдәгәрләрне саклап-озатып яшәгән, һәм шул кәсеп күп вакыт аларның яшәү чыганагы булып торган. Булачак этиләрне ерак юлларга, сугышларга алмаганнар. Бу вакытта ул хатынына өй эшләрендә ярдәм иткән. Хатынының әле корсагындагы булачак баласына төрле тарихи вакыйгалар, әкиятләр һәм гаиләсенең традицияләрен сөйләгән. Туачак баланы өйдә бик яратып көтүләрен, аның гаиләдә яхшы ярдәмче булып үсүен теләүләрен сөйләгән. Әлбәттә, бала сау-сәламәт булып туган. Үскәндә, ата-ана сүзен тыңлаучы булып тәрбияләнгән. Сүз дә юк, аның анасы баласы карынында чагында моның этисе кайларда йөри икән, исән-саумы икән дигән уйлардан азат булган. Бала ана карынында һәр көн үз этисенең тавышын ишетеп, үз милләтенең җыр-моңнарын, тарихын һәм гореф-гадәтләрен тыңлап, аларның тәэсирен тоеп үскән. Гаиләдә бер-берене массаж ясау белән шөгыльләнәләр. Һәр көн диярлек, дөресрәге, һәр кичтә хатыны – иренә, ире – хатынына. Шуның нәтиҗәсендә хатыннарда инфаркт, инсульт, целлюлит, ә ирләрдә простатит һәм тагын башка күп авырулар арткы срокка чигерелә. Ә безнең гаиләләр массажның ни икәнен дә белми, гаиләдә моны эшләми дә. Бу нәтиҗәсе бәя бирә алмаслык файдалы эшкә альтернатива юк бит!

Бу кабиләдә балаларны укыту һәм тәрбияләү Тай-Дао уку системасы нигезендә алып барыла. Максат гади генә: массажга өйрәнү, хәрби сәнгать (ир һәм кыз балалар бер дәрәҗәдә), һәм сәламәтләндерү системасы. Безнең өчен бигрәк тә сәламәтләндерү системасы кызыклы (бу системаны һәм гаилә массажын куллану нәтиҗәсендә уртача тормыш озынлыгы бу кабиләләрдә күршедәгеләргә караганда ике тапкыр озынрак).

Бу – Ике күк йөзе дигән традицион система. Аны гадирәк итеп болайрак аңларга кирәктер: «Ышанычлы юл бер генә түгел». Бу юл төрле вариантларда киң кулланыла.

Беренче сукмак маймыл сукмагы диеп атала. Аның төп эчтәлеге- хәрәкәт, гимнастика, иртәнге физкультура, физик хезмәт



● Таулар арасындагы калаш авылы.

ХАЛЫК СЕРЛӘРЕ

(эшлексезләр арасында озын гомерләләр булмый). Берәр сәгатьлек «утырып» эшләүчегә эштән соң аз гына хәрәкәтләнеп алу.

Икенче сукмак – Кыя-Таш арасындагы сукмак. Бу хәрәкәтсез предметлар белән эшләү. Статик гимнастика, сеңерләрне һәм веналарны ныгыту. Бу вакытта сулыш алуны тикшереп торырга кирәк.

Өченче сукмак – Камыш сукмагы. Аның нигезен умыртка баганасының тартылу сәләтен тәэмин итүче күнегүләре тәшкил итә. Йөзү, төрлечә асылынып тору. Өйдә перекладина булмаса, үзеңне йокыдан уянгач та ләззәтләнеп киерелеп алырга өйрәтү. Бу күнелле дә һәм файдалы да. Һәм һәр иртәне һичшиксез, елмаюдан башларга, Камыш һәр иртәне кояшка карап елмаюдан башлый (тормыш оптимистлыгы).

Дүртенче сукмак – Лиана сукмагы. Сыгылучанлыкка күнегүләр. Төрле ясcылыктагы борылышлар. Бер үк вакытта чүмәшеп алу да.

Бишенче сукмак – Юлчы сукмагы. Һәр көнне 2-3 километр җәяү йөрергә киңәш ителә. Күңелләргә якын урыннар, матур табигать, бер яктан саф һава күңелне тынычландырса, икенче яктан, җәяү йөрү ир кешедә простатиттан, хатын кызларда бик күп авырулардан профилактик чара була.

Алтынчы сукмак – Ай сукмагы. Сез биергә тиеш. Атнага ике тапкыр булса да. Мөмкин өйдә, яисә ялгыз гына, күңелең тарткан җирдә. Биюнең төрле ысуллары бар. Бигрәк тә партнер белән күңеллерәк.

Җиденче сукмак – Кояш сукмагы. Кояш сезнең тәрәзәгә генә кереп чыкмый ич. Сезнең дусларыгызныкына да карап сөендерә. Сез дә шуңа күрә аларга кунакка кергәләп чыгыгыз. Сез анда шул ук ашамлыкларны ашарсыз, ләкин башкача пешерелгәнне. Кайчак, сез үзегездә бөтенләй ашамаган ашамлыклар ашарсыз. Бу сезнең ашамлыклар аша керә торган микроэлементлар диапазонын киңәйтер. Бу үз чиратында сездә өстәмә чыдамлыгыгызны арттырыр. Сезнең һәм дусларыгызның күңелен күтәрер.

Сигезенче сукмак – Ләкләк (Аист) сукмагы. Үзеңнең сөяркәләрең белән очрашырга. Алар белән мәхәббәт белән шөгыльләнергә (бу чагында массаж ясау осталыгы да ярап куяр).

Тугызынчы сукмак – Дракон сукмагы. Драконның 3 башы: яктылык, су һәм һава. Алар сезнең юлдашларыгыз булырга тиеш. Мөмкин кадәр күбрәк саф һавада булырга тырышыгыз. Онытмагыз, кешегә һичшиксез кояш яктысы кирәк. Ешрак су янәшәсендә булыгыз. Ванна керергә, душта юынырга, кулларны юарга яисә су агымына карап сокланып торырга мөмкин. Иртәнге чәй савытыгыз кечкенә генә күлгә әйләнсен. Бу күлдә сез ай яки йолдызлар чагылышын күрмәссез. Әмма бу күл суының өске тынычлыгын тәэмин итә аласыз. Үзеңә генә тынычланырга кирәк. Һәм үзеңә дөрес итеп суларга гына кирәк.

Калашлар үзләренең борынгыдан килгән диннәрен саклап, төзек итеп иҗатлап күршеләрдән бар яхшы нәрсәләрне куша белгән. Алар Будданы, Гайсәне, Мөхәммәд пәйгамбәрне үзләренең борынгыдан килгән аллалары белән бертигез күрә. Бәлкем, бу юл аларны берәр динне инкяр итүчеләр келәймәсеннән азат иткәндер. Һәм аларга дөньяга бәя бирү (мироздание) чиген киңәйткәндер. Барлык яшәү дәверендә калашлар беркемне дә үзләренең дин юлына көчләп ышанырга мәҗбүр итмәгән. Кояш, һава, җир һәм аллалар барысына да җитәрлек дип санаганнар (Рәсәй кенәзлегендәгечә вәхшиләрчә көчләп чукындырып, христиан динен, православиене башка халыкларга такмаганнар). Гади генә яшәргә, яратырга һәм иҗат итәргә чакырганнар. Моның өчен башка халыкларның җирләрен яулап, халыкларын җәберләп, үтереп яшәргә кирәк түгел…

Бәлкем бу куркаклыктыр? Нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. Калашларның ата-бабалары Искәндәр Македонскийның талантлы, куркy белмәс сугышчылары булган. Алар башка беркем булдыра алмаганча сугыша белгән. Ләкин озак еллар башка халыклар арасында яшәп, низагларны хәрби булмаган юллар белән бик зур осталык белән чишәргә өйрәнгәннәр. Ә сирәк кенә, коралсыз чишелә алмый торган бәрелешләрдә аз «кан түгү» юлларын сайлаганнар. Чөнки үзләренең кабиләләренең зур казанышлары итеп байлыкны, җирне түгел, ә, кабиләдәшләренең гомерләрен санаганнар.

Иң кызыклысы – бу кабилә җәмгыятендә тол хатыннар булмавы. Ирләре үлгән очракта, хатыны 40 көнне кайгырып үткәрә. Аннан соң ярты ел вакыт эчендә янә үзенең теләсә кайсы кабиләдәшенә кияүгә чыга ала. Бу вакыт эчендә үзенең кулына һәм йөрәгенә тиңдәш дәгъвачы тапмаса, үлгән иренең өлкән туганының хатыны була. Ул аның балаларын да үзенең уллары итеп таный. Шундый традиция хөкем сөргәнгә, кабиләдә тол хатыннар гына түгел, караучысыз балалар да юк. Калашларның яраткан аллаларының берсе - Мәхәббәт алиһәсе. Телевизор, интернет булмаган заманнарда озын кичләрне бу алиһәгә табынып үткәрмичә, тагын ни эшләргә кала? Ире традиция буенча хатынына массаж ясый. Аннары яраткан иренә хатыны. Массаж мәхәббәт уенына әверелеп китә… Бу вакытта, калашлар ышануы буенча, организм эшләп чыгарган «нечкә» энергияне гамәлгә ашыру кирәк була. Бүтәнчә әйткәндә, бу «эштән» соң хатыны, иренең күлмәген киеп, кичке аш әзерләргә тотына (бездә дә кайбер кыз-хатыннар ирләренең күлмәкләрен киеп йөрергә ярата). Калашларның хатыннары шулай үзләренең сөекле рухи-яклаучы ирләренең тәэсирен үзләрендә сакланып калуына ышанган. Моны икенче төрле гади генә аңлатып була. Ир кешенең күлмәгенә сеңгән тиреннән хатыны иммунный системаны ныгытучы микродоза матдә ала. Бу халыкта мондый күренешләр гадәти хәл итеп саналган. Алар күп гасырлар дәвамында авыруларны дәвалау алымнарын һәм аның профилактика ысулларын җыеп, саклап килгән.

Хатыны кичке аш әзерләгән арада ире каллиграфия, агачка яки сөяккә бизәк ясау белән шөгыльләнгән, картиналар, кечерәк кенә өй тимерчелегендә вак-төяк әйберләр ясаган. Чамалавы авыр түгел, мәхәббәт алласының канат тәэсирендә һәм шул «нечкә» энергия тәэсирендә булу сәбәпле хатыннарның кичке ашлары тәмлерәк була. Ир кешенең ясаган әйберләре аеруча гүзәл әсәрләргә әверелә…

Сер түгел, башка бик күп Азия халыкларындагы кебек калашларның да ирләре еш кына кичке ашны үзләре әзерли. Ә, хатыннары ул чакта шигырьләр укый, яза, рәсем сәнгате белән мавыга, тимерчелектә шөгыльләнә…Монда искитәрлек берни дә юк. Мәгълүм хәл: кайбер ашларны, ашамлыкларны ир-атлар хатын-кызлардан да остарак әзерли. Шуның өстенә болар барысы да мәхәббәт уеннарының бер өлеше булып тора. Ә калаш халкы мондый уеннардан башка, дөнья беркатлы, ямансу дип ышанган…

Күп кенә сәяхәтчеләр, галимнәр бу халыкка күбесенчә нәфрәт һәм кара көнләшү белән карый. Ни өчен? Ә суздә нинди мөнәсәбәт туар иде, әгәр дә кичке аштан соң ир белән хатын янә дә яңа баштан мәхәббәт белән шөгыльләнә башлавын белсәгез? Калаш халкы «икенче кат» мәхәббәт белән шөгыльләнү аларның яшәү мөмкинлекләрен киңәйтә, сәламәтлекләрен ныгытуга инанган. Аларда бу хәлләрнең барысы да гади «көндәлек» хәл саналган. Һәр елның ике көнен алар мәхәббәт алиһәсенә багышлаганнар. (Күз алдына китерүе дә кыен, әгәр дә безнең илдәгечә аларда елына 112 көн ял көне булса. Һәм шул көннәрнең ике көнен мәхәббәт алиһәсенә бүлсәләр?!) Бу көннәрдә бергәләшеп күңелләренә якын урыннарга сәяхәт кылганнар, дусларына, туганнарына кунакка барганнар, балалары белән мәш килгәннәр, бер-берсенә бүләкләр бирешкәннәр. Бу көннәрдә йөртта чәчәк күп булган, шәмнәр, тәмле ис чыгарып торучы таяклар янып торган. Бу вакытларны алар бер-берләренә багышлаган…

Бу халыкның тормышын, гадәтләрен өйрәнә башлагач, мин бәхетнең, гомер яменең һәрчак үзебезнең кулларда булуына инандым. Безгә дәүләттән кайчандыр бәхет килеп ирешүен көтеп яшәмәскә, ә һәр көн үзебез, адым саен аңа якынаерга кирәклегенә ышандым. Якыннарыбыз, туганнарыбыз, балаларыбыз өчен тырышып, намуслы эшләп, хезмәт итеп яшәү һәркемгә кәнәгатьләнү һәм ахыр чиктә күңел тынычлыгы, бәхет китерә. Һәр гаиләдә милли гореф-гадәтләр нигезендә, бер-берене аңларга тырышып яшәргә кирәк. Бәхетле һәм сәламәт булу серләре үзебезнең кулларда.

Расих ҖӘЛӘЛ.
Казан.

● **Калаш кызлары.**

Талант язмышы

Вахит ИМАМОВ

(Ахыры. Башы 5 нче санда).

Ә ул ун көннең берсендә диярлек туган якларына йә кунакка, йә безгә практикага кайтып торган Казан студентлары Вәзыйх Фатыйхов (хәзер үзе инде бер дистә шигъри җыентык авторы, Союз әгъзасы һәм, иң мөһиме, без калдырып киткән район газетасының баш мөхәррире!), Дамир Бәдриев (республиканың күренекле журналисты, дистәләгән хикәя авторы), Зөфәр Җамалиев (хәзер үзе район газетасында эшли), янәдән бер Рашат Мифтахов (без аны «номер ике» дип йөрттек, Тегермәнлек авылыннан, журналист, хәзер район хакимиятендә эшли), һәм инде Балык Бистәсе – ул күренекле Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Вакыйф Нуруллин, Әхәт Гаффар, Равил Шәрәфи, Хәлим Җәлял туган як та бит әле. Казан кул сузымында гына.

Алар да әледән-әле кунакка кайтып тора, район редакциясенә керми китми, сирәк кенә булса да (юмартланып!) бер-ике әсәрен район газетасына калдырып китә...

Кадыйр абыйның фатирында әле хуҗаның, әле Ниязның яңа шигырьләр тәлгәшен тыңлап утырабыз да атна буе диярлек күрешә алмыйбыз. Безне кызыксындыру өчен редакторыбыз аена ун (!) сумлык махсус приз да булдырды. Һәр көнне берәр авылга чыгып китәбез, башкаларны көнләштерерлек мәкаләләр, зарисовка, очерк, репортаж, интервьюлар әзерлибез. Язмаларны редактор ишегенә кыстырып китәбез. Нәтиҗәсе шул: кырык ике мең кеше яшәгән районда газетаның ике телдәге тиражы бермәлне уники меңгә житте. Ышанып әйтә алам: ул заманда республикада безнең район газетасы белән тиңләшерлек башка газета юк иде!

Сүзсез дә аңлашыладыр, әлбәттә инде, безнең әйдәүчебез дә, остазыбыз да, җиңүчебез дә Кадыйр абый булды (Редактор оештырган «ярыш»та өстәмә ун тәңкәне Кадыйр абый дүрт ай буе эләктереп барды да, хуҗабыз ул призны яңадан «аллаһәппәр» итте.). Ә Кадыйр абый яза белә иде! Андагы хис, сүз тәмен тою, йөгерек тел, дөньядагы иң катлаулы төеннәрне дә чишеп бирә белә иде.

...Биектау дигән авылда микән инде, комсомолка кызлар ындыр табагына төнге сменага эшкә чыгудан баш тарткан. «Безгә ипи кирәк түгел, без ипи ашамыйбыз. Без сушки гына кимерәбез». Комсомол райкомының беренче секретаре Кадыйр абыйның иярткән дә шунда чыгып киткән. Икенче көнне район газетасында сугыш еллары ачлыгына (Кадыйр абыйның балачагы инде дөресе), әхлак темасына багышланган искиткеч мәкалә дөнья күрә. Өченче көнне, кисәтми-нитми, «Татарстан яшьләре» язманы күчереп баса.

...Тегермәнлек авылында егерме бер ел буе бер үк «Газ-51» машинасын йөртүче, үзе инде алтмыш дүрт яшькә житкән бер абзый (бабай дияргә тел бармый) бар иде. Аның турында, әлбәттә, элеккерәк елларда да газетада төрле информацияләр чыкты. Ләкин менә, абзый бәхетенә, беркөнне аның кабинасына Кадыйр абзыебыз утырып кайткан һәм нәтиҗәсе... шоферның эчке дөньясы турында гүзәл зарисовка. Кулны йөрәккә куеп әйтәм: минем хәтта бөтенсоюз газеталарында да гади шофер турында моңа тиң торырдай язма укыганым булмады...

Кадыйр абыйның публицистик хезмәтләрен бүгенге журналистика факультеты студентларына укытсаң, файдасы искиткеч булыр иде.

Ә аның балалар өчен нәни-нәни генә көлкеле хикәяләр, шигырьләр иҗат итүен, йә, кем белә? Бүген «Төчкертек хикәяләр» дигән булып, «йөремсәк мәзәкләр» дигән булып, ничаклы хлам, бер мәгънәсез, тузга язмаган, надан язмалар газета битләреннән бичара укучылар өстенә түгелә, әһ, андый мескен каләм ияләренә Балык Бистәсе газетасындагы Кадыйр абый әсәрләрен укытасы иде!..

Ә аннары... бәхетсез язмышы, бер дә җайсыз холкы-табигате аркасында җирле хакимият җитәкчеләре белән конфликтка керде дә җитмеш сигезенче елның октябрендә Чаллы каласына күченеп китте ул (әйберләрен үзем күчерештем). Һәм Кадыйр абый капылт кына сынды. Үзе дә, иҗаты да. Килмешәкләр белән тулган әхлаксыз шәһәр, куян тартмалары сыман ямьсез, салкын, кысан фатирлар, коргаксытылган, юкка чыгарылган табигать - һәммәсе изде, сытты аны. Чөнки ул туфрагыннан йолкып алынган гөл хәлендә калды. Кадыйр абыйның кулларына гына түгел, күңеленә, рухына да тышау салынды. Ничәмә-ничә еллар буена рәхәтләнеп иҗат итә алмады ул. Җанына, иҗатына рухи азык эзләп Кавказларга, Кырымнарга китеп барды. Мондый торгынлыктан Кадыйр абый фәкать сиксәненче еллар ахырында гына савыкты һәм милләт язмышы турындагы шигырьләре белән безне янә сокландырды. Ул кабат шигъри аргамагының иярендә иде.

Кадыйр абый әдәбиятта ничәмә-ничә әдипнең остазы, укытучысы булды икән? Әле генә «торгынлык еллары» дип телгә алган идем. Әйе, иҗатында торгынлык. Ә тормышта, әдәби хәрәкәттә? Сиксәненче еллар Чаллыдагы «Ләйсән» әдәби берләшмәсенең гөрләп торган вакыты иде. Балык Бистәсеннән килгән Кадыйр абый Чаллыдагы бөтен әдәби дөнья, әдәби хәрәкәтнең әйдәп баручысына әйләнде.

Кадыйр абый күпләгән язучыларга канат куйды, аларны олы юлга чыгарды. Мәрхүмнәр: Марсель Гыймазетдинов, Мөхәммәт Шәйхи, Хәниф Хөснуллин, Фазыл Шәех, Шамил Шәйдуллин, Мизхәт Хәбибуллин, Альберт Сафин, Газиз Кашапов... Аларның һәммәсе дә Кадыйр абыйның кырыс мәктәбен узды һәм, белмим, Кадыйр абый ярдәм итмәсә, көч бирмәсә, аларның исемнәре әдәбиятта сакланып калган булыр иде микән?..

Ә исәннәр, бүген инде үзләре зур исем алган каләм ияләре: Данис Хәйруллин, Факил Сафин, Равил Вәли, Мансур Сафин, Мирһади Разов, Нияз Вәли... Бәлки, җитеп торыр? Йә, бүген татар әдәбиятында үзен «йолдыз» дип санаучы кайсы шагыйрь шушы кадәр укучысы, өйрәнчеге белән мактана ала икән?..

Дөрес, Кадыйр абый тарафыннан читкә тибелгән графоманнар да аз булмады. Кадыйр абый туры сүзле талант иде, «шигырь» калыплап йөргән бушбугазларны җене сөймәде. Казанга барып та дәрәҗәле газет-журналларда әдәбият-сәнгать үсеше өчен җавап тоткан «погонлы» абзыйлар белән якалашып-ызгышып кайта иде. «Шигъриятне фәлән ел буена фәлән кеше генә очсызлатып бетерде», дип ачынып сөйли иде аннары. Шуңа сөймәделәр. Шулар аңа бик еш кына капкаларны бикләде, шулар аның турында төрле гайбәт түкте. Шулар «тырышлыгы» белән олуг әдип Кадыйр абый, шәхсән Хәсән Туфан аның иҗатына мөкиббән киткән Кадыйр абый, үзенең шигырьләрен Казанда «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыгара алмады. Кадыйр Сибгатуллин дигән олы шагыйрь бу җиһаннан бер генә мактаулы исем, бер генә премия һәм дәрәҗә дә алмый (ала алмый) китеп барды.

Казанга баргач, очрашкач, озын-озак еллар буена әдәбиятта Кадыйр абый белән иңгә-иң торып, үзара дус булып яшәгән Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗан, тагын әллә никадәрле күренекле әдипләр белән сөйләшкәнем бар.

– Кадыйр абыйның иҗаты Габдулла Тукай премиясенә лаек идеме? -дим.

– Лаек иде, – диләр. Берәү дә «юк» дими. Шулай инде, бөек Тукай әйтмешли: «Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү?! Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!» Юк инде, юк...

Башка әдипләрнең юбилейларына саллы-саллы китаплары басылып тора. Кадыйр абыйның фани дөньяга күчүенә дә утыз ел тула. Мирасы бай. Моңа кадәр дөнья күрмәгән шигырьләре генә дә йөздән артык. Ә Казан нәшриятлары Кадыйр абыйның мирасын дөньяга чыгару өчен бармакка-бармак та сукмады.

Татар әдәбиятында иң яраткан язучыларымның һәм остазларымның берсе Мөхәммәт Мәһдиев иде, шулай булып калды һәм калачак. Ә ул кая гына бармасын, куен кесәсендә фәкать Кадыйр Сибгатуллинның шигырьләрен генә йөртә иде. Һәм кайсы гына, нинди генә аудитория алдында чыгыш ясамасын, яшьле күзләре белән, иң элек Кадыйр абый шигырьләрен укый иде. Ә Мөхәммәт абыйдагы чын, асыл шигъриятькә сизгерлек, гомумән, бүген тагын кемдә дә булса бар микән ул?.. Димәк, һәр сәгатьтә, һәр минутта сагынган ул аны.

Мин дә сагынам.

2002 ел.

Басма Коръән тарихы

Россиядә беренче мәртәбә Коръән кайчан һәм кайда басылган? Бу сорауга Р.Фәхретдин җавап биргән.

Матбугат галәме белән таныш булган акыл ияләренең хәбәрләренә караганда, Коръән Шәриф беренче мәртәбә Алмания дәүләтендә Гамбург шәһәрендә басылган. Соңрак Италиядә һәм аннан соң башкала булган зур шәһәрләрдә, Франциядә күп тапкыр, һәм һәр мәртәбәсендә күп нөсхәләр нәшер ителгән. Һиҗри уночечнче гасырда Россиядә Петербургта һәм соңра Казанда да басылган.

Риваятьләргә караганда, Петербург каласында дөнья күргән Коръән Шәриф олуг Екатерина фәрманы һәм дәүләт акчасы белән басылган икән. Петербургта беренче мәртәбә басылган Коръән Шәриф нөсхәләре сирәк калса да, халык арасында һаман күренә.

Ориенталистлар тарафыннан нәшер ителгән нөсхәләрдән без күргән әсәр милади 1870 елда Флюгель тарафыннан Лейпциг шәһәрендә дөнья күргән Коръән Шәриф иде. Ләкин бу зат моннан элегрәк милади 1842, 1843 елларда ике тапкыр нәшер иткән. Без күргән нөсхәнең исә кәгазе югары сыйфатлы, хәрефләре һәм карасы гүзәл булуы белән игътибарга лаек.

Иске басмалар хакында бер таблица

Бу таблицадан элек басылган Коръән Шәрифләрнең басылган еллары һәм шәһәрләре мәгълүм булыр:

1649 – Гамбург
1668 – Италия (ике олы том)
1698 – Италия
1787 – Петербург
1790 – Петербург
1798 – Петербург
1801 – Казан
1803 – Казан
1819 – Казан
1839 – Казан
1834 – Лейпциг
1842 – Лейпциг
1870 – Лейпциг
1856 – Казан


قرآن طباعت
صاحبی
(رضاء الدين بن فخر الدين)
— اوفا —
КАЗАНЬ

— ٦ —
٦
ایسکی باسمه‌لر حقنده بر جدول
١٦٤٩ (هامبورغ)
١٦٦٨ (اطاليا)
١٦٩٨
١٧٨٧ (پطربورغ)
١٧٩٠
١٧٩٨
١٨٠١ (قزان)
١٨٠٣
١٨١٩
١٨٣٩
١٨٣٤ (ليپسيغ)
١٨٤٢
١٨٧٠
١٨٥٦ (قزان)
١٢٨٠
١٢٨٣
١٢٩٧ (استانبول)
٧

Һиҗри 1280 – Һиндстанда Мөхәммәд мәхдүм, Мәүләви мәхдүм, Мөхәммәд Габделхафиз редакциясендә.

Һиҗри 1283 – Һиндстан

Һиҗри 1297 – Истанбул Мәгариф министрлыгы рөхсәте белән ташбасма.

Ислам мәмләкәтләрендә һәм мөселманнар тарафыннан Коръән Шәриф бастыру һиҗри уночечнче гасыр ахырында башланган. Югарыда искә алынган өч мәртәбәдән артык Петербургта басылу-басылмавы хакында мәгълүмат булмады.

Р.Фәхретдин, "Коръән вә табагать", Казан, 1900 ел.

Айдар ГАЙНЕТДИНОВ.

Фикер

Бу кирәкме безгә?

Кытай инвесторы Татарстан территориясендә гаять зур, бер тәүлектә 500 тонна сөт эшкәртү комплексын төзү эшләре башлаячак. Терлек асрау һәм ит эшкәртү комплексы белән, үзенең куәтле лабораторияләре дә булачак икән. Бу эшләр уйланылган проект буенча, Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән килештерелеп, 2024 елда комплексны эшләтеп җибәрү каралган.

Бер тәүлектә 500 тонна сөт савып алыр өчен, 50-60 мең баш сыер асрау кирәк була бугай. Бу кадәр күп сыер хайванын ашату өчен икмәк, терлек азыгы һәм аны үстерү өчен гаять зур күләмдә басу-кырлар кирәк. Ерак Көнчыгыш һәм Чуашиядә Кытайларга файдаланырга бирелгән җирләрдә, яман технологияләр кулланылып, көчле химикатлар кертелгән җирләрнең иген үстерергә сәләтсез булып калулары турында язып та торалар.

Кытай инвесторының Татарстан җиренә күпме срок белән килүе турында мәгълүмат юк. Димәк, алар китәргә дип килми булып чыга. Алар сауган сөтне порошокка әйләндереп, тулысы белән Кытайның Чэнду шәһәренә поезд белән озатылачагы турында әйтелгән.

Безгә моннан берәр төрле файда булачакмы, әллә безгә шакшысы гына калачакмы? 100 кешегә эш урыны булып кына проблема чишелә дигән сүз түгел, ә салымы безгә булмыйча, кая киткәнен беләбез.

Тора-бара алар хуҗа булып, Кытайдагы уйгур мөселманнарын җәберләгән кебек, безгә дә тотынмаслармы дип ышана алабызмы? Үзебезнең фермерларга кирәк кадәр булышып, үз җирләребез үзебезнеке булып калса ярамый микәнни? Үз җиреңне читләргә бирү-илеңне сату, үзең мескен кеше хәлендә калу була бит ул. Моның бәлки, кемнәргәдер файдасы бардыр, халыкка кирәкле эш түгел бу. Кытайның күршесендә генә булган урыннарда никадәр җирләр эшкәртелми ята бит, андагы җирләрне бирергә ярамый микәнни? Безнең халык үзе дә кытайлардан ким түгел, эш сөючән халык, үз җирен үзе эшкәртә алмый мәллә?

Агулы сәясәт

Татарстан хөкүмәте җитәкчелеге тарафыннан, барлык авылларда махсус аракы сату кибетләре булдырып, бюджетны баетуга багышланган сүзләрне укыгач, аптырап калмаслык түгел. Ул авылларның күбесе болай да юкка чыгарга торалар бит? Халыкка кирәкле булган мәктәп, балалар бакчалары, мәдәният, элемтә бүлекләренең эше туктатылып, ашау-эчү ризыклары алырга кибетләре дә булмаган авылларда, аракы сату кибете булдырып, халыкны эчүчелеккә өндәү гамәлләре ахмаклык түгелме? Эчүчелектән айнып яши башлаган халык өчен сөенәсе урында, хөкүмәт җитәкчеләре өчен алар "бәла" булып күренә башлаган түгелме? Минем фаразлавым буенча, Советлар иле таркалмаган булса, халыкның күпчелеге исереклеккә чыгу халәтендә иде. Бигрәк тә авыл җирендә, нәрсәдер эшләткән өчен, аракы белән ризалату гадәткә әйләнде. Ике механизатор үзара сөйләшкәндә, берсе эшләгән эше өчен шешә белән түгел, кәгазь (акча) белән түләүгә риза булмавы турында әйткән иде. Ул кәгазь дигәннәренә, кибеттән алырга аракы булмаган вакытлар да булып алды бит.

Безнең авылның үзендә (Саба районы, Пүкәл) махсус аракы сату кибете булса да, авылда исерекләр дә, кешегә кереп соранып йөрүчеләр дә калмады хәзер. Казанда үзебез яшәгән тирәдә һәм шәһәр урамнары буйлап йөргәндә дә, исерек кеше күргәнем юк дисәм дә була. Хәзерге вакытта, туй һәм юбилей мәҗлесләрен дә спиртлы эчемлекләрсез генә үткәрүләр башланды. Үзебезнең оныкның туй мәҗлесен дә шулай гына үткәреп җибәрдек. Спиртлы эчемлекләр булмаса да бик тыныч, күңелле узды.

Аракы сатудан кергән керем кимүгә карамастан, халык аек баш белән яшәве өчен сөенергә генә кирәк бит. Аракыдан башка да, безне юкка чыгарырга теләүчеләрнең кыланмышларын күреп торабыз. Хет безнең милләттәш җитәкчеләр генә булса да, үзебезне бетерү өчен түгел, милләт сакланып калсын өчен тырышлык күрсәтсен иде. Ул хәрам сатудан кергән акча үзебездә калса бер хәл, аның кая киткәнен беләбез.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.

Айга карамаА кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

19 февраль (шимбә). ***Рәҗәб аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 20.16 сәгатьтә калка, 8.25 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.57 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

Чабыр - шифалы үлән

Цистит һәм холецистит булганда, 1 аш кашыгы вакланган чабыр (тимьян) үләнен термостагы 1 стакан кайнар суда 2 сәгать төнәтәләр. Сөзеп, көненә 3-4 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 50 шәр г эчәләр. Салкын тигәндә, 1 аш кашыгы вакланган үләнне 1 стакан кайнар суда ярты сәгать төнәтәләр, сөзеп, көненә 3 тапкыр, ашаганнан соң, 2 аш кашыгы төнәтмәне 1 чәй кашыгы бал белән эчәләр. Бронхит, коклюш, көчле ютәл булганда, өске сулыш юллары ялкынсынганда, 1 аш кашыгы вакланган үләнне 1 стакан кайнар суга салалар, кайнатып чыгаралар, 1 сәгать төнәтеп, сөзәләр, көненә 3 тапкыр, ашаганчы, 1әр аш кашыгы кабалар.

20 февраль (якшәмбе). ***Рәҗәб аеның 19 нчы көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 21.40 сәгатьтә калка, 8.34 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.02 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, эвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Сәламәтлек эликсиры

Анар согын әледән-әле куллану вегетатив-кан тамырлары дистониясе һәм гипертония булганда кан басымын нормальләштерә, стресстан саклый, женси дәртне арттыра. Көн саен 1 стакан анар согы эчү йөрәк авыруларыннан саклый һәм ДНК дәрәҗәсендә картаю процессын әкренәйтә ала.

21 февраль (дүшәмбе). ***Рәҗәб аеның 20 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 23.07 сәгатьтә калка. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.06 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Арыганда, бал аша

Арыганда, хәлсезләнгәндә, 1 әр стакан эрбет (яки әстерхан) чикләвеге һәм карабодайны иттарткычтан чыгаралар да, 1 стакан бал кушып, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр аш кашыгы кабалар. Дәва курсы – 1 ай. Карабодай кан ясалу өчен кирәкле тимергә, чикләвек – файдалы майларга бай, бал исә энергия бирә.

(**Дәвамы 18 нче биттә**).

Айга карама
кырын

22 февраль (сишәмбе). ***Рәҗәб аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Чаян йолдызлыгында, 8.45 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.10 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Кишер мае

Кишерне вак угычтан уып, эмальләнгән кәстрүлгә салалар, өстен капларлык итеп үсемлек мае агызалар, сулы зуррак кәстрүл эченә утыртып, 2 сәгать пешерәләр. Суынгач, өстеннән майны кашык белән банкага тутыралар. Бераздан ул утыра. Чиста майны шешәгә агызып, суыткычта саклыйлар. Ул җәрәхәтләрне бик шәп төзәтә. Эчәргә дә ярый - уникеилле эчәк һәм ашказаны җәрәхәте булганда, ашар алдыннан 1-2 чәй кашыгы эчәргә кирәк.

23 февраль (чәршәмбе). ***Рәҗәб аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 0.37 сәгатьтә калка, 9.00 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.15 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Диетасыз ябыгып буламы?

Була, дип раслый халык медицинасы - кичке 7дән соң ашарга гына ярамый. Кичке 7 белән 8 арасында 1 бүлем сарымсак ашап, 300 грамм кефир эчәргә кирәк. 1 айда шулай итеп 5 килога ябыгып була. Әмма панкреатиттан интекәннәр болай ябыга алмый - аларга сарымсак ашарга ярамый.

24 февраль (пәнҗешәмбе). ***Рәҗәб аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 2.10 сәгатьтә калка, 9.24 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.20 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

25 февраль (җомга). ***Рәҗәб аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмогез йолдызлыгында, 3.39 сәгатьтә калка, 9.56 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.25 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Прәннек торты

1 кг шоколадлы прәннек, 1 л каймак (майлылыгы 25 проценттан ким булмасын), 4-5 банан, 0,5 стакан шикәр, 3-4 аш кашыгы какао кирәк. Каймак, шикәр һәм какаоны миксер белән туглап куертәләр. Прәннекне аркылыга өчкә бүләләр, бананны түгәрәкләп турыйлар. Яссы зур савытка бер катлам прәннек җәеп, буш урыннарны прәннек вагы белән тутыралар. Каймаклы крем сылап, банан катламын җәяләр, аннары тагын крем, прәннек, крем, банан - беткәнче катламлап өяләр. Иң өскә прәннек җәеп, крем сылыйлар, прәннек вагы сибәләр. 1 тәүлеккә суыткычка куялар.

Җәлилче иде ул

Прозаик, шагыйрь, әдәбият галиме Хәнәфи (Канәфи) Габделбәр улы Бәдыйков Арча районының Мөрәле авылында 1941 елда туа. Районның Себер тимер юлы буендагы төбәге халкыбызга Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Тәбриз Мөбәрәков, Гөлчәчәк Галиева, Вакыйф Нуриев, Сания Әхмәтҗанова, Дамир Галимов, Гәүһәр Хәсәнова кебек талантларны биргән. Озак еллар Казан компрессорлар заводын җитәкләгән Әхмәт Мөхетдин улы Галиев тә шушы төбәкнең Сеҗе авылыннан.

Мөрәле зур авыл түгел. Анда башлангыч мәктәп кенә. Шуңа күрә Хәнәфигә аны тәмамлагач, Сеҗе авылында укырга туры килә. Бик тә тырыш, һәрнәрсәгә булдыклы уку алдынгысыннан саналган малай, мәктәпне тәмамлауга ук, Арча педагогика училищесына укырга керә.

Аны уңышлы тәмамлагач, Хәнәфи районның Сикертән сигезьеллык мәктәбенә математика укытучысы итеп җибәрелә. Читтән торып Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Ике ел үтүгә Х.Бәдыйгыйны армия сафларына алалар. Армиядән тормышны өйрәнеп, физик яктан ныгып кайта ул. Укуын университетның көндезге бүлегендә дәвам итәргә дигән фикергә килә. Студент елларында әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнергә керешә.

Университетны тәмамлагач, 1970-1974 елларда Кама Тамагы районында Иске Казиле сигезьеллык мәктәбе директоры, бер ел Олы Карамалы урта мәктәбендә директор урынбасары булып эшли.

1974 елда туган ягы Арчага кайтып, бирәдә чыга торган "Коммунизмга" газетасында хатлар бүлегеген җитәкли. 1975-1979 елларында Урта Пошалым урта мәктәбендә директор булып эшли.

Казан дәүләт университеты аспирантурасында укыганда Х.Бәдигый бөек шагыйребез Муса Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнә. Профессор Вахит Хаков җитәкчелегендә 1982 елда "Муса Җәлил поэзиясенең тел һәм стиль үзенчәлекләре" дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Җәлилне халкыбызга кайтару, аның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә Гази Кашшаф, Хатыйп Госман, Рафаэль Мостафин, Шаһинур Мостафин кебек шәхесләребез зур өлеш керткән. Х.Бәдигый да шулар арасында лаеклы урын тапты.

1994-1996 елларда Хәнәфи Татар милли университетында уку-укыту эшләре буенча проректор булып эшли, тел белеменең төрле тармаклары буенча дәресләр алып бара. 1997-1998 елларда ул "Казан" журналы мөхәррире, 1998-2004 елларда "Мирас" журналында бүлек мөхәррире, баш мөхәррир урынбасары булып эшли.

Матбугатта эшләү белән параллель рәвештә Х.Бәдигый Казан дәүләт педагогика университетында студентларга белем дә бирә. Кыска гына вакыт эчендә зур иҗат юлы үтә. Башта ассистент, аннары доцент, профессор була, декан урынбасары, декан, укыту эшләре буенча проректор вазифаларын башкара.

Соңгы елларда Хәнәфи Казан дәүләт консерваториясендә эшли. Доцент вазифасын башкара, лекцияләр укый, бер үк вакытта әдәби-гыйльми, музыкаль иҗат белән дә шөгыльләнә.

Муса Җәлил премиясе лауреаты булган Х.Бәдигый "Уроки татарского языка. Самоучитель", "Туган тел китабы", әдәби-тәнкыйть мәкаләләре яза, "Абага чәчәге", "Күңел ялкыны" дип исемләнгән шигырьләр, поэмалар җыентыгы, якташы "Востокстройтрансгаз" берләшмәсе генераль директоры, техник фәннәр докторы Тәлгать Шиһабиевка багышланган "Туган җир" повесте һәм башка китаплар дөнья күрә.

2021 елда Хәнәфи Габделбәр улы Бәдыйковның тууына 80 ел тулды. Әмма ул бу датаны билгеләп үткәндә катнаша алмады. 2020 ел ахырында каты авырудан соң арабыздан китеп барды. Хәнәфи туган авылы Мөрәле зиратында җирләнде.

Арча районының үзәк китапханәсендә Х.Бәдигыйның тууына 80 ел тулуга багышлап истәлек кичәсе үткәрелде. Анда юбилярның дуслары, шәкертләре, якташлары җыелды. Кичә Артур Исламов башкаруында Хәнәфинең "Арча ягы" җыры белән тәмамланды.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Тамаша залларына чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

18 февраль – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
19 февраль – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).
20 февраль – Шәрык клубында 14.00 – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). 18.00 – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
22 февраль – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
23 февраль – 12.00 – «Килмешәк» (С.Гаффарова).18.00 – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
24 февраль – Уфа «Нур» театрының «Фатыйма» спектакле (З.Кадыйрова).
25 февраль – Кече сәхнәдә – Уфа «Нур» театрының «Көлмәгез, мин үләм» спектакле (М.Гыйләҗев). Зур сәхнәдә – Уфа «Нур» театрының «Хыял йорты» спектакле (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 гыйнвар – 26 февраль – Ф.Шаляпин исемендәге 40 нчы халыкара опера фестивале:
21,22 февраль – «Сөембикә» (Р.Ахиярова).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

18 февраль – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
19 февраль – «Акча бездә бер букча» (З.Хәким).
20 февраль – «Төш» (Т.Миңнуллин).
22 февраль – «Беренче мәхәббәт» (И.Гали).
23 февраль – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
24 февраль – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
25 февраль – «Өзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

18 февраль – «Яратып туялмадым» (А.Әхмәтгалиева).
19 февраль – 13.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 – «Арыну» (А.Әхмәдиев, Т.Кулов).
20 февраль – «Камыр батыр».
23 февраль – 13.00 – «Асылкош җыры» (Р.Мөхәммәтшин). 18.30 – «Шәй-бу! Шай-бу!» (К.Кәримов).
24 февраль – «Микулай» (М.Гыйләҗев).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

18 февраль – «Аленький цветочек» (С.Аксаков). 19.00 – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
19 февраль – Зур залда – «Царевна-лягушка» (Н.Гернет). Кече залда – «Кәтүкнең сихри төшләре» (Х.Ибраһим, И.Нәфиев).
20 февраль – Фойеда – «Добрый день!» (Н.Егорова). Зур залда – «Солнышко и снежные человечки» (А.Веселов). Кече залда – «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла).
23 февраль – Зур залда – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов). Кече залда – «Самовары» (Р.Таһиров).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

20 февраль – Татарстан Республикасының А.Шутиков җитәкчелегендәге халык музыка уен кораллары дәүләт оркестрының «Снегурочка 2.2» дип исемләнгән концерт программасы.
22 февраль – «Сурганова һәм оркестр» төркеме концерты.
23, 25 февраль – «Спящая красавица» балеты (П.Чайковский).
24 февраль – «Щелкунчик» балеты (П.Чайковский).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

20 февраль – 12.00 – «Конек-горбунок» әкияте һәм ком анимациясе. 15.00 камера залда – Татарстан Республикасы кыллы квартеты башкаруында «Кызыл Армия маршы» дип исемләнгән концерт.
24 февраль – «Волшебный мир фортепианной миниатюры» дип исемләнгән концерт. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе профессоры С.Работкин башкаруында композиторлар Бах, Бетховен, Лист, Шуман, Шопен, Чайковский, Рахманинов, Альбенис, Скрябин музыкасы яңгыраячак.

Калганнарга кала әле дөнья ...

«Кеше китә, җыры кала...» Кала шул. Фәйрүзә Мөслимова үзе китеп баргач, ул язып калдырган җыр һәм шигырьләр дә башкача яңгырый, башкача кабул ителә.

Эзләмәгез мине шигырьләрдән,
Шигырьләрдә генә түгел мин.
Күңелләрем тулып ташкан чакта
Җырга гына килеп түгелмим.
Мин шыбырдап явам яңгыр булып,
Нурлар булып җирне киптерәм.
Дусларыма сөйләп бушанам да
Дәфтәремә шуны төшерәм.
Эзләмәгез шигырь юлларыннан,
Минем генә бары сурәтне.
Тәрәзәдән баккан боек ай да
Үз җырларын миңа өйрәтте.
Башкаларның хәсрәтен дә кичәм,
Үземнеке итеп, көенеп.
Шуңа күрә минем язганнарны
Уйламагыз бары мин диеп.

Шигырьләренең һәрбер юлыннан, беренче чиратта, автор үзе шәйләнә. Кадерле каләмдәшебез Фәйрүзә Мөслимованың 2001 елда нәшер ителгән «Ярату яралары» исемле шигырь китабының аннотациясендә «Хатын-кызның күңел төпкелләре тирәндер. Ул тирәнлекне билгеләүче сизгер үлчәмнәрнең берсе – шигырьдер» дип әйтелгәнчә, Фәйрүзәнең күңелендә кайнаган хисләре иксез-чиксез һәм кайнар иде. Шагыйрә шыбырдап яуган шифалы яңгыр булып та халык күңелен сугарды, нур булып, Туган җире – Актанышны да, Казанны да балкытты.

Сиңа кайттым, туган ягым,
Сиңа кайттым, Актаныш!
Әнә берәү дәшә миңа:
– Исәнме, таныш тавыш!
Еллар үтә, без дә башка.
Тавышлар гына таныш.
Дөнья күпме үзгәртсә дә,
Таны мине, Актаныш!..

Еш кайтты Фәйрүзә Актанышка. Балалар фестивальләренә дә, Гамил Афзал кичәләренә дә, үзенең һәм якташларының иҗат бәйрәмнәренә дә. Актаныш аңа бик кадерле иде. Район үзәгендә аның берничә туганы яши. Алар Фәйрүзәне дүрт күз белән, сагынып көтеп тора һәм аның юлдашларын да күпсенмичә, киң күңеллелек белән кунак итә иде. Китәр көн җитсә, күчтәнәчләрен төяп, туган авылының төп нигезләрендә яшәүче энесе белән киленнәре килеп җитәр иде...

Бертуган энесе Рамилгә багышлап шигырьләр тудырды ул. Журналист буларак та, туган ягына кайтып, үзе укыган Иске Балтач, Иске Кормаш мәктәпләренең бай тарихы, якташы рәссам Зилфәт Басыйров һ.б. турында мәкаләләр язды. Туган җанлы, туган җир җанлы иде Фәйрүзә. Кайтыр иде, шигырендәгечә, өф-өф итеп, мәтрүшкәле чәйләр дә эчеп утырыр иде...

И минем туган ягымның
Кышлары да, җәйләре,
Өф-өф итеп өреп эчкән
Мәтрүшкәле чәйләре.
Үтмәс борын сагындыра
Һәр бәхетле мизгеле.
И Илаһым, үз җиремнән
Мәхрүм итмә Син мине!
(«И туган ягым...»)

Иртәләде шул, балаларын да, туганнарын да, каләмдәшләрен дә өнсез итеп, көтмәгәндә бакыйлыкка күчте. Бу югалтуны күпләр, бик озак онытa алмас...

Кеше киткән саен дөнья бетә,
Калганнарга кала әле дөнья... –
Дип әйтте дә китеп барды әнкәй
Һәм җылысыз калды безнең оя.
Үз дөньясын алып китте әнкәй,
Кителепләр төште безнеке дә.
Ахыргача бөтенәймәс хәзер,
Мөмкин булмас аны төзәтергә...

Фәйрүзә Мөслимова да каләмдәшләре арасында зур ихтирам казанып яшәде. Ул русчаны да, туган телен дә яхшы белгән, тирән гыйлемле әдибә иде. Шуңа съездлар, җыелышлар вакытында протокол кебек документларны аңа язарга куштылар. Шуңа карамастан ул бервакытта да борынын күтәреп йөрмәде. Кыскасы, төрле интригаларга катнашмавы, сүз йөртмәве, чиста күңелле булуы, гадилеге белән дә әүлияләргә тиң гали зат иде ул. Шагыйрә буларак та, чакыру ясалган бер генә очрашудан да баш тартмагандыр. Чөнки чакыручылар аның никадәр яхшы юлдаш, төркемдәшләренә тыныч холыклы, мәрхәмәтле иптәш икәнен белә иде. Чыгыш ясаганда да, ул бервакытта да чәчрәп алдан йөрми. Коллегаларына да, тамашачыга да тирән ихтирам саклап, үзен әдәпле һәм тыйнак тотып, сүзен үлчәп әйтә белә иде. Шуңа күрә язучылар, Фәйрүзә белән каядыр баруны бәхеткә санап, юлга кузгала иде. Минем, мәсәлән, бик күп мәртәбәләр сәфәрем Фәйрүзә Мөслимова белән туры килде.

Ерак юлга чыксак, һәрвакыт үзе пешергән ризык яки үзе ясаган алма кагы ала. Кайда гына булсак та, биш вакыт намазын сәгатен кичектермичә укый иде. Фәйрүзә, гомумән, гыйлем эстәүдән бервакытта да туктамады. Вакытлы матбугатны да даими алдырып, дини гыйлемен дә туктаусыз баетып, үстереп яшәде. Шул ук вакытта бакчасын да ташламыйча яшелчәсен, җиләк-җимешен үстерде. Аның тырышлыгын һәм чырышлыгын тормышының һәр өлкәсендә күреп була иде. Шигырендәгечә.

Җир йөзенә кояш чыга, кояш байый,
Җир йөзенә яңгыр ява – сулар таша.
Шул дөньяда һәрбер кеше
кырмыскадай
Үз саламын сөйрәп бара еллар аша.
Йөргән булам мин дә шулай
салам сөйрәп,
Бетми генә. Югыйсә бит әллә кайчан
Эскерт үсте,
Без ташыган саламнардан...

Фәйрүзәбезне югалтуыбыз зур кайгы булса да, аның акыллы итеп яшәгән гомер юлы үзе өчен үкенерлек булмагандыр. Фәйрүзә дөрес итеп, матур итеп, иманлы итеп яшәде. Авырлыкларны сабырлык белән җиңеп, авызындагы кара канын эчкә йотып. Сыкранганда язылган «Тол хатын», «Көндәшем» кебек шигырьләре булса да, яралы йөрәген, китап исеме итеп алынган «Ярату яралары» күрсәтеп торса да, алар Фәйрүзә иҗатының төп нигезен тәшкил итми. Фәйрүзә искиткеч сабыр, көчле рухлы ханым, талантлы шагыйрә, прозада да көч сынаган, бик матур ягымлы хикәяләр калдырган язучы иде. Күпләргә үрнәк булып, мохтаҗларга таяныч булып, яшәде. Балаларын, оныкларын өзелеп яратып яшәде.

Тирә-якта дус бар, дошман бар,
Тормыш дәрьясында чайкалам.
Кемгә кирәк соң мин, дип уйлыйм да,
Кофер уйны куып тукталам:
– Аһ, балам!
Нинди матур минем дөньям, димен,
Ай-Кояшка карап сокланам.
Шобһәле төш күреп уянсам да,
Зиһенемнән читкә аткарам:
– Аһ, балам!..

Каләмдәшләренә мәрхәмәтле булуы, кешене эш урынына, дәрәҗәсенә карап сортларга аермавы, аның кече күңелле, олы йөрәкле чын Кеше булуы турында сөйли иде. Әйтик, кемнәрдер тарафыннан якты йөз күрмәгән каләм ияләре дә аның өй бүлмәсендә кадерле кунак иде.

Китәләр яңгырлы юллардан –
Болытлы күлләрне кичәләр.
Күңелдә кала тик яктырып
Бергәләп үткәргән кичәләр...

Фәйрүзә Әсхәт кызы Мөслимова намуслы итеп яшәгән сирәк кешеләрнең берсе булды. Тирән итеп дингә чумып, чын күңеленнән инанып, соклангыч дәрәҗәдәге тыйнаклык белән яшәде ул. Юнәлгән кыйбласыннан тайпылмады. Бу сыйфатлары аның күп шигырьләрендә чагыла.

Әйтерсең лә миннән калмый
Бер кечкенә кеше йөри:
Барысын да белеп тора,
Үзен генә һичкем күрми.
Яхшыга да, яманга да
Бәя бирә һәр эшемә.
Дөнья-мәхшәр алдый алмас,
Тигезләнсәм шул «кеше»гә.
...Бер кыйбладан икенчегә
Сикермәсен, ди ул, ялгыш.
Юл сабучым һәм киңәшчем
Ул «кеше» бит – минем намус!

Киткәненә артык күп тә түгел, тик инде ул, үзәкләрне өзеп сагындыра. Юклыгына ышанасы килмичә сагындыра. Әле күптәнме аның миндә, минем аларда тәмләп чәй эчкән көннәребез... Борай ярмасы һәм күркә итеннән вак бәлеш пешергән иде. Башында ак яулык, билендә алъяпкыч. Юка гәүдәсе сылу, төз. Якты йөзендә, нурлы күзләрендә елмаю, кунакчыллык...

Дөньялыкта көрешергә язсын...
Ә дөньясы бер кыл өстендә
Дөньялыкта имин тормыш теләп
Калган олан-онык өчен дә –
Мәңгелеккә беркөн китәсез сез...
Сабырлыклар бирсен кешегә.
Һәрбер гомер – мизгел генә бары,
Дөньясы да тик кыл өстендә...

Дөньясы да, кеше гомере дә кыл өстендә икән шул. Болытсыз, яңгырсыз, давылсыз сәгатьләрдә, көтмәгәндә китеп баруы, чалт аяз көнне яшен суккандай кинәт булды. Хәтта авырганын да ишетеп өлгермәгән идек бит. Үзе кебек тыныч, кешеләрне хафага салмаган соңгы юл...

Уттан ала, суга сала бу дөнья,
Һәрнәрсәдән йөрәгеңдә эз кала.
Утыннан да, суыннан да аралап,
Ак кәгазьдә коткаручы СҮЗ кала...

Култамга белән бүләк ителгән бер китабында ул миңа: «Яралы булсак та, яра булмыйк!» – дип язып биргән (2001 ел). Бу - Фәйрүзә Мөслимова гына әйтә ала торган саллы да, фәлсәфи дә, тәрбияви дә шигырьләр, галиҗәнап сүзләр. Алар минем эш өстәлемдә. Димәк, һәр сәгать, һәр минут күз алдымда... Сүзләре хәтеремдә, йөрәгемдә!..

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.

Космостагы чүп-чар

Космоста чүп-чар көннән-көн арта бара, бервакыт ул шулкадәр күбәеп, яңа иярченнәр җибәрергә урын да калмаска мөмкин. Галимнәр исәпләп чыгаруынча, хәзер анда үлчәме 1 миллиметрдан зуррак 128 миллионга якын һәм 10 сантиметрдан зуррак 34 меңләп кисәк чүп бар. 1 миллиметрдан да кечерәкләрен исә санап бетерерлек түгел – орбитада триллионнарча кисәкчә әйләнә. 3 меңләп ясалма иярчен чүп-чар аркасында сафтан чыккан һәм үзләре чүпкә әверелгән. Зур тизлектә әйләнгәнгә, үлчәме 1 сантиметрдан да кечерәк булган кисәкчекләр дә орбитадагы станциянең метеоритлардан саклагыч бронясын тишәргә сәләтле, ә инде 10 сантиметрдан зуррак объект белән бәрелешкәндә теләсә нинди космик аппарат яки станция шундук челпәрәмә килә. РФА Астрономия институтының өлкән гыйльми хезмәткәре Наил Бәхтигәрәев әйтүенчә, космостан үлчәме 20 сантиметрдан зуррак чүп-чарны гына җыеп алып була, ә кечерәкләреннән котылу юллары, инде 60 ел эзләнсә дә, һаман табылмый. Бүген иске иярченнәрне күрше орбиталарга күчерү технологиясе яхшы эшли, әмма әлеге ысул нигәдер сирәк кулланыла. Космостагы чүп-чар Җиргә дә төшерелә әле. Зур ясалма иярченнәр һәм йөк кораблары Тын океандагы Немо ноктасы янында – планетабыздагы коры җирдән иң ерак урнашкан урында – суга батырыла. Бу урында корабларга йөзү һәм самолетларга очу тыела. 1971 елдан 2016 елга кадәр анда кимендә 260 аппарат батырылган – шул рәвешле космостагы чүп проблемасы Җирдәге проблемага да әйләнгән инде.

(“РБК”).

Солы боткасы чирдән саклый

Диетологлар көндәлек рационга инде классикага әйләнгән солы боткасын кертергә куша. Янәсе, ул бөтен ризыктан да файдалырак. Ньюкасл университеты галиме Крис Сил, иртән ашалган бер тәлинкә солы боткасы теләсә кайсы кешенең сәламәтлеген яхшырта ала, дип ышандырмакчы була. Доктор әйтүенчә, анда файдалы азык җепселләре, магний, тимер, бакыр, B төркеме витаминнары күп, май һәм шикәр аз. Солы боткасы ашказанын тыгыз гель кебек урап ала һәм туклык хисе тудыра, шул ук вакытта файдалы бактерияләр өчен ризык булып тора, иммун системаны ныгыта, холестерин микъдарын киметә. Тикшеренү көн саен 70 грамм солы боткасы ашаудан кандагы куркыныч холестерин микъдарының 7 процентка кимүен күрсәткән. Профессор Сил әйтүенчә, солыдагы бета-глюкан – онкологик чирләрдән саклый торган сирәк табигый матдәләрдән берсе. Кайбер белгечләр солы боткасында тимернең артык күплегенә хафаланса да, бу арзанлы продукт иң кыйбатлы даруларга көндәш була ала. 14 еллык тикшеренү күрсәткәнчә, солы боткасы йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан да саклый, гомерне озайта. Әммә Британия докторлары әйтүенчә, сәламәтлек өчен никадәр файдалы булуын белсәләр дә, яшьләр солы боткасын яратып ашамый, алар аны артык гади һәм арзанга саный. Азык җитештерүчеләргә дә файдалырак түгел, бәлки табышлырак ризыкны рекламалау һәм сату кызыграк.

(“МедНовости.ру”).

Дубай тәхете варисының затлы малы

Гарәп Әмирлекләрендәге иң бай шәех – 39 яшьлек Хәмдән ибне Мөхәммәд әл-Мәктүм. Искиткеч затлы малга ия булса да, ул Инстаграм сәхифәсендә аларны күрсәтеп мактанмый, бәлки үзе төшергән фотоларны гына куеп бара. Без исә аның иң кыйбатлы мөлкәтен барларга булдык. Шәех дөяләрне бик ярата, гүзәллек конкурсында 17 мең хайван арасында иң матуры дип табылганын исә 2,7 миллион долларга сатып алган! Шотландиядәге утары 63 мең акр мәйдан били, якын арада анда принц һәм аның гаиләсенә ауга килгәндә яшәр өчен йорт төзелеп бетәчәк. The Python амфибия-машинасының берсе 150 мең доллар тора, шәехнең исә шундый алты машинасы бар. Тәхет варисының тагын бер мөлкәте - дөньядагы иң зиннәтле кунакханәләрдән саналган архитектура җәүһәрен бизәүгә генә дә 12 миллиард доллар акча сарыф ителгән. 2014 елда шәех 6,5 миллион долларга өч аргамак сатып алган, ул үзе ат чабышларында катнаша һәм еш җиңә. Шәех гаиләсе 40 Boeing 787-10 Dreamliners самолетына да хуҗа, мондый бер очкыч 306 миллион доллар тора. Ripsaw танкының берсе 500 мең долларга бәяләнә, принцның исә мондый танклары берничә. Lamborghini Veneno Roadster – бик сирәк машина, 2014 елда шундый 9 автомобиль җитештерелгән, шулардан алтысы – Хәмдән әл-Мәктүмнеке. Һәркайсы 4,5 миллион доллар тора, димәк, 750 шәр ат көчле яраткан машиналарын сатып алуга барлыгы 27 миллион доллар акча тоткан. 3 секундта 60 чакрым үтәргә сәләтле McLaren гибрид супермашинасы да шәех гаражын бизи. Ferrari La Ferrari маркалы ике машинасын ул аукционда 7 һәм 10 миллион долларга сатып алган. Шәехнең 731 ат көчле Ferrari F12 Berlinetta автомобиле 60 чакрымны 2,8 секундта үтәргә сәләтле. Дөньяда иң тизйөрешле спорт автомобиле буларак мәгълүм Bugatti Veyron машинасы да бар әле Хәмдән әл-Мәктүмнең, ул 1,7 миллион долларга бәяләнә.

(“Russianemirates.com”).

● Двойной Ferrari.

Газета өчен
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

21 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.30 «КОРОТКОЕ ДЫХАНИЕ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Акыл баттл» һәм «Сәйлән».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30, 21.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «БИТВА ЗА ЗЕМЛЮ». 16+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Открытый космос».
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
23.20 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ВТОРОЕ ДЫХАНИЕ». 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «КОГДА ЗАКОНЧИТСЯ ФЕВРАЛЬ». 12+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Олег Каравайчук.
7.35 «Дамы и господа доисторических времен».
8.35 «Либретто». П.Чайковский «Лебединое озеро».
8.50 «ЖДИТЕ «ДЖОНА ГРАФТОНА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Поет Тамара Синявская».
12.00 Дневник фестиваля искусств Юрия Башмета.
12.30 «ДОЖИВЕМ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА».
14.15 «Лингвистический детектив. Андрей Зализняк».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.20 «Забытое ремесло».
16.40 «БУМБАРАШ».
17.45 Фестиваль в Вербье. Марк Бушков и Дмитрий Маслеев.
18.40 «История Преображенского полка, или Железная стена».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 «Сати. Нескучная классика...»
21.15 Юбилей Веры Алентовой. Линия жизни.
22.10 «ВРЕМЯ ЖЕЛАНИЙ».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+
23.35 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

22 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОТКОЕ ДЫХАНИЕ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Чёрное озеро». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Язмыш». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30, 21.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «С ПЯТИ ДО СЕМИ». 16+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Погоня за вкусом». 16+
16.20 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
22.25 Юбилейный концерт Вячеслава Бутусова. 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ВТОРОЕ ДЫХАНИЕ». 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «КОГДА ЗАКОНЧИТСЯ ФЕВРАЛЬ». 12+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35 «Франция. Путешествие во времени».
8.35 Цвет времени. Анатолий Зверев.
8.50 «ЖДИТЕ «ДЖОНА ГРАФТОНА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Владимир Этуш. Юбилейный вечер».
12.00 Дневник фестиваля искусств Юрия Башмета.
12.30 «ВАНЯ».
14.05 «Познавая цвет войны».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Александр Борисов».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
16.30 Цвет времени. Карандаш.
16.40 «БУМБАРАШ».
17.45 Фестиваль в Вербье. Леонидас Кавакос и Фестивальный оркестр Вербье.
18.40 «История Семеновского полка, или Небываемое бывает».
19.45 Главная роль.
20.35 «Евгений Куропатков. Монолог о времени и о себе».
21.30 «Белая студия».
22.15 «БАЛЛАДА О СОЛДАТЕ».
23.40 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+
23.35 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

23 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «Күңелем минем...» Җәвит Шакировның юбилей кичәсе. 6+
12.30 «Татарлар». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «ПУНКТ ПРОПУСКА. ОФИЦЕРСКАЯ ИСТОРИЯ». 16+
16.00 Концерт Эльмиры Калимуллиной. 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.20 «Соотечественники». 12+
22.10 «Мисс Татарстан-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Палитра». 6+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30, 21.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
11.30 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00 «СТО ДНЕЙ СВОБОДЫ». 12+
16.30 «Концерт ко Дню Защитника Отечества».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.50 «ТУННЕЛЬ: ОПАСНО ДЛЯ ЖИЗНИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро».
10.00, 12.00 Новости.
10.10 «АЛЕКСАНДР НЕВСКИЙ». 12+
12.10 «КРЕПОСТЬ БАДАБЕР». 16+
15.55 Концерт Ансамбля имени Александрова в Большом театре 12+
17.20 Юбилейный концерт Николая Расторгуева и группы «Любэ». 12+
19.00 «СИРИЙСКАЯ СОНАТА». 16+
21.00 «Время».
21.20 «ОФИЦЕРЫ». 6+
23.05 Концерт «Офицеры». 12+

«РОССИЯ»

4.40 «ЛЮБОВЬ НЕ ПО ПРАВИЛАМ». 12+
6.20 «ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА ГЕНЕРАЛА». 16+
10.10 «Сто к одному».
11.00, 20.00 Вести.
11.20 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
12.25 «МАРШРУТЫ ЛЮБВИ». 12+
16.10 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ». 6+
18.00 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню защитника Отечества.
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «ОГОНЬ». 6+
23.50 «ЭКИПАЖ». 6+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Приключения волшебного глобуса, или Проделки ведьмы».
7.50 «БУМБАРАШ».
10.00 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.30 «БАЛЛАДА О СОЛДАТЕ».
12.00 Дневник фестиваля искусств Юрия Башмета.
12.30 «Айболит-66». Нормальные герои всегда идут в обход».
13.10 «Как животные разговаривают».
14.00 «ТРУФФАЛЬДИНО ИЗ БЕРГАМО».
16.15 Концерт Ансамбля песни и пляски Российской Армии имени А.В. Александрова в Большом театре России.
17.30 «Через минное поле к пророкам».
18.30 «ЧЕЛОВЕК-АМФИБИЯ».
20.05 «Романтика романса».
21.00 «МЕРТВЫЙ СЕЗОН».
23.15 Вероника Джиоева, Василий Ладюк, Василий Петренко, ГАСО России имени Е.Ф.Светланова. Знаменитые оперные арии и дуэты.

«НТВ»

4.55 «ЛЕЙТЕНАНТ СУВОРОВ». 12+
6.35 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 12+
7.35, 8.20 «ОТСТАВНИК». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
10.20 «ОТСТАВНИК-2». 16+
12.20 «ОТСТАВНИК-3». 16+
14.30, 16.20 «ОТСТАВНИК. ОДИН ЗА ВСЕХ». 16+
17.00 «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА». 16+
19.40 «ДИНА И ДОБЕРМАН». 12+

Пәнҗешәмбе

24 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОТКОЕ ДЫХАНИЕ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
230.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Бакый Урманче турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30, 21.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
11.30 «Погоня за вкусом». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПОХОРОНИТЕ МЕНЯ ЗА ПЛИНТУСОМ». 16+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Вокруг света. Места силы». 16+
16.20 «Три кота».
17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «КРАСНЫЙ ПРИЗРАК». 16+
23.25 «Большая игра». 16+
0.20 «Его звали Майор Вихрь». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ». 6+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «КОГДА ЗАКОНЧИТСЯ ФЕВРАЛЬ». 12+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35 «Неаполь. Жизнь на вулкане».
8.35 Цвет времени. Ар-деко.
8.50 «ТРУФФАЛЬДИНО ИЗ БЕРГАМО».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Иосиф Бродский. Поэт о поэтах».
12.00 Дневник фестиваля искусств Юрия Башмета.
12.25 «ВСЕМ - СПАСИБО!..».
14.00 Цвет времени. Рене Магритт.
14.15 Острова. Всеволод Санаев.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Нижегородский гипюр».
15.50 «2 Верник 2».
16.35 «МЕРТВЫЙ СЕЗОН».
17.45 Фестиваль в Вербье. Кристоф Барати, Валерий Гергиев и Фестивальный оркестр.
18.35 К 75-летию Евгения Зевина. Линия жизни.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Игорь Волгин. «Странные сближенья».
20.35 «Наш, только наш».
21.20 «Энигма. Теодор Курентзис».
22.05 «ПАРАД ПЛАНЕТ».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.25 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+
23.45 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

25 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОТКОЕ ДЫХАНИЕ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «ДВЕ ВЕРСИИ ОДНОГО СТОЛКНОВЕНИЯ». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 14.00, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Родная земля». 12+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Сәгыйть Хәбибуллин турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30, 21.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «МАДАМ». 16+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Это реальная история». 16+
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.30 «Голос. Дети».
23.05 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 20.45 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ПОСТОРОННЯЯ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.00 «Юморина». 16+
23.50 «ОГОНЬ». 6+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35 «Душа Петербурга».
8.35, 17.45 «Забытое ремесло».
8.50 «ТРУФФАЛЬДИНО ИЗ БЕРГАМО».
10.20 «ЛЮБИМАЯ ДЕВУШКА».
11.50 Открытая книга. Игорь Волгин. «Странные сближенья».
12.15 «ЧЕЛОВЕК-АМФИБИЯ».
13.50 «Франция. Замок Шенонсо».
14.20 Власть факта. «Священный союз и трудный выбор Александра I».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Теодор Курентзис».
16.20 Цвет времени. Эдвард Мунк. «Крик».
16.35 «МЕРТВЫЙ СЕЗОН».
18.00 «Билет в Большой».
18.45 «Другая история».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Линия жизни. Максим Никулин.
21.15 «КОГДА ДЕРЕВЬЯ БЫЛИ БОЛЬШИМИ».
22.45 «2 Верник 2».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00, 14.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+
23.25 «Своя правда». 16+

Шимбә

26 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.20 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «УЕННАН УЙМАК 2». 12+
16.00 «Татар халык җырлары».
16.30 «Юлчы». 6+
17.00 «Әдәби хәзинә». 6+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «ГОД ТЕЛЁНКА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Риф Гатауллин турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Мин бу җирне матурларга тудым». Әнгам Атнабаев иҗатына багышланган кичә. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Моң-җырлары - ак җилкән». Ганс Сәйфуллинның юбилей кичәсе. 12+
22.30 Спектакль «Хуҗа Насретдин». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Это лечится». 12+
5.30 «Люди РФ». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Сказочный патруль».
8.00 «Непростые вещи». 12+
8.30 «ПЕРЕВОДЧИК». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДЕВУШКА ГРЕЗ». 16+
14.45 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БОРГ/МАКИНРОЙ». 16+
22.50 «Человек - невидимка». 16+
23.45 «Цвет из иных миров». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00 Новости.
10.15 «Операция «Динамо», или Приключения русских в Британии». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
13.30 «РАБА ЛЮБВИ». 12+
15.20 «Кто хочет стать миллионером?»
17.00 «Точь-в-точь». 16+
19.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.20 «КВН». 16+
23.35 Музыкальная премия «Жара». 12+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
12.50 «Доктор Мясников». 12+
13.50 «ТОЧКА КИПЕНИЯ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
20.00 Вести в субботу.
21.00 «ЗАГС». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.25 «КОГДА ДЕРЕВЬЯ БЫЛИ БОЛЬШИМИ».
10.00 «Передвижники. Николай Кузнецов».
10.30 «АННА НА ШЕЕ».
11.55 «Спасти от варваров».
12.35 Человеческий фактор. «Заводской блокнот».
13.05 «Эти огненные фламинго. В мире красок и тайн».
14.00 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
15.35 III Всероссийский конкурс молодых музыкантов «Созвездие».
17.10 «СТАРАЯ, СТАРАЯ СКАЗКА».
18.40 «Технологии счастья».
19.25 «Энциклопедия загадок».
19.50 «ЗАБЫТАЯ МЕЛОДИЯ ДЛЯ ФЛЕЙТЫ».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб шаболовка 37.

«НТВ»

4.45 «ЧП. Расследование». 16+
5.10 «ДОКТОР ЛИЗА». 12+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.50 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 Ты не поверишь! 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

27 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Мин бу җирне матурларга тудым». Әнгам Атнабаев иҗатына багышланган кичә. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Хайкю». 12+
9.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.20 «Бәхет язым». Нәфкать Нигъмәтуллин концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Зифәр Харисовның юбилей кичәсе». 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Профсоюз - союз сильных». 12+
20.15 «Батырлар». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ДЕЛО ДЛЯ НАСТОЯЩИХ МУЖЧИН». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35, 23.20 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Ул бит кичә иде». 12+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Риф Гатауллин турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 Эльмир Низамовның иҗат кичәсе. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Спектакль «Хәят». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Клинический случай». 12+
5.30, 8.30, 15.00 «Люди РФ». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Сказочный патруль».
8.00 «Эпидемия». 12+
9.00 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БОРГ/МАКИНРОЙ». 16+
15.30 «ПЕРЕВОДЧИК». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДЕВУШКА ГРЕЗ». 16+
22.45 «Шерлоки». 16+
23.35 «ОККУПАЦИЯ: МИССИЯ «ДОЖДЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

4.55, 6.10 «ВРЕМЯ СОБИРАТЬ КАМНИ». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
13.55 К юбилею Веры Алентовой. «Как долго я тебя искала...» 12+
15.00 «ШИРЛИ-МЫРЛИ». 16+
17.45 Концерт Максима Галкина. 12+
19.05 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.00 «Уроки фарси». 16+

«РОССИЯ»

5.20 «ЖИЗНЬ ПОСЛЕ ЖИЗНИ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «Парад юмора». 16+
13.50 «ТОЧКА КИПЕНИЯ». 16+
17.50 «Танцы со Звёздами». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 «Храбрый олененок».
7.30 «СТАРАЯ, СТАРАЯ СКАЗКА».
9.00 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.30 «Мы - грамотеи!»
10.10 «ПОРТРЕТ ЖЕНЫ ХУДОЖНИКА».
11.35 Диалоги о животных.
12.20 Невский ковчег. Теория невозможного.
12.45 «Архи-важно».
13.15 «Игра в бисер» «Джеймс Джойс. «Портрет художника в юности».
13.55 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
15.20 «ВНЕЗАПНО, ПРОШЛЫМ ЛЕТОМ».
17.10 «Пешком...»
17.40 75 лет Авангарду Леонтьеву. Линия жизни.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ЧИСТОЕ НЕБО».
22.00 Гала-концерт в честь 350-летия Парижской национальной оперы.

«НТВ»

4.55 «НАШИХ БЬЮТ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Маска». Новый сезон. 12+
23.35 «Звезды сошлись». 16+

Хезмәт урынында үлемле очраклар килеп чыккач фаҗигагә юл куйган җаваплы хезмәткәрләр хөкемгә тартыла. Шул ук вакытта бәлагә дучар булучыларның саксызлык күрсәтүе исәпкә алына, еш кына җинаять эзәрлекләве туктатыла. Узган ел Әлмәт шәһәр судында нефтьчеләр оешмаларында булган ике хәвеф-хәтәр буенча якларның килешүе дигән билгеләмә белән шундый карарлар кабул ителде.

Җинаятьчел җавапсызлылык

2020 елның 1 августында нефть чыгару скважиналарына капиталь ремонт ясау белән шөгыльләнә торган ширкәттә гадәти эш көне була. Әлмәттән ерак булмаган бер «качалка»ны төзәтүне төгәлләгән бригада, мәсәлән, Колшәрип авылы янындагы икенчесенә күчәргә җыена. Иртә белән аеклыкка тикшеренү, хәвефсезлек буенча инструктаж узганнан соң бораулаучы Илдар Гарипов, күтәргеч машинисты Фаяз Мозаффаров, бораулаучы ярдәмчесе Искәндәр Хәйретдинов көнкүреш вагоны, эш кораллары будкасы, суырту, күтәрү җайланмалары һәм башка биниһая күп кирәк-яракны зур машиналарга урнаштыралар, ә төштән соң яңа урынга таба кузгалалар.

34-36 яшьләрендәге тәҗрибәле ир-атлар барып җиткәч тә үз вазифаларын үтәргә керешәләр, ягъни җиһазларны бушатып урнаштыру белән шөгыльләнәләр. Һәрвакыт башкарыла торган гадәти эшне мастер Рамил Хафизов килеп җиткәнче үк башлыйлар, шул рәвешле, ток үткәргеч чыбыклар сузыла, бетон мәйданчыкка куелган узара «культвагон», «сушилка» дип йөртелүче көнкүреш вагонына ут тоташтырыла, кыскасы, бар да үз җае белән бара. Ләкин тиздән моның читтән караганда гына шулай булуы ачыклана.

Көндезге сәгать 3 тулганда, бурильщик И.Гариповның кисәк кычкырып җибәрүе ишетелә. Үз эшләре белән мәшгуль ике ир-ат борылып карагач та, көнкүреш вагоны баскычы култыксасына тотынып, чүгәләп катып калган хезмәттәшләрен күрәләр. Аны ток сугуы шунда ук аңлашыла, Искәндәр электр щиты янына йөгерә, яңа тоташтырылган штепсельне тартып алып, токны өзә, бичара Илдарның кулы тимер торбадан аерыла һәм ул җиргә, төгәлрәге, бетонга сыерылып төшә. Беренче ярдәм күрсәтү буенча хәзерлеге булган Искәндәр белән Фаяз шунда ук, чынлыкта, инде үлгән дусларына җан кертергә тырышып азапланалар. Шул арада килеп җиткән мастер Р.Хафизов хәвефле хәбәрне тиешле урыннарга ирештерә.

Тикшерү комитетының Әлмәт шәһәре бүлегеннән Эмиль Солтанов хезмәтне саклау кагыйдәләрен бозу сәбәпле, саксызлык белән кеше үлеменә китерү очрагы буенча җинаять эше кузгата. Металлдан эшләнгән вагонга токның «ноль фазасы» урынына 380 вольт көчәнешле үткәргеч тоташтырылу, димәк, мәрхүм И.Гариповның ялгышуы аркасында эләгүе шунда ук ачыклана. Өстәвенә, вагон тиешле тәртиптә җиргә тоташтырылмаган булган.

Белгечләр, әгәр «заземление» булса, Гарипов баскычка килеп җиткәнче үк, хәвеф барын сизәр һәм кире борылыр иде диләр. Димәк, электр белән бәйле эшләрне шуннан башларга кирәк булган. Бусы да ун елдан артык шушы оешмада хезмәт куйган тәҗрибәле, белемле-хәзерлекле кеше үз саксызлыгы корбаны булган дигән фикергә этәрә.

Чиксез кайгы-хәсрәткә дучар булып 32 яшендә тол калган ханым да ире бәхетсезлеккә юлыккан дип саный, җинаять эшендә зарар күрүче булса да, беркемне дә гаепләми, дәгъва белдерми. Нефть чыгару оешмасы туйдыручысын югалткан гаиләне ярдәмсез калдырмагандыр.

Әлеге шаукымлы вакыйганы «Татнефть» җәмгыяте комиссиясе дә тикшерә һәм, кыскача гына әйтсәк, фаҗига Илдар Гариповның электр куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуы аркасында килеп чыккан дип таба. Чыннан да, бораулаучының электр тоташтыруын, ягъни вилканы розеткага тыкканын мастер яисә башка җитәкче карап торырга тиеш түгел кебек. Ләкин монда бер мөһим мәсьәлә читтә кала. Эш шунда ки, бригада алып килгән кабельдәге дүрт тармаклы вилкада аны ялгыш тоташтырырга мөмкинлек бирмәүче, димәк, токның «массага», ягъни тимер вагонга китүенә юл куймаучы җайланма (предохранитель) торырга тиеш була. Кызганычка, бу очракта яраксыз хәлгә килгән әлеге җайланма бәхетсезлекне кисәтә алмый. Шуңа күрә бар гаепне мәрхүмгә өю дә гадел булмый.

Аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче Э.Солтанов та эшкә нокта куярга җыенмый. Озын-озакка сузылган тикшерү эшләре Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы экспертлары үткәргән техник экспертиза нәтиҗәләре билгеле булгач борылыш ала. Анда ватык вилка, тоташтырылмаган «заземление» гына түгел, шактый кимчелекләр, бигрәк тә, мастер Р.Хафизов тарафыннан юл куелган, ахыр чиктә, аяныч фаҗига килеп чыгарга этәргеч биргән җитешсезлекләр күрсәтелә.

Әлеге экспертиза нәтиҗәләре белән танышкач, элегрәк шаһит буларак биргән күрсәтмәләрендә үзен аклап сөйләгән мастер Р.Хафизов кеше үлеменә китергән саксызлык күрсәтүен тануын белдереп беркетмә төзи. Үзләре үткәргән тикшерү вакытында ошбу мәртәбәле мастерның бер генә җитешсезлеген дә күрсәтмәгән «Татнефть»нең җаваплы хезмәткәрләре экспертлар фикере белән килешә. Ниһаять, 1969 елгы Рамил Хафизовка Җинаять кодексының 143 нче маддәсе буенча рәсми гаепләү белдерелә һәм ярты ел дигәндә эш суд карамагына бирелә. Әйтелгәнчә, ул зарар күргән якның мәрхәмәтлелек күрсәтүе сәбәпле һәм И.Гариповның саксыз кылануы исәпкә алынып, мөхтәрәм кешене җәзасыз калдырырга дигән карар чыгара.

Монда эшләүчеләр пандемия башлангач та, хезмәткәрләр саны кимегәч, түләү начарлаудан зарланалар, эшче куллар җитмәгәч берьюлы ике кеше өчен эшләргә туры килә диләр. 2021 елның 18 июнендә химик продукция җитештерү цехының Миңнебай станциясендә урнашкан 2 нче участогына төнге сменага өч аппаратчы чыга. Ягъни 1968 елгы Юрий Мартынов, 33-34 яшьләрендәге Алексей Пегов, Тимур Гарифуллин кичке 7 дән иртәнге 7 гә чаклы элек мастер җитәкчелегендә 5-6 кеше башкарган эшне үтәргә тиеш була. Димәк, техник һәм җитәкче хезмәткәрләр ягыннан беркинди контроль булмый. Дөрес, цех башлыгы Илшат Әбүнәгыймов мастер вазифаларын Тимурга йөкли. Телдән генә әйтелгән әмернең нәтиҗәсе булмый, әлбәттә. Мастер булып йөрсәм, эшләргә кеше калмас иде дип, Тимур үзе дә әлеге вазифаларны үтәвен кире кага.

Шулай итеп махсус киемнәр кимәгән өч аппаратчы үз эшләрен башкара. Кичке сәгать 11 нчедә өлкәнрәк Ю.Мартынов 200 литрлы мичкәләрдәге аеруча хәтәрләр рәтендәге фтор-водород кислотасын химик катнашма ясый торган күләмле савытларга суыртып агыза, инструкция буенча ике хезмәткәр эшләргә тиешле урында үзе генә кайнаша. Бишенче мичкә бушады дигәндә агач аслык тактасы сынып китү сәбәпле аның янындагы тулы мичкә ава, үтергеч сыеклык Юрийның сул боты, балтырына чәчри.

Әйтергә кирәк, әгәр ул резин итекләр, махсус алъяпкычтан гына булса да, нәтиҗә ул кадәр үк хәвефле булмас иде. Абзый шунда ук чалбарын салып шланг белән агызып су сиптерә башласа да, зәһәр сыеклык пешереп-көйдереп өлгерә, сулыш юлларына зыян китерә. Хезмәттәшләре култыклап алып барып киемнәрен алмаштыралар, Тимур үз машинасында «Татнефть» җәмгыяте сырхауханәсенә алып китә аны. Ю.Мартынов шул арада килеп җиткән 24 яшьлек улы Максимга сырхауханәгә култык таяклары алып килергә куша, аягы төзәлгәнче алар ярдәмендә йөрергә уйлый, димәк. Ләкин туктаусыз йөткерүче ир-атның хәле кабул иту бүлмәсендә үк начарая да, аны реанимация бүлегенә салалар. Икенче көнне сәгать 10 да табиб төнне шунда үткәргән хәләл җефете һәм улына хәле яхшыру турында өметле хәбәр ирештерә. Ләкин ул чакта Юрийның ике-өч сәгать гомере калган була, янупешү өстенә сулыш юллары, үпкәгә килә торган артерия зарарлану аркасында җан бирә ул. Авыз-борынны каплап агулы матдәләрдән саклый торган битлек булмау да хәлиткеч роль уйный, димәк.

Үлемле фаҗига бик тиз ыгы-зыгы куптара. Әйтик, Тимур Гарифуллинны шунда ук эшенә чакырып китерәләр һәм мастер булып эшләргә гариза язарга тәкъдим итәләр, ләкин итәккә ут капкач күрсәтелгән ошбу ышаныч ир-атны шатландырмый. Чөнки берничә көн алданрак эшли башлады дип язачаклар да, кеше үлеменә китергән җитешсезлекләр өчен җавап тотарга туры киләчәген аңлый һәм тәкъдимне кире кага. Ә инде мастер юк икән, барысына да цех башлыгы И.Әбүнәгыймов гаепле булып чыга. Чарасызлыктан Ю.Мартынов үлгән көнне үк гаебен танып, мәрхүмнең гаиләсенә мөмкин булган кадәр матди ярдәм күрсәтәчәген белдереп, беркетмә төзи ул.

53 яшендә һәлак булган Юрий хатыны, 5, 12, 24 яшьләрендәге өч улы белән Миңнебай станциясе бистәсендә яшәгән, олы кызы гаиләсе белән күрше авылда тора. Якын кешесен югалткан ханым, өлкән кыз, җинаять эшендә зарар күрүче итеп билгеләнгән Максим беренче мәлдә бәхетсезлек очрагын җентекләп тикшерүне таләп итәләр, күрсәтмәләрендә эш урынындагы тәртипсезлек вә җитешсезлекләрне санап үтәләр, чөнки бу хакта мәрхүмнән күп тапкырлар ишеткән булалар. Кыскасы, гаепләүләрне кырыс җәзага тартырга телиләр.

Җинаять эшен тикшерү мәшәкатьле булмый. Төнге сменада цехта мастер булмау сәбәпле, эшчеләрнең контрольсез эшләве, Ю.Мартыновның ике хезмәткәр эшен ялгызы башкаруы, махсус киемнән, битлектән булмавы, ахыр чиктә, хәтәр кислота тулы мичкәләрнең черек поддонга куелуы һәм башка җитешсезлекләр ярылып ята, кеше үлеменә алар сәбәпче, төгәлрәге, цех җитәкчесе гаепле икәне дә аермачык. Шул ук вакытта мәрхүмнең ваемсызлыгын да билгеләп үтми ярамас. Адәм баласы иминлеге турында үзе дә кайгыртырга, кислотага бирешми торган киемне мастер яисә цех башлыгы мәҗбүр итмичә дә кияргә тиештер бит!..

Шунысы да күзгә ташлана, әлеге җитешсезлекләр соңгы ике елда даими күренешкә әверелгән. Бу инде ковид дигән зәхмәтнең икътисадның шушы нык тармагын да какшатуын раслый. Ләкин эш урынындагы үлем-китемнәрне аклый алмый бу. 1975 елгы И.Әбүнәгыймовка да хезмәтне саклау кагыйдәләрен бозу сәбәпле саксызлык белән кеше үтерү дигән җинаятьтә гаепләү белдерелә. Узган ел октябрь аенда җинаять эше судка тапшырыла.

Тора-бара зарар күргән якның гаепләнүчегә мөнәсәбәте йомшый төшә. Үлгәннәрне кайтарып булмый, исәннәрне кайгыртырга, иң әүвәл, ике кечкенә малайны аякка бастырырга кирәк. Бу җәһәттән оешманың 2 миллион 300 мең сумлык ярдәм күрсәтүен искәртик. Әлмәт шәһәр суды хөкемдарына якларның килешүе сәбәпле, җинаять эзәрлекләвен туктатырга дигән тагын бер карар чыгарырга гына кала. Мондый очракларда гаепләнүче җәзасыз калдырыла, әмма хөкем ителгән зат булып санала.

Наил ВАХИТОВ.

Көләч йөзле РӘМЗИЯ

Бүген күпләр тормышларын бизәбрәк күрсәтергә омтыла. Күңел бушлыгын тышкы ялтырау белән тутырмакчылар. Бу максатта интернет, социаль челтәрләрдән бик оста файдаланалар. Төрле матурлык салоннарына сорау зур. Шундый бер «Матур City»не Г.Кариев театрында күрдек. Анда чәчтараш, сакалкисәр, тырнакбуяр булып эшләүче кәттә егетләр авылдан килгән беркатлы Гөлнарадан күбрәк акча суырып калу турында ниятләгән булса, ахырдан Гөлнара үзе боларны яхшы якка үзгәртеп куя. Сүз Татарстанның атказанган артисты Рәмзия Закирҗанованың юбилее уңаеннан Айгөл Әхмәтгалиева әсәре буенча режиссер Ренат Әюпов куйган «Матур City» спектакле турында.

Спектакль җиңел комедия рухында хәл кылынган булса да, заманның тискәре күренешләрен тәнкыйть утына тота. Бүген кешеләрнең акыл-белемдә түгел, матурлыкта ярышулары, элек пышылдап колакка гына әйтелгән, күңелдә генә йөргән сөю, мәхәббәтне бөтен халык алдына чыгарып чәчүләре бер карауга мәзәк тоелса, шул ук вакытта кызганыч та. Тормыштан сер, яшерен мәгънәләр югалып, ул шәрә хатын-кызга охшый бара сыман. Бер сере калмаган шыр ялангач кыз-хатын исә кемгә кызык? Әдәбиятта, сәхнә әсәрләрендә дә шул ук хәл күзәтелә. Авторларның әлеге дә баягы үзләрен алга чыгарырга омтылулары нәтиҗәсендә тирәнлек, матурлык югала.

Спектакль геройлары Хәйрулла белән Гөлнара да күп еллар үткәч, бер-берсен социаль челтәрләрдә эзләп таба, очрашырга сүз куеша. Шуннан Гөлнара, гомер буе хәләл хезмәте белән җыйган акчаларын алып, шушы матурлык салонына килеп чыга да инде. Килсә, биредә протеже аша гына эләгеп булуын белгәч, авылдагы күршесе Салават исемен кыстырып җибәрүе була, кәттә егетләр җырчы Салават дип алданып, Гөлнараны хөрмәткә күмә. Салават, гади генә күрше түгел, Гөлнараны утыз ел буена яшерен яратучы тирән кичерешле кеше икән. Хәйруш исә социаль челтәрләрдә купшыланып утырган бер буш куык булып чыга. Чәчтараш егетләр Гөлнара белән Салаватның туен бушлай үз хисапларына уздырырлык дәрәҗәдә үзгәреш кичерә.

Композитор Камил Котдусов, хормейстер Лилия Зәйнуллина иҗат иткән, өйрәткән җыр-көйләр, балетмейстер Елена Музеева куйган биюләр спектакльгә заманча рух, җиңеллек, шуклык өсти. Хәзерге яшьләр рухында кап-карадан, сыланып торган чалбарлардан, чәчләренә «койрык» ясап, муен-беләкләренә татуировка төшереп чыккан урта буын актерлар Фәнис Кәлимуллин, Илфат Камалиевкә каравы гына да мәзәк. Алмачуар, Йосыф рольләре аркылы йөрәккә кереп калган Илнар Низамиев тә биредә бөтенләй үзгә амплуада – шоу-бизнес йолдызы Хәйрулла Хаевич, ягъни Хәйруш булып сәхнәгә чыкса да, килештереп уйный. Фернат Насыйбуллин (Салават) һәм Илсаф Нәҗипов (чәчтарашларның берсе) булмаса, ансамбльнең бер өлеше китек калыр иде. Кич буе биш асыл ир-атны үз тирәсендә биетүче, бенефис-спектакльнең сәбәпчесе Рәмзия Закирҗанова чын йолдыз сыман балкыды.

Спектакльнең юбилярга туры килеп сайлануын билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Кайбервакыт режиссерлар атаклы, күренекле шәхесләребезне авыру, сырхау халәтләрендә үткән елларын исләренә төшерүчеләр итеп сурәтли. Әлфия Авзалова турындагы шундый спектакль бигрәк тә күңелгә тигән иде. Татар тормышында мескенлек җитми, дигән сыман, аны сәхнәгә дә алып менәләр. «Матур City» исә, киресенчә, күтәренке рухы белән күңелләргә ошады. Юбилей булгач, әнә шундый булсын! Актер, актрисаларыбыз йолдыз сыман балкысын!

Әллә Рәмзия Закирҗанова тормышында авырлыклар булмаганмы? Анаң каршы була торып, тугызынчы сыйныфтан соң Азнакайдан Казан театр училищесына качып кит әле! Училище тәмамлап, ун ел академия театры сәхнәсендә «Асылъяр», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Казан егетләре», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Зәңгәр шәл» һ.б. танылган спектакльләрдә балкыганнан соң, Мәҗнүн башын югалтырлык чибәр, иҗат дәрте ташып торган чагында сәхнәдән бөтенләйгә китү актриса өчен нәрсә икәнен беләсезме? Тамашачы алкышлары, чәчкә бәйләмнәре төшләренә кермәгән дисезме? Сәхнә тузанын сагынып ялгыз чакларында үксемәгәнме? Тик хатын-кызның иң беренчел бурычы – иренә тугры дус, терәк, балаларына – ана, гаилә учагын саклаучы булу. Өстәвенә, тормыш иптәше Ленар Гыйльметдинов – республикабыз театрларында танылган сәхнә бизәүче рәссам. Ике сарык башы бер казанга сыймый, дигән кебек, ике иҗат иясенә бергә яшәүләре җиңел түгел. Рәмзия иренең иҗатына юл ачып, гаилә мәшәкатьләрен үз өстенә ала.

Ә инде нарасыйлары, канат ныгыткан кошлар сыман, тормыш күгендә үзләре очарга омтыла башлагач, Рәмзиябез кабат театр, сәхнәгә каерылып карый. Аңа кадәр утызлап кинофильмда төшсә дә, барыбер үзенеке җанга якын булып, ымсындыра. Режиссер Р.Әюповның чакыруын алып, ул Яшьләр театрына килә. Башта труппа мөдире булып эшли. Барысы да яшьләр. Аларны бер йодрыкка туплау җиңел бирелмәгәндер. Әмма бүген үзләре урта буын исәбендә йөргән артистлар труппа мөдирен хөрмәт белән искә ала. Чөнки Рәмзия берсенең гаебен, икенчесе алдында фаш итми, шыпырт кына колагына пышылдый. Бөтенесен бердәй күреп үз балаларыдай кайгырта, яклый, саклый белә.

Җәйге гастрольләр алдыннан күренекле актриса Халидә Сөнгатуллина авыру сәбәпле, режиссер Р.Закирҗанованы «Көзебезнең язы» спектакленә кертеп җибәрә. Хәзер исә аның «Сөннәтче бабай», «Кәҗүл читек», «Супер кияү», «Питер Пэн», «Ак чәчәкләр кебек...», «Нигез ташлары» кебек һ.б. тамашачы яратып карый торган спектакльләрдә рольләре бар. «Матур City»да исә ул нәкъ үзен уйнады. Рәмзия Закирҗанова, Гөлнара кебек, янып торган күмер күзле, горур, алтынны арзанлы ялтыравыктан аера белүче мәгънәле, көләч йөзле һәм тормышка бөтен барлыгы белән гашыйк актриса.

Бенефистан соң Р.Закирҗанованы депутат Альбина Насыйрова, Театр әһелләре берлеге җитәкчесе Фәрит Бикчәнтәев исеменнән Майя Швецова, төрле театрларыбызда иҗат итүче дуслары, хезмәттәшләре, курсташлары, әлбәттә, режиссер Р.Әюпов һәм театрның директоры Л.Янсуар тәбрикләде.

Бу кичәдә чәчкә бәйләмнәреннән дә, тамашачы алкышларыннан да көчлерәк тәэсирләндергән нәрсә – кеше кадере. Кариев театрында үлгәннәрне онытмыйча, исәннәрнең кадерен белеп яшиләр. Драматург Фәнәвил Галиевнең рухына багышлап куелган «Корт», Халидә Сөнгатуллина юбилеена иҗат ителгән «Яратып туялмадым», Нуриәхмәт Сафинның гомер бәйрәменә багышланган «Арыну», инде менә «Матур City»не күрдек. Артист өчен сәхнә тутырып уйнаудан да зуррак нинди бәхет бар?

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

**«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru**

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 18.02.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2740

16+